ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА



БЕЗНЕ ОНЫТМАГЫЗ

Фәүзия
Бәйрәмова

Безне онытмагыз

Казан
Татарстан китап нәшрияты
1998

ББК 84(Р-Тат)—6
Б86

Мөхәррире ФӘНЗАМАН БАТТАЛ

Б $\frac{4702560203—018}{М 132(03)—98}$ 61—96

ББК 84(Р-Тат.)—6

ISBN 5—298—00680—9

© Татарстан китап нәшрияты, 1998.

АТЫЛГАН ЙОЛДЫЗ

Драма 2 бүлектә

(Әсәрдә кулланылган барлык хатлар, тәнкыйть мәкаләләре, шигырьләр үзгәртелмичә файдаланылды.)

КАТНАШАЛАР:

Такташ.
Беренче Гөлчәһрә.
Ак дус.
Кара дус.
Икенче Гөлчәһрә.
Яшь шагыйрьләр, артистлар,
журналистлар, студентлар.

Вакыйга 1923—1931 елларда Казан шәһәрендә бара.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

1923 ел. Ул заманда шагыйрьләр, артистлар яши торган кунакханәләрнең берсе. Зур бүлмә. Бүлмәдә яшь шагыйрьләр, артистлар, студентлар. Пәрдә ачылганда гөжләшеп нәрсә турындадыр бәхәсләшәләр. Ак һәм Кара дуслар бәхәскә катнашмыйлар. Бер читтә шигырь тикшерәләр.

Яшь артист. Ну, малай, минем сәхнәдә андый хәлне күргән юк иде әле. Ул сәхнә артында янар таулар ут ата, ул сәхнәдә газраилләр, фәрештәләр очып йөри.

Я ш ь к е ш е *(бүлдереп).* Син чамалап сөйлә инде бераз. Очып йөри, имеш. Җырлап, кычкырып тордылар диген.

Я ш ь а р т и с т. Юк идең — дәшмә! Күрмәдең — белмисең! Ә менә мин әйтәм — очтылар, дим. Ул нәләтләр, ул ялварулар! Бу сиңа мич арасында гыйшык-мыйшык аңлату түгел инде. Бу — Такташ! «Җир уллары!» Вакыйга күкләрдә бара, җирдә! Аллалар, Адәм балалары... *(Кабил булып укый.)*

Ник мине ул, ник яраткан,
Куймагач юл иркемә?!
Ник минем бәхетемне биргән
Башкаларның иркенә?!
Ант итәм иркем белән, бел!
Әкълимә булыр минем,
Бирмимен мин башкаларга —
Ул минем аллам, динем!

И к е н ч е с е *(чәчрәп торып, Адәм булып укый):*

Ник тудырдым мин сине?
Аһ! Ник бала дип асрадым?
Ник сине туган вакыттук
Янган утка атмадым?!

Я ш ь а р т и с т *(Кабил булып):*

Ник атмадың?!!

И к е н ч е с е *(Адәм булып):*

Көчле утлар, зур тәмуглар
Мәңгелек йортың булыр.

(Йомшап.)

Тәүбә ит! Кем сөйләшә — ул куркыныч.

Я ш ь а р т и с т *(Кабил булып):*

Тәүбә!!!
Ха-ха-ха-ха-ха-ха-ха-ха!!
Бул тыныч!
Мин табынмыйм ул ходайга,
Ул ходай җәббар, явыз.
Мин табам башка ходай,
Ярдәмчене, бел: ул — кылыч!

Я ш ь к е ш е *(бүлдереп)*. Алла, дин, кылыч! Шушы да булдымы революция әсәре?! Соң моннан чит идеология, буржуалык аңкып тора бит! Кая монда эшчеләр тормышы, кая монда яңалык, кая монда илнең революцион адым белән алга баруы?! Нәрсә, Такташ революциягә каршымыни?

Я ш ь а р т и с т. Бу — сәхнә! Шартлылык! Символ! Идея! Аңлыйсыңмы, авыл бәрәңгесе?!

Я ш ь к е ш е. Сәхнә тормышны күрсәтергә тиеш. Сәхнә безнең корыч адымнарны, тирескә баткан аякларны, менә бу мускулларны күрсәтергә тиеш! Сәхнә ул — революция! Дин, мәхәббәт, имеш! Кем ул Такташ! Үзе кайсы якта?!

Каты бәхәс башлана. Шул вакыт сәхнәгә атылып Яшь шагыйрь килеп керә. Кулында журнал.

Я ш ь ш а г ы й р ь. Бетергәннәр! Харап иткәннәр! Суйганнар!!!

Я ш ь л ә р. Кемне?

Я ш ь ш а г ы й р ь. Такташны үтергәннәр... *(Башын тотып утыра.)*

Халык телсез кала.

Я ш ь а р т и с т *(әкрен генә аның янына килә)*. Син нәрсә... Бутыйсыңмы әллә? Әле бүген генә күргән идем бит, исән иде.

Я ш ь ш а г ы й р ь *(журналны суза)*. Менә... *(Яшь артист журналны ала. Укый. Эчен тотып көлә башлый.)*

Я ш ь а р т и с т. Ха-ха-ха! Бетергәннәр Такташны! Суйганнар! Ну ярып та караганнар! Тел бар безнең татарда! Менә *(укый)*.

«Бер мишәр малае төшендә шагыйрь булганын күрде, ди. Күрде дә, ди, йокысыннан зерә дә кинәнеп уянды, ди». Ха-ха-ха! Тукта, «Җир уллары» турында да бар монда. *(Укый.)* «Халык та юк иде ди. Үзебез өчен генә уйнамыйк инде, дип, урамнан кем үтеп бара — шуны әйдәп, китереп,

тамаша иттерделәр, ди». Ха-ха-ха! Менә сиңа Такташ! «Чаян» абзаң үзе пешергән Такташны! *(Укый.)* «Шагыйрь дулап китеп, акны карадан аера алмый — барысын да адәм аңламый торган чеп-чи «алаша» теле белән эт итеп сүккән, ди». Һәм менә мәкаләнең ахыры. *(Укый.)*

Тик китә кай чакта кәефең,
Хакимең булса ишәк.
Бар татарга ят, мәхәббәтсез —
Күсәк һәм килмешәк...

Менә бу мәкалә ичмасам!

Ак Дус килеп, аның кулыннан журналны тартып ала.

Ак Дус. Ә син нәрсә үрле-кырлы сикерәсең? Әле генә Такташны мактап авыз суларыңны корыткан идең бит. Нәрсә бик тиз кайтып төштең?

Яшь артист. Мин нәрсә... Әнә язганнар бит. Кызык итеп язганнар...

Ак Дус. Кызык... Нәрсәсе кызык моның. Такташны халык алдында адәм мәсхәрәсе иткәннәр. Соң алар бит Такташның кисеп ташлаган тырнагына да тормыйлар!

Кара Дус *(янына килеп)*. Я, кызма. Бала-чага белән бала-чага булма. *(Журналга күрсәтеп.)* Моңа да исең китмәсен. Язган — беткән. Хәзер кемне язмыйлар? Барыбызга да эләгә. Кара, исемен дә тапканнар бит — «Шак-шак шагир булды». Ну, бу «Чаян»ны! Да, катырак әйткәннәр икән шул. *(Укый.)* «Казанга китте дә, ди, үзен бик шәп, эре сатты, ди. Казанда сәхнә әсәрләре язу модага кергән чак иде, ди. Ул да карт шагыйрьнең нәсыйхәт юллары буйлап бер «фаҗига» язган, ди. Ул нәрсәсен бик шәп, бик шәп дип сәхнәгә тәкъдим итте, ди. Талымсыз татар сәхнәсе алып уйнады, ди...»

Югарыдагы сүзләрне укыганда, Такташ кереп, ишек яңагына сөялеп тыңлап тора. Аны беркем дә күрми.

Такташ *(алга чыгып, бүлдереп)*. Ә Казан аны менә шушылай кабул итте, ди.

Яшьләр Такташны чорнап алалар.

Кара Дус *(җилкәсенә кулын салып)*. Вакланма, Такташ! Яза бирсеннәр! Хәзер шундый заман — ачыктан-ачык әйтү заманы. Яңаны төзибез бит, кәбәм! Яңа өчен янабыз.

Такташ. Мин янмыйммы?! Бөтен уйларымны, хистойгыларымны, җанымны кешеләргә өләшәм. Бөтен җылылыгымны аларга бирәм. Шул җан җылысыннан башка, минем бит бернием дә юк. Ә алар әнә миңа «килмешәк» дип кенә кычкыралар.

Ак Дус *(икенче ягына басып)*. Син, Такташ, алай артык гомумиләштермә инде. Нигә, кешеләр, дисең? Халыкның монда ни катнашы бар? Бер адәм кисәге язган шунда.

Яшь шагыйрь. Әйдәгез, егетләр, җыелып, шул мәкаләгә җавап язабыз! Протест язабыз! *(Кара Дуска.)* Дус! Чыгар үз гәзитеңдә шул язманы?

Кара Дус. Вакланмагыз, дип әйттем бит. Мәкалә түгел, шигырь язып җавап бирергә кирәк.

Ак Дус. Дөрес, дус! Әйдә, Такташ, укып җибәр әле өр-яңа бер шигыреңне!

Яшьләр. Укы, Такташ, укы!

Такташ *(елмаеп)*. Я, тыңлагыз алайса. Тик, катырак киткән урыннары булса, бигайбә! Йөрәкнең бик янган вакытында язылган шигырь...

Яшьләр. Исеме, исеме ничек?

Такташ. «Казан» дип атала. Драмадан бер монолог.

Чәчләрен артка чөеп, укый башлый.

Күзләремә ничек ачык итеп
Кайгы нуры төшкән.
Аларда
Үз-үземә нәфрәт хисе яна.
Оялам да,
Куркамын да хәзер карарга...
Ә кайчандыр алар көн килерен

Хәбәр иткән язгы таңдагы
Кояш нуры кебек якты иде.
Өметле иде;
Хәзер андагы
Ул сихерле нурлар сүнгәннәр.
Ә тагы
Алар шулай итеп янармы?
Казан!
Фахиш шәһәр,
Синең урамыңа
Мин, гыйсъянчы, кереп адаштым.
Череп беткән мещан баткагында
Иркен уйларымнан саташтым.
Казан!
Фахиш шәһәр,
Синең урамыңда
Җанга җылы юктан туңам мин,
Череп беткән мещан мунчасында
Көзге чәчәк кебек сулам мин.
Казан!
Шагыйрьләрең бардак җырлый синең,
Әдипләрең эчеп тилергән,
Нэпманнарың чуар дуңгыз кебек
Кеше каны эчеп симергән.
Казан!
Фахиш шәһәр!
Синең урамыңа
Көчле дуслар эзләп килдем мин...
Тик ялгыштым,
Синдә Дон-Кихотлар,
Милләтчеләр туе күрдем мин...
Киләчәктә юкса мине дәме
Шушы ваклык басар, күмәрме?
Күкрәгемдә янган җәһәннәмнәр
Шулай әкрен генә сүнәрме?
Әгәр алай булса,

Ул вакытта...
Үләргә?—
Ачу итеп тормыш чүпләренә
Үз-үземне җиргә күмәргә?—
А, юк!
Әгәр алай итсәм, алар өчен
Бик зур корбан булыр идем мин.
Шул тормышның астын өскә китереп
Җимерергә, тар-мар итәргә!!
Әйе,
Бу тормышны җимерер, ватар өчен
Алар килә,
Ишетәм:
Яшь көчләрнең
Аяк тавышлары ишетелә!

Бар да кул чабалар.

Кара Дус. Шәп! Молодец, Такташ! Ахыры бигрәк тә яхшы чыккан. Менә каләмеңне кай якка борырга кирәк сиңа! Яңалыкны җырла, яшь көчләрнең аяк тавышларын җырла! Ә башында... буталчык, кирәкмәс нәрсәләр күп.

Ак Дус. Ә миңа калса, башта—чын Такташ. Газап, эзләнү, көрәш. Ә ахырында пафос күп.

Кара Дус. Ә синең үзеңдә юкмы пафос? Кара инде:

Корыч тешләр белән
Тимер кырып,
чәчкә коям,—
Чәчкәләрдән һәйкәл ясап,
Анда кемне бастырам?
Сине...
аны...
моны...
сезне...

Юк!
«Барыгызны»
бергә
Эшче исемендә бастырам.

Ак Дус. Гениальный шигырь! Безгә пафос белән язсак та килешә. Ә менә Такташка — килешми. Ура! кычкыра башласа, ул ясалмага әйләнә.

Яшь кеше. Такташ, сиңа бер сорау бар иде.

Такташ. Әйт, яшь дус.

Яшь кеше. Нәрсәдән шушы хәтле риза түгел син?

Такташ. Аңламадым.

Яшь кеше. Аңламадыңмы? Менә без, совет яшьләре дә аңламыйбыз шул. Бөтен шигырьләреңдә нәләт, ризасызлык, газап, каргыш. Бәлки син революцияне кабул итмисеңдер?

Бар да гөжләп алалар. Кинәт тыналар.

Такташ. Ну, егет... Син әйтеп тә карыйсың. Мин революцияне, ач-ялангач килеш, «Марсельеза» җырлап, Бохара урамнарында каршыладым. Минем атам-анам Сыркыды авылының ярлы крестьяннары. Кайдан килсен миңа революцияне кабул итмәү? Җырларымнан башка дөньяда минем бер байлыгым да юк.

Яшь кеше. Алайса, нигә һаман карганасың? Нидән риза түгел син?

Такташ. Үз-үземнән. Бары тик үз-үземнән. Мин шигъриятта тар кысаларга гына сыймыйм. Күңелем белән күкләргә дә менеп китәм, сарайларга да барып керәм. Нәрсә эзләгәнемне үзем дә белмим. Җан дулый.

Кара Дус. Ә белергә кирәк, Такташ. Син эзләгәнне революция инде әзерләп бирде. Хәзер шул турыда җырларга кирәк.

Такташ. Менә шуның көен таба алмыйм шул...

Ак Дус. Революциягә көй кирәкмени? Революциягә ритм кирәк! Бәр, җимер, яңаны төз! Мылтыгың булсын

төз! Тра-та-та! Атака! Алга! Искелек — дошман! Үлеме булсын кылычтан!

Шул вакыт ишектән бер төркем кызлар килеп керә. Алар рабфак студенткалары. Алар арасында Беренче Гөлчәһрә дә бар. Ул үзенең чаялыгы белән барысыннан да аерылып тора.

Беренче Гөлчәһрә. Кем монда шулхәтле әтәчләнә? А, шагыйрьләр! Артистлар! Әйдәгез, кызлар, үтегез, тартынмагыз. Безнең татар шагыйрьләре бераз оялчан булалар, үзләре чакыра белмәсләр.

Ак Дус яннарына йөгереп килә. Гөлчәһрәгә нәзакәт белән кулын бирә.

Ак Дус. Ак шагыйрь.

Беренче Гөлчәһрә. Ә мин сезне беләм. Сез футурист бит. «Айга ут төртәм, җирне гөл итәм. Тра-та-та! Атака!» Ха-ха-ха! *(Сөйләшә-сөйләшә бер читкә китәләр.)*

Такташ *(Кара Дуска)*. Бу нинди пәри кызы?

Кара Дус. Бумы? Бу — рабфак студенткасы. Бик кәттә кыз. Җитмәгән җире юк. Русчасын, татарчасын, гарәпчәсен су кебек эчә. Казан каласын ду китереп яши.

Такташ. Адәм баласына... кайдан килгән шушы хәтле гүзәллек? Пәри затыннан түгелме икән ул?

Кара Дус. Кара, Такташ, ул Казанда күп кешенең башын әйләндерде инде. Сак бул, синең дә башыңа җитмәсен.

Такташ. Кайгырма, дус. Минем өчен ул — гүзәллек кенә. Шигъриятнең үзе кебек гүзәллек. Йа... булса да булыр икән шундый матурлык...

Беренче Гөлчәһрә. Кызлар, егетләр, әйдәгез, шигырь әйтешле уйныйбыз. Монда килеп, шагыйрьләрдән шигырь дә тыңламасаң! Менә сезнең номерлар. *(Өләшә.)* Безгә атап шигырьләрегезне әзерләгез.

Ак Дус. Минем әзер! Шигырь дә әзер, аны кемгә бирәсен дә беләм... *(Тиз-тиз шигырь яза башлый. Номерын күкрәгенә кадап куя.)*

Барысы да шигырь язып, шигырьләрен кызларга өләшәләр. Һәрберсенең күкрәгендә — үз номеры. Такташ кына берни язмый. Буш кәгазьне, кеше аша, Гөлчәһрәгә җибәрә. Гөлчәһрә кулында шигырьләр күп.

Беренче Гөлчәһрә. Я, егетләр, укыгыз!

Ак Дус.

Кердең дә —
Үтердең!
Кояш сүнде, ай тотылды,—
Беттем.
Кирәкми дөньясы —
А, гүзәл,—
Аяк астында Шагыйрь үзе!

(Тезләнә.)

Беренче Гөлчәһрә. Номерың миндә, чибәр егет!

Ак Дус. Йөрәгем дә!

Беренче Гөлчәһрә. Кояш, ай сүнгән, ул йөрәк ялгызы ни эшли алыр соң? Алай да, шигырь миңа ошады. Кабул итәм. Икенче номер?

Кара Дус. Минем номер. Ул — сезнең кулда.

Беренче Гөлчәһрә. Шигыреңне укы, шагыйрь!

Кара Дус.

Яңа заман корып барган чакта
Яңа заман кызы — син тудың.
Илебездә барган үзгәрешләр —
Синең җирдә янган символың!
Бир кулыңны, илнең ал таңы,
Ирекле мәхәббәт Ватаны!

Беренче Гөлчәһрә. Браво, шагыйрь! Солидно! Бераз буталчыграк, пафос зур, ләкин барыбер шәп! Кабул итәм. Өченче номер? Кем? Нигә ак кәгазь? Шагыйрьнең әллә кызлар күргәч язар сүзе онытылганмы?

Такташ. Онытылмаган, гүзәл. Ул шигырь бәгырьгә газаплар белән күптән уелган инде...

(Укый.)

Син уйныйсың. Ә мин шундый ардым;
Өзелеп-өзелеп тыным алам да
Карыйм сиңа: син бер хәят үзең
Уйнап йөргән илдә, яланда.
Толымнарың белән җилләр уйный,
Уңга-сулга ташлый туздырып,
Алар бәхетлеләр...
Соң мин, соң мин нигә,
Төннәр буе шунда утырып,
Кул сузарга куркам?!

(Такташ укыганда, Гөлчәһрә, сихерләнгәндәй, алга таба килә.)

Тарат, сеңлем, озын чәчләреңне!
Алар сузылып төшсен алдыңа,—
Шулай килешә сиңа. Су кызыдай
Кил дә хәзер минем алдыма,
Төпсез күзләреңне айга текәп
Утыр; күлдә — шәүләң уйнасын,
Узган-барган кешеләр туктап карап,
«Су кызы» дип сине уйласын!
Аһ, Әминәм! Булмадың ник бер су кызы,
Иркенлектә уйнап йөрүче?
Ник булмадым мин бер урман углы
Синең дустың — яшь бер көтүче?
Кыймас иде безгә мәкер күзләр
Болай шөбһә белән карарга.

Беренче Гөлчәһрә *(битен каплап)*. Юк! Юк! Кабул итмим! Кабул итмим...

Такташ. Нигә, туташ, шигырь сезгә ошамадымыни?

Беренче Гөлчәһрә. Шигырегез яхшы. Ләкин ул миңа багышланган түгел! Сез аны ниндидер Әминәгә багышлагансыз. Ә миңа укырга батырчылык иттегез.

Такташ. Ниндидер Әминә... Гафу итегез, туташ, бер мизгелгә мин кинәт аны күргәндәй булдым. Әминәм, дип уйладым.

Гөлчәһрә. Мин Әминә түгел!

Такташ. Ә кем соң сез?

Гөлчәһрә. Мин — Гөлчәһрә Хәмзина!

Такташ. Ә мин — шагыйрь Һади Такташ.

Гөлчәһрә. Такташ?! Кызлар, ишеттегезме, үзе — Такташ, үзе миңа атап бер юл шигырь яза алмаган! Ха-ха-ха!

Такташ. Мин теләсә ничек шигырь яза алмыйм, туташ.

Гөлчәһрә. Теләсә ничек? Сез ишеттегезме? Ха-ха-ха! *(Кулындагы бөтен шигырьләрне аяк астына чәчә.)* Язарсың, шагыйрь! Менә болар кебек язарсың! Моны сиңа Гөлчәһрә Хәмзина әйтә. Ха-ха-ха! *(Чыгып китә.)*

Такташ. Җен кызы. Валлаһи, җен кызы! Адәм баласы мондый шашкын булмый... Бөтен зиһенемне чуалтты.

Кара Дус *(җилкәсенә кулын салып)*. Кара, башыңны әйләндермәсен, Такташ! Җүнле кызга охшамаган ул.

Ак Дус *(икенче яктан килеп, Такташның җилкәсенә кулын сала)*. Калдыр ул кызны, Такташ. Сиңа бөтенләй тиң түгел ул. Берегез — ут, берегез — су...

Такташ.

Пәри кызы! Ник чыктың да юлларыма,
Утлы кызыл гөлләр тотып кулларыңа,
Гөлләреңне ыргытып бер елмайдың да
Ник яшерендең, төренеп таң нурларына?

Их, дуслар! *(Аларны кочаклап ала.)* Яшисе килеп китте бит әле, яшисе!

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Такташның кунакханәдәге үз бүлмәсе. Такташ ялгыз.

Такташ. Ничек язарга? Нәрсә турында язарга? Күкрәгемдә — янар таулар ялкыны. Ләкин дөньяга минем бу ут-ялкыннарым кирәкми. Дөньяга таш-тимер турында җырлар кирәк. Мин алар теләгәнчә яза алмыйм! Газеталар минем хакта тәнкыйть мәкаләләре белән тулган. Һәр ши-

гырем штыклар белән каршы алына. Йөрәк каныма манчып язган «Җир уллары» бойкотка очрады. Бер фикерсез, кызыл, шома сүзләрдән генә торган шигырьләрне ура! кычкырып каршы алалар. Минем дә үзгәрүемне, башкалар кебек яза башлавымны көтәләр. Ә мин яза алмыйм! Яза алмыйм! *(Өстәленә каплана.)*

Бүлмәгә әкрен генә Беренче Гөлчәһрә керә. Арттан килеп, Такташның күзләрен куллары белән каплый.

Такташ *(баса)*. Кем син, йортыма рөхсәтсез килеп кергән юлаучы?

Гөлчәһрә дәшми.

Син кешеме, пәри затыннанмы? Нинди максат белән минем күзләремне каплдың? Бу дөньяны миннән мәңгегә каплавыңмы, пәри кызы?

Беренче Гөлчәһрә. Мин синнән шигырь алырга килдем, шагыйрь. *(Каршына утыра.)*

Такташ. Шигырь юк, пәри кызы. Күңелемдәге шигырь орлыкларын җил-давыллар туздырган...

Гөлчәһрә. Син бигрәк сәер кеше икәнсең, шагыйрь! Яңалары юк икән, искеләрен укы. Сине бит бүгенге көндә татарның иң яхшы шагыйре диләр.

Такташ. Шулай диләрмени? Безнең мәртәбәле газета-журналларыбыз шулай язмыйдыр бит?

Гөлчәһрә. Нигә миңа газета-журналлар фикере? Халык шулай сөйли, яшьләр, студентлар шулай әйтә.

Такташ. Менә бит, бер җылы сүздән дә күңелләр күтәрелеп китте бит әле. Бер карасаң, күп тә кирәкми адәм баласына. Нндирәк шигырь укыйм микән мин сезгә, Гөлчәһрә туташ?

Гөлчәһрә. Әлбәттә, мәхәббәт турында. Миңа чүкеч җыры кирәкми. Мәхәббәт булсын.

Такташ. Я, ярый алайса. Тыңлагыз.

Аһ, әгәр мин бер зур рәссам булсам,
Тәрсим итеп ул кыз баланы

Бүләк итәр идем сезгә,
Бүләк итәр идем мин аны.
Җир йөзенең бөек рәссамнары!
Килегез дә миңа сөйләгез!
Аның тузган чәчен буяганда
Нинди буяу белән буйыйм да,
Зәңгәр күзкәйләрен, җаным итеп,
Ничек кенә буяп куйыйм да,
Ничек тәрсим итим мин аны?!

Гөлчәһрә. Җитте, туктагыз! Сез һаман үткәннәрдә саташасыз, һаман эзләнәсез. Нәрсә эзлисез сез? Кемне?

Такташ. Белмим. Нәрсә эзләгәнемне, нәрсә көткәнемне белгән көннән, шагыйрь булудан туктар идем.

Гөлчәһрә. Кем ул — зәңгәр күзле чибәркәй? Нигә Сезнең шигырьләрдә мин юк?!

Такташ. Сез аның булырына ышанасызмы?

Гөлчәһрә. Ха-ха-ха! Әлбәттә! Чөнки мин — Гөлчәһрә Хәмзина. Пәри кызы, җен кызы, чегән кызы, мишәр кызы! Тик минем күзләрем зәңгәр түгел, яшел! Шигыреңдә бутый күрмә! Ха-ха-ха!

Ишектә Ак Дус күренә.

Ак Дус. Чегән кызы! Тавышың урамның теге башыннан ишетелә. Син нәрсә монда шагыйрьнең башын әйләндерәсең?

Гөлчәһрә. Әйләндерерсең аның башын! Син әле аны белмисең. Таш ул синең шагыйрең. Так-таш! Таш! Ха-ха-ха!

Такташ. Дөньяда ташларны эретерлек көч тә бар, Гөлчәһрә туташ! Во! Ту-таш! Таш! Таш. Ха-ха-ха! *(Көләләр.)*

Ак Дус. Кая, Такташ, синдә капкаларга һәрвакыт бирәр нәрсә була торган иде. Гөрләтеп бер чәй эчеп алыйк әле, булмаса?

Такташ. Ипи-чәй бар, егетләр. Кичә генә Заһидлардан 2 кадак чәй алып торган идем. Утыр, Гөлчәһрә туташ, фәкыйрь табынымның түрендә бул.

Ак Дус. Ә минем күңелемнең түрендә — Гөлчәһрә туташ!

Такташ. Кара син аны, Такташның чәен эчеп, ярын да кочмакчы.

Гөлчәһрә. Во! Ишеттегезме! Ярын, диде. Мин күңелемә салып куйдым, шагыйрь!

Такташ. Ай, канатларым! Ай, дусларым... Бер карaганда, менә күп тә кирәк түгел адәм баласына. Менә шундый көзге салкын кичтә куыш, бер кисәк ипи... Җылы караш.

Ак Дус. Нәрсә, янар таулар кирәкмимени инде хәзер, Такташ? Күкләргә дә менәсең килмиме?

Такташ. Күкләр ерак... А впрочем, нәрсә теләгәнемне мин үзем дә белмим әле. Йөрәк уйный, йөрәк ярсый. Анда давыл тынмаган әле, егетләр!

Гөлчәһрә. Син картайгач та шулай давыллы булырсыңмы икән, Такташ?

Такташ. Юк, Гөлчәһрә, мин картайгач тыныч кына, ягымлы гына бер карт булырмын. Тезем тулы оныкларым булыр. Бу авырлыклар, ачлы-туклы тормыш артта калыр... Дөньяның бәхеттән мөлдерәп торган чаклары булыр әле, егетләр!

Ак Дус. Күңелләр нечкәреп китте. Әйдә, үзебезнең бер мишәр көен сузыйк әле, Такташ дус.

Гөлчәһрә. Мин дә кушылам! Мин дә мишәр кызы бит!

Такташ моңлы тавыш белән «Аючылар» җырын башлый. Аңа башкалар да кушыла.

Аючылар, баручылар,
Кайтыгыз үз ил генәмә,
Үз илемә, үз җиремә,
Карыйм күзем туйганчы,
Елыйм яшем беткәнче...

Такташ. Бу — безнең Сыркыды көе...

Ак Дус. Бездә дә җырлыйлар аны.

Гөлчәһрә. Мин дә әтидән ишеттем. Көрәнле көе, дип җырлый иде.

Такташ. Халыкныкы инде алайса...

Ак Дус. Карагыз әле! Җырлаганнан соң, бер аяк та язып аласы килеп китте. Әйдәгез, киногa?! Америка турында шәп фильм бара икән.

Гөлчәһрә *(сөенеп)*. Әйе шул! Әйдәгез! Мин дә ишеткән идем. Керергә акча гына булмады.

Ак Дус. Акча ягы миндә дә бераз такыррак икән такырын. Карале, Такташ, син бу көннәрдә гәзиттән гонорар алдың бугай?

Такташ. Мә, дус! Ни бары — шушы. Бераз булса да, әниләргә җибәрдем. Калганын — мә, алыгыз. *(Акча бирә.)*

Ак Дус. Соң, үзең бармыйсыңмыни?

Такташ. «Чаян» өчен язасы мәкаләм бар. Өйгә алып кайтып эшләмәсәң, редакциядә генә бетми. Иртәгә өлгертәсе.

Гөлчәһрә. Нәрсә, алай да була! Бүгенге заманда бары тик Такташ кына шулай эшли ала.

Такташ. Ничек, Гөлчәһрә.?

Гөлчәһрә. Акча бирә-бирә, янына килгән кызны башка белән чыгарып җибәрә. Киттек, Ак Дус!

Ак Дус. Без киттек, Такташ! Яз мәкаләләреңне! Яз шигырьләреңне! Бүген кич янымда Гөлчәһрә туташ утырганда, миңа берни кирәкми!

Китәләр.

Такташ. Менә, дивана. Тәрәзәгә килеп кунган кошчыкны шулай очыр инде! Җыенып үзем дә барсам, нәрсә була иде инде? Черт белсен, әллә нинди арыганлык шунда. Вакыты-вакыты белән әллә нинди күңел төшенкелеге. Язам — язганым ярамый! Аннан яза алмас хәлгә киләм. Ә мин — шагыйрь! Мин язарга тиеш. Мин бит язганда гына яшим. Ни өчен мин кемнәргәдер ярaклашып яшәргә тиеш?! Ни өчен?!

Кара Дус керә.

Такташ. А, дус! Мине аңлый, акыллы киңәш бирә алырлык бердәнбер дус! Утыр! Өемнең түрендә бул.

Кара Дус. Төсең киткән, Такташ. Бик күп эшлисең ахры.

Такташ *(идәндәге кәгазьләрне күрсәтеп)*. Әнә! Аяк асты тулган. Аяк астында аунарлык кына шигырьләр туа хәзер миндә.

Кара Дус. Үзеңне алай төшермә, Такташ! Вакланма! Син — зур шагыйрь. Кара, шуны сорамакчы идем. Теге чикерткә моннан чыгып бара идеме әллә ул?

Такташ. Кемне әйтәсең?

Кара Дус. Рабфак Гөлчәһрәсе. Кара аны, Такташ. Бу тирәгә бик иянләндермә син аны. Күзләре урынында түгел аның.

Такташ. Юк инде, алай ук түгел инде. Ул артык кыю, чая кыз. Болай, күңеле яхшыга охшаган аның. Ну үткенлек бар инде. Ут!

Кара Дус. Безнең футурист шагыйрьгә чатябышкан. Култыклашканнар, сырышканнар, башны-башка терәгәннәр. Мине күрмичә дә үтеп киттеләр.

Такташ *(күңелсез генә)*. Салкын бит. Гөлчәһрәнең өстендә бик җиңел иде. Шуңа күрә безнең дуска сыенгандыр.

Кара Дус. Алай да, мин сине кисәтәм. Ялгыша күрмә. Үзеңне дә, иҗатыңны да харап итәрсең.

Такташ. Иҗат... Иҗат болай да кыл өстендә...

Кара Дус. Син нәрсә Гали Рәхимнәр сүзен сөйлисең? Алар әнә анда синең хакта күрәзәчелек итеп яталар, имеш, «атылган йолдыз булып, үз утында үзе янып югалмагае!» Туктале, кая әле журналы. *(«Безнең көн» журналын чыгара.)* Менә нәрсә ди бит, контр. Синең турында әйтә. Тыңла. *(Укый.)* «...Көчле каләм белән мәңгелекнең тимер ишекләрен ватырмын, ди торгач, ул үзе шул тимер ишекләргә бәрелеп, канатлары сынып, кире җиргә төшеп сүнмәгәе иде»,— ди. Кара, ничек оста карылдый. Тыңла, тагы нәрсә ди. *(Укый.)* «...Әмма бу көчнең татар әдәбияты

мәйданыннан югалуы чынлап та тәэсирле бер хәл булыр иде; чөнки бу яшь шагыйрьдә безнең татар шагыйрьләренең күбесендә булмаган бер ялкын белән бергә гаҗәп нәзек шигърият һәм әдәби зәвык булганы күзгә бәреләә». *(Журналны ташлый.)* Контр. Сине үзенең буржуазия сазлыгына сөйри бит. «Нечкә зәвык, гаҗәеп шигърият!» Хәзер ут, кан заманы! Тимер заманы! Яңаны төзибез. Нечкәреп торып булмый. Өзелеп китүебез бар.

Такташ. Синеке дә дөрес, дус. Аңарда да хаклык бар. Шигъриятте, иң беренче, хис кирәк. Ә впрочем, ике арада буталып калдым мин. Элеккечә дә язарга ярамый, яңалыкны да әле җаным, күңелем аша үткәрә алмыйм. Мин кабул итеп бетермәгән нәрсәләр күп. Туктап калдым.

Кара Дус. Туктап калма! Беренче эш итеп, менә шушы вак буржуа җырчыларына каршы җавап яз! Бетереп яз үзләрен. Сөйрәмәсеннәр сине мещан, баткагына. Үз газитемдә чыгарам, яз гына!

Такташ. Алай да ярамас. Революциянең теге ягыннан килгән тәнкыйтьчеләр әдәбиятны бик яхшы беләләр. Дөнья әдәбиятын! Алар арасында бик фикерлеләре дә бар. Безнең бит ни мәдрәсә, ни югары уку йорты. Аларга каршы чыгарга түгел, алардан өйрәнергә кирәк.

Кара Дус. Димәк, аларга каршы чыга алмыйсың, ә безгә каршы чыгасың? Тагы бер-ике менә шушындый төче мәкалә, син, билләһи, дип әйтәм, безгә каршы, Советка каршы кулыңа кылыч аласы кеше икәнсең.

Такташ. Син нәрсә?! Минем ничек язуым, эзләнүем, юл таба алмавым — минем шәхси эшем! Причем монда Совет власте? Соң мин сезнең барыгызга караганда да җаным белән партияле, коммунист. Ләкин иҗат белән син аны бутама!

Кара Дус. Илгә хәзер синең эзләнүләрең, җен-пәриләрең кирәкми! Илгә синең шагыйрь буларак юл ярып, әйдәп баруың кирәк. Ә син аңа просто әзерлексез икәнсең. Ничек ялгышканмын мин синең хакта.

Такташ. Соң, нишлим соң, дустым?! Нишлим!!!

Кара Дус. Яз, безгә, илгә нәрсә кирәк, шуны яз. Куеп тор хисләреңне, шашуларыңны. Андый шигырьләр заманы үтте инде. Яз менә шундый бер шигырь... синең коммунистлыгың, җаның шунда күренерлек булсын. Иртәгә әдәби кичәдә укырсың. Юк икән — бигайбә. Син безгә юлдаш түгел. *(Китә.)*

Такташ. *(Ялгызы)*. Язам! Язам мин андый шигырьне! Төне буе язам, йөрәгемне яндырып, шуның яктысында язам. Үткәннәрдән, зәңгәр күзле беркатлы яшьлегемнән соңгы шигыремне язам...

Сәхнә караңгылана.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мәдәният йорты. Биредә әдәбият кичәсе булачак. Зал хәзергә буш. Беренче Гөлчәһрә керә.

Беренче Гөлчәһрә. Кайда утырыйм икән? Артка барып, бөтенләй күрмәмешкә салышып утырсам? Күрмәмешкә салынсаң, күрмәс. Шул булыр. Бик исе китәр. Ә син бөтен кызлар алдында сүз бирдең, имеш, Такташны үземә каратам! Гөлчәһрә башың белән адәм көлкесенә калырсың аннары. *(Алга утә.)* Юк, алга утырам. Күзенә кереп утырам. Буталсын, саташсын, сүзен онытсын! Ялгышып, «Гөлчәһрә!» дип кушып җибәрсен. *(Көлә.)* Во була аннары! *(Сәхнәгә йөгереп менә дә, җырлый башлый.)*

Нигә?.. Нигә синең шаян күзләр
Күзләремә болай багалар?
Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
Керфек очларыңнан тамалар?!

(Биеп әйләнә.)

Залга Кара Дус керә дә, сокlануын яшерә алмыйча, Гөлчәһрәгә карап тора.

Кара Дус. Браво, Гөлчәһрә туташ! Инде мин шигырь тыңламаска да риза. Гүзәллегегез каршында тагы бер кат башымны иям. *(Килеп, кулын үбә.)*

Гөлчәһрә. А, җитди шагыйрь! Шигырь укырга килдеңме, тыңларгамы?

Кара Дус. Сез сер тота беләсезме, Гөлчәһрә туташ? *(Як-ягына каранып, уфтанып.)* Мин бүген берәүнең шигърияте белән мәңгегә хушлашырга килдем.

Гөлчәһрә. Сез... кемне күздә тотасыз?

Кара Дус. Кемне күздә тотканны бик яхшы беләсез, Гөлчәһрә туташ. Мин аны кызганам. Бетте шагыйрь. Язар сүзе бетте. Саерак булган, коры шапырыну булган икән ул.

Гөлчәһрә. Сез... аннан көнләшкәнгә шулай әйтәсез. Чөнки ул сезнең барыгызга караганда да талантлырак. Шуңа яратмыйсыз.

Кара Дус. Ә син яратасыңмы? Кызык өчен, үзеңә карату өчен генә йөрисең бит. Һәм дөрес эшлисең. Сиңа тиң түгел ул.

Гөлчәһрә. Ул — шагыйрь! Такташ!

Кара Дус. Ә син — дөньяның иң гүзәл кызы. *(Кулларыннан алып.)* Җүләр була күрмә, мавыгып китмә. Бу гүзәллекне аңлый аламы соң ул? Сыркыдының чабатачы Хәйрук улы! Гөлчәһрә! Мин сине яратам! Мин сине дөньяның алиһәсе итәчәкмен. Син матурлык өчен генә яратылган. Ач шагыйрь хатыны булу өчен түгел. Алда мине зур урыннар, дәрәҗә көтә... Гөлчәһрә...

Гөлчәһрә. Китегез, зинһар! Кешеләр килер вакыт җитте. Кемне уйлаганымны, нәрсә теләгәнемне мин үзем дә белмим. Тик хәзергә китегез миннән.

Кара Дус. Вәгъдә?!

Гөлчәһрә. Ашыктырмагыз. Мин бүген шигырь тыңларга килдем.

Кара Дус. Ха-ха-ха! Шигырь булмаячак! Шигырьгә пародия, елау, мескенләнү генә булачак.

Ашыгып Ак Дус керә.

Ак Дус. Такташ күренмиме әле? Халык арасында сүз таралган — Такташ яңа шигырен укыячак икән. Күптән язганы юк иде, ни әйтер икән Такташ?

Кара Дус. Тыңлап карарбыз.

Ак Дус. Гөлчәһрә, бәгърем, кил, утыр әле яныма! Такташны тыңлаудан да бигрәк, синең белән янәшә утырыр өчен килдем.

Гөлчәһрә. Ә мин Такташны тыңлар өчен килдем!

Ак Дус. Нинди чебен тешләде сине? Алайса, үзем янында барып утырам. Такташны бергәләп тыңларбыз.

Залга яшьләр белән бергә Такташ килеп керә. Ул агарынып киткән. Бер читкә барып баса.

Яшь шагыйрь. Утырыштыгызмы? Хәзер сүзне символист шагыйрь Һади Такташка бирәбез.

Такташ сәхнәгә менә.

Такташ. Хәзер мин сезгә символизм буенча язылмаган нәрсә укыйм. Аны школларга аеру минем эшем түгел, бәлки әдәбият тикшерүчеләр эше. Мин бары «Такташист» кына. Мин сезгә бүген төнлә язган соңгы шигыремне укыйм. *(Укый.)*

ТАКТАШ ҮЛДЕ

Көчле кояш күптән баткан инде,
Караңгылык баскан җир өстен,—
Ә ул һаман утын якмый, тик утыра.
Бәлки... кем белсен,
Аның көчле кулы бик күп еллар
Шулай эшли-эшли талгач та,
Күкрәгендә хәят нурларыннан
Соңгы нуры сүнеп калгач та,
Аның ирекле күңле тынар өчен
Караңгылык тели торгандыр?
Бәлки шулайдыр да,

Бәлки...
Өстәлендә аның бер хат тора —
Карт анасы язган;
Хатында
Шундый юллар:
...Хәләл сөтен имезеп, төннәр буе
Йокламыйча сине саклаган,
Авырганда үлем кочагына
Үзен атып, сине яклаган
Ул кем иде?
Соңгы сынык нанын сиңа биреп,
Ач калса да, «балам» диюче,
Бөтен дөнья синнән качканда да
Бер ялгызы калып сөюче
Ул кем иде?
Син ач килеш читтә йөргән чакта,
Синең өчен
Елый-елый күзсез калучы,
Синең бәхетең өчен җир өстендә
Тәмуг газаплары алучы
Ул кем иде?..
— Мескен әнкәң!
Ул әле дә өзелеп сагна сине,
Ә син?
Әткәң,
Ул әле дә шулай сөренә-сөренә,
Таяк тоткан килеш, урамда
Туктап ютәлли дә:
«Мин әле дә сезнең өчен
Салкын буранда
Һаман йөрим»,—ди ул.
Аның күләгәсе һаман йөри,
Һаман, һаман да...
Бер ул гына түгел,
Бире бик күп алар;
Ач, ялангач килеш яланда

Тик йөриләр
Тик йөриләр...
«Син кайт, балам!
Син кайт безнең янга,
Әүвәлгедәй сине сөярбез,
Балам, иркәм, бәгърем, диярбез!
Син кайт, балам!»
Төн үтә дә,
Иртәнге җил аңа җавап яза:
— Улың үлде.
Сагнып хатлар язма, бәхетсез карт,
Зәңгәр күзле улың исменә;
Ул юк инде...
Сагнып хатлар көтмә, изге «карчык»!
Көзге төндә
Тәрәзә төбендә,
Тәрәзәңне кагып:
— Аңардан! — дип,
Хат китермәс хәзер беркем дә...
Төштә күреп аны уянгач та,
Рәсмен кулыңа алып син аның,
Таң җилләре аша
Елый-елый
Көтмә инде аның сәламен!
Ул юк инде,
Ата!
Синең өчен
Ул юк инде...
Ана!
Синең өчен,
Сезнең өчен үлде мәңгегә...
Иске тормыш!
Синең кырларыңда
Зәңгәр күзле уйчан яшь егет —
Ул юк инде...
Иске тормыш!

Синең «гөл бакча»ңда,
Сөренә-сөренә ачтан интегеп,
Хәят эзләп йөргән уйчан егет —
Ул юк инде...
Гаиләң тар синең аның өчен,
Йортың — төрмә,
Ишекләре корыч-тимердән.
Балаларың — исерек,
Нәслең — черегән!
Барысы тилергән!
Нәфрәт итеп «синең гаиләңә»,
Барлык матурлык дип белгән
нәрсәңә,
Нәфрәт итеп сиңа!
Ул ант итә Казан урамында,
Ул ант итә мещан базында,
Ул ант итә сезнең арагызда,
Әй, сез, калдык нэпман уллары!
Базар корольләре!
Шарлатаннар!
Череп беткән сыра кортлары!
Сез табынган алтын-көмешләрне
Тәңре итеп үзенә алалмый;
Сез аунаган пычрак баткаклыкта
Үзе өчен урын табалмый;
Ишетәсезме!
Сезгә кабак дусты,
Җырчы малай булып калалмый!
Көрәшчеләр!
Сезнең арагызга яшь бер егет килә,
Аның да
Һичбер нәрсәсе юк:
Малы да:
Атасы да,
Анасы да,
Сөйгән яры да...

Яшьләр гөрләп кул чаба башлыйлар. Кайсылары сызгыра. Кем «Браво!», «Бис!» дип, кем «Долой!» дип кычкыра. «Чит идеология!», «Буржуазия исе килә!» дигән тавышлар да яңгырый. Такташ башын иеп басып тора. Ак Дус сәхнәгә атылып менеп, Такташны кочып ала.

Ак Дус. Чын шигырь бу, Такташ! Тик һичбер нәрсәсе юк дип дөрес әйтмәгәнсең. Без бар бит! Шулаймы, яшьләр?!

Астан гөжләп җавап бирәләр:

— Кая безнең өченче дустыбыз? Мен бирегә, котла Такташны! Син теләгән шигырьне язган!

Астан: «Китте ул!», «Китте» дигән тавышлар ишетелә. Яшьләр дә әкренләп таралып бетә. Сәхнәгә Беренче Гөлчәһрә күтәрелә.

Гөлчәһрә. Рәхмәт, Һади абый. Мин Сезне бүген үзем өчен өр-яңадан ачтым.

Такташ. Рәхмәт, сеңлем! Синең аңлавың минем өчен бик тә, бик тә мөһим. *(Кулларын ала.)*

Ак Дус. Такташ үлде. Такташ терелде! Димәк, яшибез! Их, йөрәк яна! Молодец, Такташ дус! Җиндең! *(Йөгереп чыгып китә.)*

Гөлчәһрә. Нәрсә булган аңа?

Такташ. Шагыйрь кеше бит... Бер яна, бер сүнә. Ә дөресрәге, сиңа гашыйк бугай ул, Гөлчәһрә.

Гөлчәһрә *(назланып)*. Миңа? Ә минем зәңгәр күзле уйчан егет белән сөйләшәсем килә. Минем аны терелтәсем килә. *(Йөгереп чыга башлый.)*

Такташ *(кулларыннан алып)*. Син терелттең инде аны, Гөлчәһрә! *(Йөгереп чыгып китәләр.)*

Әкрен генә «Урман кызы»ның мелодиясе яңгырый.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

«Урман кызы» мелодиясе дәвам итә. Такташ бүлмәсе. Такташ ялгыз.

Такташ. Нигә өченче көн инде иң якын дустым дәшми? Илгә яңача җырлаулар кирәк, диде, бөтенесен үзгәртергә өндәде. Төн утырып шигырь яздым. Аның фикерен көттем. Ә ул бер сүз әйтми чыгып китте. Димәк, ул минем шигыремне кабул итмәде. Әлбәттә. Үз юлыннан, үз кыйбласыннан чигенгән кешене, үз-үзен үтергән Такташны кем кабул итсен?! Кеше әйткән саен үзгәргән шагыйрьне... Башкалар әле сәхнәгә менеп котлаган була бит. Ничек оста уйныйлар... Ә ул — дәшми... Ник килми ул?

Ишектә Ак Дус күренә.

А, син...

Ак Дус. Ә син башканы көттеңме?

Такташ. Әйе, башканы көттем.

Ак Дус. Такташ! Бик җитди сүзем бар иде сиңа, дустым.

Такташ. Мәхәббәт турындадыр инде. Синең шуннан да «җитди» мажараң булмас.

Ак Дус. Бу юлы мажара гына түгел шул. Чын мәхәббәт. Калдыр син аны, Такташ! Мәхәббәт өчен син артык җитди, авыр кеше. Гөлчәһрә синең шагыйрьлегеңә генә кызыга.

Такташ. Син дә шагыйрь бит.

Ак Дус. Минем шигырьләрем хатын-кыз өчен түгел! Менә яңа тормыш, тимер чыңы, көрәш кыры...

Такташ. Менә шулар белән яшә инде алайса. Яңа тормышта нәрсәгә сиңа мәхәббәт?

Ак Дус. Такташ! Син акыллы, син талантлы, син даһи! Нигә барысы да бер кешегә?! Калдыр миңа Гөлчәһрәне? Валлаһи, яратам бит мин ул җен кызын!

Такташ. Соң син миңа ничә тапкыр шулай кереп, ничә тапкыр мәхәббәтең турында сөйләдең бит! Бер айга да бармый бит ул синең яратуларың!

Ак Дус. Юк! Бу юлы — мәңгелек! Ул бит җен! Ул бит сихерче! Шуның яшел күзләре йокларга да, язарга да ирек бирми. Яшәргә ирек бирми! Сиңа нәрсәгә ул кыз, я?! Ул бит синең идеалың түгел.

Такташ. Белмим... Кем икәнен белмим... Мин синең кебек башымны югалтмадым, дус. Ләкин ул кыз янымда булганда, дөнья яктырак тоела миңа. Караңгылык чигенә. Просто рәхәт. Яшисе килә.

Ак Дус. Димәк, син серьезно?

Такташ *(көлеп)*. Белмим, дидем бит. Мин ул турыда уйламыйм әле. Башка нәрсәгә эчем поша.

Ак Дус. Дусның эндәшмәвенәме?

Такташ. Әйе. Ә син кайдан беләсең?

Ак Дус. Соң, ул миңа да эндәшми. Теге шигырь кичәсеннән соң кисәк кенә шулай булды.

Такташ. Димәк, ул минем шигырьне кабул итмәгән! Минем яну, өзгәләнүләремне аңламаган! Димәк, ул шигырьдә берни дә юк!

Ак Дус. Юк, Такташ, ашыкма. Шигырең бик җитди. Аның ни дәрәҗәдә җитдилеген әле бүген генә аңлап та бетереп булмыйдыр. Барыбыз да яшьләр, янабыз, эзләнәбез, язабыз... Синең бу шигыреңдә кемгәдер рәнҗеш тә, газап та, көрәш тә бар. Әллә нәрсәләр бар. Минем баш кына җитми.

Такташ. Ә нигә ул дәшми соң?! Нигә? Ул бит акыллы, җитди кеше. Миңа аның фикере бик кирәк. Аңлыйсыңмы, дустым, синең түгел, аның фикере кирәк!!

Ашыгып, Гөлчәһрә керә, кулында газета.

А, таң кызы! Син миңа иң авыр вакытларда күренә башладың әле.

Беренче Гөлчәһрә. Мин сезгә күңелсез хәбәр алып килдем. Ул Сезне саткан.

Ак Дус. Кем саткан?

Гөлчәһрә. Син түгел, шагыйрь. Сатлык җан булу өчен син артык гади, уенчак кеше. Менә аның иң якын дусты — ул — җитди шагыйрь саткан.

Т а к т а ш. Ул?! Син нәрсә бутыйсың, җен кызы? Нинди гайбәт белән килдең йортыма?!

Г ө л ч ә һ р ә. Гайбәт?! Мә, укы алайса. *(Газетаны бирә.)*

Т а к т а ш *(укый)*. «Такташизм». «30 ноябрьдә әдәбият түгәрәгенең нәүбәттәге җыелышы булып, берничә кулъязма укылды. Тыңларга килүчеләр гадәттәгечә күп иде. Кичәне бик шома үтте дияргә ярый. Тик «Такташ үлде» исемле черек идеологияле шигырь генә һәрбер коммунистның, комсомолец иптәшләрнең күзенә бәрелде». *(Мәкаләнең ахырын карап.)* Ул! Ул!!! Ул шулай язган! *(Газетаны ташлап, битен каплап утыра.)*

А к Д у с. Менә ни өчен дәшми йөргән икән ул?! Очраганда да башын иеп, читкә карап китә иде бит. Нинди пычрак мөһер суккан! «Черек идеология»... Куркыныч фикер бу... Моның шаукымы әле күп елларга барачак.

Т а к т а ш *(башын күтәрми генә)*. Укып бетер.

А к Д у с *(газетаны алып)*. Монда Гайса турында фәлсәфә саткан. Ә, менә... *(Укый.)* «...дини әкиятләргә ияртелеп язган әсәргә бәлки тукталырга да кирәкми торгандыр. Нindидер мещаннар мохитендә үскән, соңыннан зәңгәр күзле яшьлек чакларын сагынган тәти җегетнең («Такташист»ның) 17—21 нче елларда йоклаганы, советлар тәмам ныгыгач кына «нәләт нигъмәтләргә» дигән сүзләргә кагылмыйча мөмкин түгел. Гражданнар сугышының кызу вакытларында психологический үлгәнсең икән — бик яхшы. Күреп карыйк, яңа тормышта нинди яңалыклар күрсәтерсең икән!» Укый алмыйм! Барып бугазыннан аласым килә!

Г ө л ч ә һ р ә. Егетләр, нәрсә була инде бу? Соң ул Такташның иң якын дусты иде түгелме соң? Такташ, нигә эндәшмисең?

Т а к т а ш. Нәрсә әйтим, канәтым. Башка күсәк белән орган кебек булды.

А к Д у с. Аркага пычак чәнечкән кебек, диген.

Г ө л ч ә һ р ә *(газетаны карап)*. О, монда бетмәгән бит әле! Иң кәттәләре монда калган әле. *(Укый.)* «...«Такташ

үлде» шигыре кулак, мулла һәм башка шул ук типтагы икътисади төркемнәрнең җегетләрендә, кызларында булган филантропияле настроение күрсәтә». Оһо! *(Укый.)* «Эшче-крестьян массасы революцияне турыдан-туры үзе ясый. Давыллардан соң урынлашкан вакытлы тынлык вакытында Октябрь корабының койрыгына ябышкан иярчен мосафирлар үлеп терелгәч тә җитәкчелек эшен кулларына ала алмыйлар. Шуңа күрә 23 нче ел җиткәч кенә «мин — иске тормыш өчен үлдем. Яңасы өчен терелдем. Көрәшчеләр, арагызга зәңгәр күзле тәти җегет килә!» дию белән «Такташизм» (!) мәсләгенең чынлап та дөрест идеологияле икәнлегенә ышандыруы читен». Бетте. Бетергән.

Такташ. Нигә андый фикергә килгән ул? Мине иң дөрес аңлый торган кеше шул иде бит...

Гөлчәһрә. Иң дөрес аңлый торган? Син ялгышасың, Такташ. Аның синең турында фикере бик үк яхшыдан түгел иде.

Такташ. Син нәрсә беләсең, Гөлчәһрә?! Бу, гомумән, син аңлый торган нәрсәләр түгел.

Гөлчәһрә. Мин аңламый торганмы?! Соң шул кичә алдыннан гына ул миңа әйтеп торды, «Такташ бетте, башка яза алмаячак», дип. Миңа үзенең мәхәббәтен аңлатты!

Такташ. Мәхәббәтен?! *(Уйланып тора да шаркылдап көлә башлый.)* Ха-ха-ха! Ха-ха-ха! Аңладым. Наконец-то, аңладым. Соң ул боларның барысын да көнләшүдән язган. Мине Гөлчәһрәдән көнләп язган! Ә мин, җүләр, әллә нәрсәләр уйлап бетердем.

Ак Дус. Мин дә сине Гөлчәһрәдән көнлим. Ярты сәгать элек кенә мин дә сиңа Гөлчәһрәне яратуымны әйттем. Ләкин менә болай итеп газета битен пычратырга... Сине пычратырга! Юк, бутама, Такташ!

Такташ. Нәрсә, бутама? Син гашыйк булсаң соң? Син атна саен гашыйк буласың. Аның, гомумән, хатын-кызга тел катып сүз әйткәне юк. Гөлчәһрәгә гашыйк булган... һәм менә нәтиҗәсе.

Гөлчәһрә. Ай-һай җиңел хәл итәсең, шагыйрь! Әллә аның миңа гашыйк булуына сөенәсең дә инде?

Такташ. Мин әдәбиятта, шигърияттә ир-ат дуслыгы арасына хатын-кыз килеп керүне, гомумән, өнәп бетермим. Күп зыян туарга мөмкин аннан. Менә бүгенге факт та шуны сөйли.

Гөлчәһрә. Такташ! Син миннән күпкә өлкән. Ләкин хәзер син нәкъ балаларча фикер йөртәсең. Ул синең шагыйрьлегеңнән көнләшә, талантыңнан көнләшә! Бөтен тормышыңнан көнләшә. Кара көнләшү белән көнләшә. Мин хатын-кыз булып шуны сизенәм, нигә син кирәкмәгәндә шулай киң күңелле соң?! Син бит сукырларча фикер йөртәсең!!

Такташ. Гөлчәһрә! Булды! Син ике шагыйрь арасына кермә. Син миңа бик якын, беләсеңме, әлегә үзем дә аңлата алмыйм, бик, бик якын... Ләкин... кысылма син бу мәсьәләләргә. Аның турында миңа башка начар фикер әйтәсе булма. *(Ак Дуска.)* Бу сиңа да кагыла.

Гөлчәһрә. Аһ, шулаймыни? *(Ак Дуска.)* Киттек, Ак Дус! Аның өчен дөньяда шигърияттән, шигъри дуслыктан башка берни юк. Киттек!

Ак Дус. Мин Такташны бу хәлендә калдырып китә алмыйм. Мин сине аларның барысына караганда да күбрәк яратам, ләкин синең белән китә алмыйм.

Гөлчәһрә. Ха-ха-ха! Шигъри дуслык! Ярар, карарбыз, күпмегә барыр ул дуслыгыгыз. Бер-берегезне терелә ашап бетерәчәксез бит сез!!! *(Ишеккә бара. Аннан Кара Дус килеп керә.)* А... килдеңме, шагыйрь? Мине эзләп килдеңме?

Кара Дус. Коридордан үтеп барганда, тавышыңны ишеттем. Егетләрнең дә хәлен белеп чыгыйм, дидем. Саулармысез, егетләр? *(Кулын бирә. Такташ исәнләшә. Ак Дус читкә барып баса.)* Алай икән... Я, ярый, исәнлегегезне белдем. Киттек, Гөлчәһрә! Урамда беренче кар ява анда. Казан каласын «барабыз»да бер әйләнербез! Рәт бар. Киттек!

Гөлчәһрә. Киттек, шагыйрь! Төн безнеке! Тик башың әйләнмәсен! Атыңнан төшеп кала күрмә! *(Йөгереп чыгып китәләр.)*

Ак Дус. Гөлчәһрә! *(Артыннан бара. Аннан йөгереп тәрәзәгә килә.)* Киттеләр. Әнә атны туктаттылар. Гөлчәһрә аның кочагына ауды... *(Йөзен каплап, читкә борыла. Такташка.)* Сине сатып алган гонорарына, әнә, Гөлчәһрәне шәһәр әйләндерә.

Такташ. Дус, калдыр әле син мине бүген. Ансыз да йөрәгем яна. Калдыр әле... Шигырьләрем көтә.

Ак Дус. Их, син! Ярыңны тартып алалар — шигырь дисең! Дусларың ташлап чыгып китә — шигырь дисең! Дөнья шигырь белән генә бармый бит, тиле даһи! *(Чыгып китә.)*

Такташ *(ялгыз)*. Нишлим соң?! Минем өчен дөнья шигырь белән генә бара. Шигырь белән генә...

Такташ кәгазьләрен туздырып, шигырь язарга утыра. Аның бөтен тирәюне гөж килеп яши — бишләр, кочалар, бүлмә буйлап шайтан-фәрештәләр йөри. Күк читендә ялкын телләре сикерешә. Шагыйрь һаман яза. Шул мәхшәрнең һәммәсе арасында Шагыйрь берүзе яза! Таң алдыннан бар да тынычлана. Артта ак карлар яуганы күренә. Шагыйрь, башын өстәлгә куеп, йокыга китә. Ишектән әкрен генә Беренче Гөлчәһрә керә. Такташ янына килеп, алдына тезләнә.

Такташ *(уянып)*. Таң кызы!.. Ә мин синең киләсеңне белдем. Син миңа шулай таң алдыннан килергә тиеш идең... Таң кызым минем, җен кызым... *(Иркәли.)*

Кинәт тәрәзәләр ачылып китә дә, салкын җил кереп, Такташның бөтен кәгазьләрен туздырып ташлый. Гөлчәһрә куркып Такташка сыена. Шул давыл, җил өермәсе уртасында икәү басып торалар. Бөтен җирдә кәгазь — Такташ шигырьләре оча.

Такташ. Бу әле давылның башы гына, Гөлчәһрә... Башы гына...

Гөлчәһрә. Сынмабызмы соң, Һади?

Такташ. Сынмаска кирәк, канәтем. Хәзер без икәү бит.

Сәхнә бераз караңгыланып ала. Музыка.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Такташ белән Гөлчәһрә нәкъ шул кыяфәттә басып торалар. Бүлмәдә үзгәреш — бала караваты. Кыш. 1926 ел.

Такташ. Арыдыңмы, Гөлчәһрәм?

Беренче Гөлчәһрә. Салкын булды, ахры... Бала төне буе йокламады.

Такташ. Азрак ягабыз шул. Бүген үк утын юнәтергә кирәк. Күбрәк яга башла.

Гөлчәһрә. Юк! Юк! Кыш көне утын табып булмас. Монысын чаклап кына тотарбыз.

Такташ. Күкрәк иммәгәнгә дә борчыладыр инде ул?

Гөлчәһрә. Шулай килеп чыкты бит инде. Ярар, ныграк булып үсәр. Атасына охшаса, нык булыр.

Такташ. Анасына охшаса, тагы да ныграк булыр. Пәри малае кебек булыр.

Гөлчәһрә. Кит инде, бала өстенә әллә ниләр әйтмә. Нишләп пәри малае булсын ул минем улым?! Иеме, улым?

Такташ *(арттан килеп)*. Ие, әни, ие...

Көлешәләр.
Ишек ачылып китә. Төргәк тотып Ак Дус керә.

Ак Дус. Болар һаман көлешәләр! Ну, егетләр, көнләшәм үзегездән. Көнләшсәм дә, аяк барыбер шушында тарта.

Такташ. Өйләнергә кирәк, дус, өйләнергә кирәк. Өйләнгәч, аяк өй ягына таба тарта башлый.

Ак Дус. Безгә дигән кызларга берәм-берәм өйләнеп бетерәсез дә... *(Төргәгеннән букет чыгара.)* Менә, малайны котлап.

Гөлчәһрә. Ай, нинди матур! Ай, бәби тапкач, беренче чәчәкләрем!

Такташ *(уңайсызланып)*. Такыррак чак туры килде шул.

Ак Дус. Өр-яңа пиджагымны закладка салдым. Гөлчәһрә, синең өчен йөрәгемне дә закладка салырга да риза.

Гөлчәһрә. Син һаман шул тел бистәсе икән әле. Такташны көнләштерерсең. *(Чыга.)*

Ак Дус. Юк, миннән көнләшми ул. Минем уйларымның ак икәнен белә бит ул. Мин үзем синнән көнләшәм, Такташ! Валлаһи, көнләшәм. Гөлчәһрәгә өйләндең, инде малай атасы булдың. Казанга килеп, дүрт ел эчендә бит.

Такташ. Син әле монда кайбер нәрсәләрне төшереп калдырдың, дус. Дүрт ел эчендә миңа Казанда нинди исемнәр тактылар? — «Такташ — сәяси белемсез, Такташ — чит элемент. Такташ — вак буржуа шагыйре». Менә шулардан арына алмыйм мин хәзер. Нәрсә генә язып карасам да, шул мөһерне сугалар. «Мин контр түгел, халык улы», дип манара башына менеп кычкырсам да ышанмаячаклар.

Ак Дус. Син үзеңне тәнкыйтьләргә яратасың, Такташ! Әйт, татарда «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын кем язды? Син! Татар шигъриятендә беренче булып Ленинга һәйкәл куйдың. Ә «Сыркыды авылы»?

Комсомоллар — яшь ленинчылар алар,
Комсомоллар — искелеккә
Бомбалар!

Гөлчәһрә *(теге яктан)*. Чү, баланы уятасыз! Ике шагыйрь очрашты. Хыялланалар хәзер.

Такташ. Беләсеңме, дус, ул тема да бераз ялыктыра башлады мине. Минем өчен шигърият ул — хис, кеше күңеле, аның табыш һәм югалтулары. Хәзер мин, домна миче кебек, металл бирәм! Кешегә ияреп, Ура! кычкырам. Сәүдәгәрләрне пыр китереп сүгәм. Комсомолларны мактыйм. Кыскасы, гәҗит материалы. Арыдым.

Ак Дус. Ул «Авыл яшьләре» журналы да бик бетерә ахры сине. Җыен агрономический мәкаләләрне, хайваннар карау турында син язып ятасың бит.

Такташ. Башыңа төшсә, язарсың, туган. Синең эш рәхәт, койрыгыңны сыртка салып, укып кына йөрисең. Студент!

Ак Дус. Аның каравы синең кебек гаилә рәхәте күрмим. Кара инде син бу куышны! Күгәрчен оясы бит. Ә вообще то, сиңа да бераз укып алырга кирәк, Такташ.

Такташ. Мин теләгәндә булмады. Ташкенттан Мәскәүдә уку теләге белән килгән идем бит мин. Булмады. Шагыйрьлек басты. Аннан менә — тормыш. Хатын. Бала. Кая уку? Эшләп тә җиткереп булмый. Әле менә ничә ай фатир өчен түләнмәгән. Гөлчәһрәнең өс-башын карарга кирәк. Хатын-кыз бит. Аның менә бу юеш танавына да кирәк була башлар... Юк инде, брат, шигырь генә язарбыз инде.

Ишектә Кара Дус күренә.

Ак Дус. О, менә тагын бер семьянин. Тукта, син нишләп ялгыз әле? Хатының кайда?

Кара Дус. Хәзерге хатын-кызны аз беләсең син, дустым. Ул хәзер җәмәгать эшлеклесе. Әллә нинди җыелышларга чаба, чыгыш ясый, укый, яза... Дөрес әйтәмме, Такташ?

Такташ. Нәкъ шул, канәтем! Нәкъ. Әле менә безнең Гөлчәһрә дә...

Гөлчәһрә *(кулына таба белән бәрәңге тоткан)*. Тагы Гөлчәһрәнең гайбәтен сатасыңмы? Кара син аларны! Әз генә борылсаң, хатын яманлый башлыйсыз.

Кара Дус. Гөлчәһрә ханым! Соң сез рәхәтләнеп яманларга ирек бирәсезмени? Телгә алуга, каршыга килеп чыгасыз бит сез. Менә, улыгыз белән тәбрик итәбез үзегезне. *(Материал бирә.)* Хатын белән бер сәгать сайладык.

Гөлчәһрә *(материалын өстенә куеп карый)*. Ай, җәйгә күлмәк тектерәм! Бөтен Казанда иң модный булачак! *(Кара Дусны үбеп ала.)* Рәхмәт, дустым, җәйгә күлмәкле иттең. Халат белән җәй чыгармын, дип куркып тора идем.

Такташ *(сүрән генә)*. Рәхмәт, дус. Безнең такыррак вакыт шул...

Гөлчәһрә. Әйдә, утырыгыз әле. Бәби чәе эчәбез. Никахсызларның беренче мәҗлесе. Кыздырган бәрәңге!

Табын янына утырышалар.

Ак Дус. Ай, Гөлчәһрә, кулларың алтын икән! Мондый бәрәңгене гомер ашаганым юк иде.

Кара Дус. Шәп, шәп, тәмле. Молодец, Гөлчәһрә. Бу бәрәңгене ашагач, Такташ тагын да дәртләнеп яза башлый инде.

Такташ. Язам, егетләр! Менә малай тугач, бер шигырь язып ташладым әле. Үземнең бала чак, шук чаклар искә төште! Халык ничек кабул итәр тагын.

Ак Дус. Такташ, укып җибәр әле шул шигыреңне! Күптән синең шигырь укыганны тыңлаган юк.

Гөлчәһрә. Аңа әйт кенә! Көне буе укырга әзер. Только бик мавыгып китмә, баланы уятырсың.

Такташ. Уянсын! Их, егетләр! Аңламыйсыз әти кешенең хәлләрен!

Гөлчәһрә. Я, укы инде! Мактану тәмам. Әйтерсең, ул тапкан малай.

Такташ. Шулай. «Нәни разбойник». *(Укый.)*

Ак Дус. Менә бит, язарга тема таба алмыйм дисең. Әнә бу юеш танау да сиңа язарга күпме илһам биргән! Әле бу башы гына бит.

Кара Дус. Алай да, бу муллалар, ата казлар белән бик кайнашмаска иде сиңа. Пролетариат әдәбияты өчен вак нәрсәләр алар. Син менә бүгенге яңа тормыш турында җырла.

Такташ *(тирә-ягына күрсәтеп)*. Бүгенге яңа тормыш минем өчен хәзергә менә шушы. Калганын сез язарсыз инде, дуслар. Сез дә шагыйрь бит.

Ак Дус. Әйе шул. Син беркайчан да безгә тегеләй яз, болай яз дип акыл сатмыйсың. Ни өчен һаман без сине өйрәтергә тиеш әле!

Такташ. Киңәш бирергә мөмкин инде анысы. Тем более, берегез — студент, икенчегез — зур урында. Ә мин

кем — сәяси белемсез бер шагыйрь. Октябрь корабының койрыгына ябышкан.

Кара Дус. Я, Такташ, егет чактагыларны искә алып утырма. Мин дөрест әйтәм сиңа. Күңелемдә тырнак очы хәтле дә кер юк.

Такташ. Ышанам. Кемгә-кемгә, сиңа ышанам мин, дус.

Кара Дус. Авыр заманда яшибез, Такташ. Сиңа теш кайраучылар да күп. 24 нче елгы әдәби судны хәтерлисеңме? Ничек сиңа каршы күтәрелеп чыктылар? Әдәбиятка якын җибәрмәскә, шигырьләреңне бер җирдә дә бастырмаска иде бит исәпләре. Шул вакытта сине кем яклады?

Такташ *(күңелсез генә)*. Рәхмәт инде, дус.

Кара Дус. Әллә хәзер хәл бик җиңел дип беләсеңме? Бөтен газетлар сиңа тәнкыйть белән тулган бит.

Ак Дус. Соң, дус, синдә хәзер власть зур, ул тәнкыйть мәкаләләрен чыгартмый торган итеп эшлә син.

Кара Дус. Такташ — беспартийный. Аның иҗаты аеруча күзәтү астында. Аны яклыйм дип, мин болай да үз өстемә күп нәрсә алам.

Такташ. Рәхмәт инде, дус.

Гөлчәһрә. Я, ярар, хәзер әнә бик шигырь язып утыра алмас. Шигырь язмагач, тәнкыйте дә булмас.

Ак Дус. Нәрсә, Гөлчәһрә, Такташны үзеңә нянка итеп алмакчы буласыңмы әллә?

Гөлчәһрә. Үз баласы бит, шулаймы, Ади? Берничә елга гына түзәр.

Такташ. Гөлчәһрә, син тагы шул турыда... Мин бу эшкә риза түгел, дип әйттем бит инде. Ничу аны монда кузгатырга.

Гөлчәһрә. Юк, юк, кузгатабыз да, киңәшәбез дә менә. Дусларың ни әйтер?

Кара Дус. Эш нәрсәдә?

Ак Дус. Нәрсә бүлешә алмыйсыз тагы?

Гөлчәһрә. Мин укуымны Мәскәү рабфагында дәвам итәргә уйладым. Аннан — шунда ук университет, юридик факультет.

Ак Дус *(сызгырып җибәрә)*. Менә сиңа мә!.. Ә бала? Ә Такташ?

Гөлчәһрә. Син бигрәк кадимичә фикер йөртәсең. Соң, бала дип, ир дип укуымны ташлый алмыйм бит инде мин. Сез шигырьләрегездә дан җырлаган яңа тормыш менә шушы була инде ул.

Кара Дус. Монда мәсьәлә бик җитди. Бөтен ягын да уйларга кирәк. Беренчедән, балаң бик яшь...

Гөлчәһрә *(аны бүлдереп)*. Әниләр Казанга килде. Алар карап тора ала. Сыркыдыга кайтарып куярга мөмкин. В конце концов, мин аны үзем белән Мәскәүгә дә ала алам! Детдомга биреп торырмын.

Такташ. Гөлчәһрә! Ай-яй... син үзең бала шул әле. Ай җиңел карыйсың... Соң, бала бит ул. Йодрык хәтле беспомощный бер җан. Кая куясың аны?

Ак Дус. Гөлчәһрә, минемчә, син ашыгасың. Яңа тормыш ул шигырьләрдә җырларга гына матур. Ә монда тере җан иясе.

Гөлчәһрә *(кызып)*. Сиңа гаиләле кешеләргә киңәш бирергә иртәрәк әле. Синең башыңда җил уйный, атна саен гашыйк буласың... Киңәш биреп утырган була тагы...

Такташ. Гөлчәһрә! Бу мәсьәләне үзебез генә хәл итәрбез, ярыймы, аппагым? Сиңа борчылырга ярамый, өзлегерсең.

Гөлчәһрә. Миңа бер атнадан китәргә кирәк. Кышкы каникуллар бетә. Укулар башлана. Соңга калырга ярамый.

Такташ. Бер тиен акча юк...

Гөлчәһрә. Киемнәрне сатармын! Менә шул бер тиен булмаганга укыйм да инде мин. Киләчәктә шушы хәерче тормышта яшәмәс өчен!

Такташ. Гөлчәһрә!

Кара Дус. Карале, Такташ, баласын карарга кеше дә булгач, әллә укуын дәвам итсенме соң? Илгә укымышлы хатын-кызлар кирәк бит, үзең беләсең.

Такташ. Ә нигә ул минем хатын хисабына булырга тиеш? Минем баланың анасы хисабына?

Г ө л ч ә һ р ә. Сине вак буржуа дип белеп сүгәләр икән. Кара син аны — «минем хатын!» Бала анасы! Ә социализмны кем төзер?!

Теге якта бала елый башлый.

Т а к т а ш. Их! Әйтер идем инде... Бар, әнә, социализмың җылап ята.

Гөлчәһрә чыга.

К а р а Д у с. Бик борчылма, Такташ. Әнә, минеке дә укыган бит. Беләсеңме, яшәргә җайлырак, дус. Любой нәрсәне аның белән киңәшәм. Бөтен законнарны белә.

Т а к т а ш. Сезнең бала юк...

К а р а Д у с. Ничего, балагызга да берни булмас. Үзең багарсың, ул кайтыр... Борчылма.

А к Д у с. Ә мин барыбер җибәрмәс идем! Бәйләп куяр идем! Бикләп куяр идем. Янымда гына утыртыр идем. Их, Такташ... *(Чыгып китә.)*

К а р а Д у с. Син аңа игътибар итмә. Гөлчәһрәгә һаман гашыйк бит ул. Шуңа өйләнми дә. Нишләтәсең инде, тилене чәчеп үстермиләр бит. Я, ярый, мин дә кузгалыйм әле. Карчык көтә торгандыр.

Т а к т а ш. Парлашып килегез, дус. Гөлчәһрә киткәнче, тагы килеп чыгыгыз. Бәлки калырга үгетли алырсыз?

К а р а Д у с. Ярый, кагылырбыз әле. *(Китә.)*

Т а к т а ш *(ялгыз)*. Нәрсә инде бу? Яши генә башладык — инде җимерелүеме? Нигә кешеләрнең кеше кебек тә, минем генә барысы да шулай катлаулы соң? Шигърияттә бөтен йөрәгемне биреп яздым — кычкырып көлделәр, мыскыл иттеләр. Бөтен җаным белән гашыйк булып, тиңсез башымны пәри кызының аяк астына салдым — атлап чыгып китәргә җыена? Әллә мин үзем артык катлаулы яшимме соң? Кеше кебек барысына да төкереп, бер көнлек рәхәт өчен генә яшисеме әллә? Я план, расчет белән генә? Нәрсә сөйлим мин? Бөтенләй саташтыра мине бу Гөлчәһрә!

Гөлчәһрә чыга.

Гөлчәһрә. Чак йокыга китте. Сөт тә бетеп бара. Иртәгә нишләрбез?

Такташ. Син нишлисең? Син Мәскәүгә укырга китеп барасың. Миңа хәл итәргә барысын да.

Гөлчәһрә. Я инде, син ир-ат бит, юкка җебеп утырма. Бүген үк баланы әниләргә илтеп куярбыз. Ул җаен табар. Бала үстергән кеше.

Такташ. Гөлчәһрә! Китмисеңме әллә, канәтем? Син дә булмасаң, җүләрләнәм бит мин монда. Акылымнан шашам бит мин синнән башка.

Гөлчәһрә *(көлеп)*. Шигырь язарсың! Шагыйрь кешегә язу өчен сагыш кирәк, газап кирәк, аерылу кирәк. Менә дигән шигырьләр язарсың.

Такташ. Берне язарсың, икене язарсың. Биш ел бит ул, Гөлчәһрә. Биш ел синсез. Янып, ташка әйләнермен бит мин! Бер-беребезне югалтырбыз без синең белән...

Гөлчәһрә. Юкны юрап утырма әле. Тукта, тукта, тукта? Син көнләшәсеңме әллә? Шуңа күрә җибәрәсең килмиме?

Такташ. Үлеп көнләшәм. Яныңнан искән җилдән дә, сөялгән багананнан да көнләшәм! Өстеңә кигән күлмәгеңнән дә көнләшәм, ул миңа караганда сиңа күбрәк сарыла! Көнләшәм, Гөлчәһрә. Көнләшүемне дә беләсең, яратуымны да... Китмә, бәгърем. Укып бетер монда гына. Хоть көн саен үзеңне күреп, исәнлегеңне белеп торырмын.

Гөлчәһрә. Юк, Ади, юк. Без монда гомердә дә кеше арасына керә алмыйбыз. Хәзер башка заман. Мәдрәсә белеме белән генә әллә кая барып булмый.

Такташ. Мин — шагыйрь. Аңлыйсыңмы, шагыйрь!

Гөлчәһрә. Син — бүген шагыйрь. Иртәгә кем буласыңны кем белә? Әнә газета битләрендә ничек талыйлар үзеңне. Кругом бит! Вак буржуа да калмый, черек идеология, чит элемент, тагы әллә нәрсәләр. Мин беләм синең ярлы Хәйрук малае, чабаталы даһи икәнеңне, үзең дә беләсең. Син үз-үзеңне яклый алмыйсың. Менә мин сине

яклар өчен укырга тиеш. Мин университетның юридик факультетына да шуның өчен барам.

Такташ. Мине яклар өчен, значит?

Гөлчәһрә. А как же! Сине, үземне, улымны. Икебезнең беребезгә укырга кирәк. Хис белән генә тамак туймый.

Такташ. Гел болай булмас әле, Гөлчәһрә. Менә пьесага утырам, хикәяләр язып карарга да исәп бар. Әгәр китүеңнең сәбәбе шул гына — хәерчелек кенә булса — көнтөн эшлим! Баш күтәрми язам! Китмә генә!

Гөлчәһрә. Их, Ади! Син хәзер дә көн-төн эшлисең бит! Булмый, шигырь язып кына яшәп булмый. Гаилә, бала булгач, бигрәк тә... Әле әти-әниләрең, туганнарың җыелып көтеп тора. Әниләрең хат саен хәлләре авырдан зарланалар.

Такташ. Аларның хәлләре безнекеннән дә авыр шул. Шигырь язып кына рәткә сала торган түгел. Ә впрочем, синең укуыңнан да ярдәм көтмим мин. Йөрәгемдә әллә нинди шом. Сине мәңгегә югалтырмын кебек.

Гөлчәһрә *(каршысына тезләнеп)*. Шашкан даһием минем! Мин бит төшләремдә дә синең тавышыңны ишетеп уянам! Синдәге йомшаклык, синдәге наз, синдәге күңел — бөтен дөньясында юк бит алар! Җүләрем! Яратам! Шашып яратам! Телисеңме, мин сиңа әле ун малай табып бирәм?! Укыйм да, балаларыңа ана да булам — син сабыр гына ит, син бераз көт кенә!

Такташ. Көтәм... Мин гомер буе көтәргә дә риза. Тик... җаныма хыянәт кенә итмә, Гөлчәһрә! Мин синең хыянәтеңне күтәрә алмам.

Гөлчәһрә *(кулларыннан үбеп)*. Беркайчан да, беркайчан да.

Теге якта бала елый. Гөлчәһрә аны алып чыгып, Такташка тоттыра. Үзе әкрен генә чыгып китә. Такташ баланы көйләп йоклата. Бүлмә караңгылана. Такташ баланы караватка сала. Караңгыда Такташ һәм бала караваты гына яктыртыла. Тагы тәрәзәдән җил-давыл бәреп керә. Такташның бөтен бүлмәсен туздыра. Такташ күкрәге белән бала караватын җилдән саклый. Бүлмәдә кәгазьләр оча. Такташ, зур көч, газап

белән караватп-бүлмәне (язмыш, тормышны) югарыга таба этеп алып менә башлый. Җил бераз тынган арада карават өстенә куеп шигырьләр яза. Идән тагын кәгазьләр белән тула. Тирә-юньдә — шайтан, пәри түе. Зур корсаклы түрәләр, чиновниклар, тук тормышлы кешеләр. Такташ һаман тормышны берьялгызы югарыга таба этә. Чит-читтән тавышлар: «Иҗатына крест куярга кирәк!», «Сызып ташларга!», «Вак буржуа!», «Талант!», «Чабаталы даһи!», «Ха-ха-ха!» 1926, 1927, 1928 еллар — ялгыз гаилә тормышы артта кала. Такташ һаман менә дә менә.

Пәрдә

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

1929 ел. Казан. Такташ бүлмәсе. Өстәлдә Гөлчәһрә фотосы. Такташ Гөлчәһрәгә хат язып утыра. Эфирда хат тексты:

«Гөлчәһрә!

Сиңа 15 сум акча җибәрдем. Үзебез бер төрле торабыз. Бала исән. Үземнең настроение бик начар. Ялгызлык, юксыну, әллә нәрсә. Торасың, эшлисең, әллә нәрсә. Ә бит дөньяга яшәр өчен килгәнбез — ә яшәвебез әллә нинди юлсызлык, кызыксызлык белән бара. Аерылып торуның да чиге булырмы икән? Соңгы вакытларда эшләгән дә юк. Эшләргә дәрт тә юк. Эшләвемнең кирәге дә юк. Сине сагынам. Тыныч, пошлый, әллә нинди авыр сагыну белән сагынам. Соңгы көннәрдә бигрәк ялгыз. Кемне дә күрәсе килми. Сөйләшәсе, шулай ук үземне үзем дә күрәсе килми. Әллә нәрсә йөрәктә. Сау калам.

Такташ.

4 январь 1929 ел»

Ишектә Ак Дус күренә.

Ак Дус. Әллә йоклыйсың инде, Такташ?

Такташ. Йоклыйм, дустым, җаным йоклый, йөрәгем йоклый. Уятучымны югалттым.

Ак Дус. Син бигрәк хис кешесе, Такташ. Бер генә минут газапланмый, бәргәләнми торган вакытың бармы икән синең?

Т а к т а ш. Мин сиңа әйткән идем бит инде — янмасам, газапланмасам, мин шагыйрь түгел, дип. Тик соңгы вакытта тормыш мәшәкатьләре, ваклык күмеп китте. Җанны шул баса.

А к Д у с. Сизелә, Такташ, сизелә. «Югалган матурлык»та да нык сизелә ул.

Т а к т а ш. Укып чыктыңмы?!

А к Д у с. Укыдым. Яхшы нәрсә. Но сүзе күп булачак. Хатын-кыздан җәмәгать эшлеклесе дип йөргән вакытта, син аны бөтенләй өйгә бикләп куярга өндисең!

Т а к т а ш. Аңламагансың! Сүз хатын-кызны йортка бикләү турында бармый, сүз хатын-кыздагы гүзәллекне, аңа табигать биргән сыйфатларны саклап калу турында бара! Әлбәттә, һәрбер укучы, караучы шушылай аңласа, тәнкыйтьтән башың чыкмас.

А к Д у с. Нәкъ шулай аңлаячаклар. Әле сине үз тормышыңны язуда гаепләячәкләр. Кайбер элементларын мин дә шәйләдем.

Т а к т а ш. Но монысы инде слишком! Әдәби әсәрдән тагы минем гаилә серләрен эзли башласыннар!

А к Д у с. Мин әйттем, калганын үзең уйла. Син — автор. Син — даһи. Син — Такташ. Мин бер футурист кына.

Т а к т а ш. Синең күңелең ак. Син уйлаганыңны әйтәсең. Минем янда соңгы вакытта берне уйлап, икенчене эшләүчеләр күбәйде ахры. Үземнең янда шигырьләремне мактап чыгып китәләр дә, карыйм — икенче көнне газетада тәнкыйть. Шул «дус»ның берәрсе язган була...

А к Д у с. Бар, андыйлар да бар. Мин үзем дә күп кыйналам. Ләкин мин синең кебек йөрәккә якын алмыйм. Кызык кына. Көрәш дәрте кыза.

Т а к т а ш. Ныклабрак, бәгыреңә үтәрлек итеп кыйналганың юктыр әле.

А к Д у с. Кем белә?.. Минем бит әле ныклап язганым да юк.

Т а к т а ш. Анысы дөрес.

Ак Дус. Такташ, керүемнең сәбәбе башка иде. Мәскәүгә барышым, Гөлчәһрәгә берәр сүзең юкмы?

Такташ. Мәскәүгә барышың?! Нигә?

Ак Дус. Соң, йомыш белән. Нәшрият тирәләренә. Болай, шәхси эшләр дә бар. *(Елмая.)* Йөрәк мәсьәләсендә.

Такташ. Йөрәк? Тукта, ә Гөлчәһрәнең кайда торуын син кайдан беләсең?

Ак Дус. Аны кем белми? Мәскәүгә барган саен күрәбез бит.

Такташ. Ничек?! Син Гөлчәһрәне һәр баруыңда күрәсең? Әйтмәгән иде... Сәер.

Ак Дус. Нәрсәсе сәер инде аның. Ул бит кызлар белән тора. Кызлар бар җирдә мин һәрвакыт әзер инде! *(Салют бирә.)*

Такташ. Күзләрең гөнаһсыз, дустым. Әллә уйныйсың гынамы? Юктыр, юктыр...

Ак Дус. Кая, бармы сәлам хатың? Китешем югыйсә.

Такташ. Бар, дустым, бар! Үз кулына тапшыр. Тизрәк кайтсын. Кайбер имтиханнарын җәйгә калдырырга да була. Такташ сагынудан җүләрләнә диген... Юк, берни әйтмә. Менә хатны гына тапшыр.

Ак Дус. Ярар, бер атнадан җавабын алып кайтырмын. Көт. *(Китә.)*

Такташ *(ялгызы)*. Көтмичә нишлисең?.. *(Кульязмаларын кулына ала.)* 18 январьда театрда «Югалган матурлык»ны уйнаячаклар. Соңгы вакытта күңел кушуы буенча язылган бердәнбер әйбер. Казан мещаннары ни әйтерләр икән? Төрле яктан тагы ут ачарлар инде. Әй, кадалып китсеннәр! *(Язарга утыра.)*

Кара Дус керә.
Эфирда Кара Дус уйлары.

Яза, һаман яза. Нәрсә шул чаклы мәҗбүр итә аны тилереп, котырып язарга? Ярым ач, ташланган, тибелгән. Ә һаман яза. Менә минем язар өчен бөтен шартларым бар — җылы өем, назлы хатыным, өстәл тулы сыем, дә-

рәҗәле урыным. Ә яза алмыйм. Ул яза, ә мин яза алмыйм! Халык аның өчен үлеп тора, мине эш урыныма карап кына санлыйлар. Нәрсә бу?! *(Кычкырып.)* Нәрсә бу?

Т а к т а ш *(борылып)*. Ә, иң якын дустым! *(Кочаклап ала.)* Уз, утыр әйдә. Иң ямансу чакларымда әле дә ярый син бар. Эч пошудан үземне кая куярга белмим.

К а р а Д у с. Мин сиңа сөенечле хәбәр белән килмәдем әле, Такташ. Мин дә үз-үземне кая куярга белмим. Синең өчен, синең гаиләң өчен борчылам.

Т а к т а ш. Тагы Гөлчәһрә турындамы? Ни ишеттең?

К а р а Д у с. Берни дә ишетмәдем. Ишетсәм дә сиңа әйтмәс идем. Барыбер ышанмыйсың. Аның күпме случайларын мин сиңа әйтә килдем, гел гафу итә килдең.

Т а к т а ш. Гайбәт иде бит ул! Без Гөлчәһрә белән аңлаштык бит инде.

К а р а Д у с. Хатын-кызга ышанма син... Мәскәүгә баргач, минем үземә дә күзләрен бик уйнаткан иде ул. Киноларга чакырган булып, кичләрен бакчалардан әйләнеп килик, дип.

Т а к т а ш. Син! Шушыңа чаклы бу хәлләрне миңа әйтмәдеңме?! Син — минем иң якын дустым — шушы эшләргә бардыңмы?! *(Йөзен каплап читкә борыла.)*

К а р а Д у с. Соң, Такташ, соң, җаным, барсам, сиңа сөйләп торыр идемме? Йөрәгемә түзә алмаганга гына сөйлим. Сине жәлләп. Их, син, аңламадың... *(Китә башлый.)*

Т а к т а ш. Зинһар, китмә. Калдырма мине ялгызымны. Әйтер сүзең ул түгел иде бит...

К а р а Д у с *(кире килеп)*. Ул түгел иде шул. Но синең болай да чыкмаган җаның гына калган. Анысын да әйтсәм, бөтенләй аяктан егылырсың.

Т а к т а ш. Әйт.

К а р а Д у с. Безнең Ак Дус Мәскәүгә Гөлчәһрә янына китте.

Т а к т а ш. Беләм. Ул миңа әйтте.

Кара Дус. Әйтте?! Барган саен керүен дә әйттеме?

Такташ. Анысын да әйтте. Мин әле Гөлчәһрәгә хат та биреп җибәрдем.

Кара Дус. Их, Такташ, бөтенләй сукырайгансың икән син. Ул бит Мәскәүгә синең хатының белән гыйшык-мыйшык уйнар өчен генә йөри. Хат илтә, имеш. Ах, дустым, дустым, башың бер дә юк икән.

Такташ. Тукта, ничек гыйшык-мыйшык? Ул бит минем дустым, шагыйрь кеше.

Кара Дус. Булса соң! Ул бит Гөлчәһрәне гомере буе яратты. Өйләнми дә бит. Соң, аларның яратышуларын, йөрүләрен ярты Казан, ярты Мәскәү белә бит инде! Син белмәмешкә салынасың.

Такташ. Беттем. Җир йөзләренә чыгарлыгым калмады. Чат саен бармак төртеп миннән көләрләр. Их, Такташ! Харап иттең тиңсез башыңны хатын-кыз белән бәйләп!

Кара Дус. Кайгырма, дустым! Аер да җибәр син аны. Менә дигән кыз табып бирәбез без сиңа.

Такташ. Аны беркем дә алыштыра алмый... Беләсеңме, нәрсә әйтсәләр дә, шушы хәлендә дә... сагынам... яратам... аңа ышанам, кеше сүзенә түгел.

Кара Дус. Бала-чага булма. Бүген Мәскәүгә чыгып кит, бүген эзләренә төшәсең. Күзәтеп йөр. Бер атна йөр, бер ай йөр, барыбер эзләренә төшәрсең. Сүземне тыңла, дурак булма.

Такташ. Шагыйрь кеше өчен болай йөрү — түбәнлек. Болай йөргәнемне белсә, Гөлчәһрә үзе аерылырга гариза язачак. Син әле аны белмисең.

Кара Дус. Язмый! Хатын-кыз язамы соң?! Шулай мыскыллап, теңкәңә тия әле ул синең. Тиенләп акчаңны суырып ятып... Бар тапканыңны шуңа җибәреп ятасың бит. Башыңа кияргә бүрегең дә юк... Кеше арасында синең өчен кызарам...

Такташ. Нишләргә соң? Әллә чынлап та барып кайтыргамы? Юлга акча ягы да такыр. Шушы көннәрдә пьеса

да уйналырга тиеш. Хатын-кыз артыннан йөри торган вакытмы соң?!

Кара Дус. Акчасын үзем биреп торам. Мә, күпме кирәк? Бар, йөр, күр.

Такташ. Алайса, болай итәбез. Мин тиз генә театрга барып кайтам. Пьесада үзгәртәсе урыннар бар иде. Эшкә дә кереп чыгарга кирәк. Записка булса да калдырырмын. Син, зинһар, бала янында утырып тор инде. Ул бераз авырыбрак тора иде.

Кара Дус. Ярар, бар, борчылма, утырырмын. Журнал өчен тәмамлыйсы мәкаләм бар иде. Шуны карап чыгармын.

Такташ. Әнә, минем пьесага да күз салып алсаң була. Син укымаган бит әле аны. *(Китә.)*

Кара Дус. Йөгерәсеңме? Йөгер-йөгер, тормыш йөгертә ул. Бу сиңа янар таулар, җен кызлары турында шигырь язу гына түгел! Чабаталы даһи! Казанның иң гүзәл кызына нәфсен сузды бит! Үзенең кем икәнен белмичә. Соң, андый гүзәлләрне саклый алырлык нәрсә бар соң синдә?! Нәрсә?! Талант диярсең бәлки? Талант... Андый гына талант бездә дә бар ул. Үтә кызыл тиз уңа ди. Үз урыныңа утыртырлар әле сине, тәти җегет. Кара бу бүлмәдәге салкынлыкны! Башыңа киеп утырмасаң, колагың өшер. *(Бүреген кия. Кульязманы алып карый.)* Бөтен татар театры, авыз суларын корытып, шушы әйбер турында сөйлиме инде? Да, тел дә бар инде үзендә... Бар монда хикмәтле нәрсәләр. Әйдә, куелсын әле. Бу инде сиңа тиләләр турында шигырьләр генә түгел, моның өчен *(өскә күрсәтеп)* әнә анда җавап бирергә туры киләчәк. *(Тагын кәгазьләр карый башлый.)*

Ишектән әкрен генә Гөлчәһрә керә. Башында озын колаклы ак куян бүрек, өстендә кыска тун. Кулында чемодан. Ул килеп Кара Дусны арттан кочып ала.

Гөлчәһрә. Үләм! Сагындым! Сагындым... Кулларыңны сагындым, күзләреңне сагындым. Даһием, шашканым, көнчелем, җүләрем. *(Алдына тезләнә.)*

Кара Дус. Я, хода! Дөньяда шулай итеп тә яратып буламы икәнни?!

Гөлчәһрә *(сискәнеп сикереп тора).* Син кем?! *(Пистолет чыгара.)* Ничек монда кердең? Җаныңны җәһәннәмгә очырам бит хәзер!

Кара Дус. Чү, чү, Гөлчәһрә! Бу мин бит, мин. Такташ театрга китте, мин бала карап утырам.

Гөлчәһрә. Син?! *(Кычкырып көлә башлый.)* Атып үтерә яздым бит үзеңне. Такташ дип белеп, ялгыш кочаклап та ташладым ахрысы.

Кара Дус. Гомеремдә андый назны беренче күрдем. Син Такташка гел шулаймы?

Гөлчәһрә. Мин Такташка гел шулай! Мин аны сихерләдем! Мин аны яратам. Мин аны ашап бетерер идем. Менә бер төнгә, бер көнгә күрер өчен кайттым үзләрен. *(Бала янына килә.)* Йоклыйсыңмы, улым? Үсеп киткән. Тагын бер ел укыйсым калды. Аннары бер көнгә дә аерылмас идем үзләреннән!

Кара Дус. Я, Мәскәү нишли анда, Гөлчәһрә?

Гөлчәһрә. Мәскәү гөрли. Ул лекцияләр, ул театрлар, ул магазиннар! Я, мин үзгәргәнме? Ябыкмаганмынмы?

Кара Дус. Икенче мондый гүзәлне күргәнем юк әле... Минем сине күргәч үк тәннәрем чымырдый башлый.

Гөлчәһрә. Я, я, күп сөйләшмә. Я Такташны көнләштерерсең. Минем чабаталы даһием нишләп йөри соң?

Кара Дус. Йөри. Тегеләй язып карый, болай язып карый. Аллалар чоры үтте, этләр, мәчеләр чоры да үтте, хәзер әнә, хатын-кызны сүгеп язмакчы.

Гөлчәһрә. Син гомер буе Такташны яратмадың. Ә Такташ шуны аңламый бит. Үзе ир-ат, нинди шагыйрь! Ә синең кара уйларыңны сизми.

Кара Дус. Кем аркасында, кем аркасында шушы хәлгә килдем мин?! Арада гел син басып тордың! Мин аның шагыйрьлегеннән түгел, ирлегеннән көнләштем! Синең аныкы булуыңнан көнләштем, Гөлчәһрә! *(Кулларын*

үбә башлый.) Яратам мин сине! Хатыныма да бөтен дөньясына, сиңа үч итеп кенә өйләндем. Бир миңа назларыңны, назга, җылылыкка сусадым мин... *(Кочакламакчы була.)*

Гөлчәһрә. Кит! Син нишлисең?! Үз өемдә миңа шундый сүзләр сөйлисең?!

Кара Дус. Башка җирдә дә риза! Ризалыгыңны гына бир! Син бит дөнья бәһасе хатын! Риза гына бул! Тәкташны да бу хәлендә яшәтмәм. Дөньяның патшасы итәрмен. Риза бул.

Гөлчәһрә *(барып утыра)*. Димәк, син миңа шундый нәрсә тәкъдим итәсең? Өемә килеп...

Кара Дус. Мәхәббәт тәкъдим итәм... Сөю-сөелү.

Гөлчәһрә *(сикереп торып)*. Мәхәббәт түгел бу! Син миңа азгынлык тәкъдим итәсең! Урам хатыннары белән генә шулай ачыктан-ачык сөйләшәләр.

Кара Дус. Нәрсә, Мәскәүдә кем туры килсә, шуның белән ярый, ә монда сайланабызмы?

Гөлчәһрә. Нәрсә? *(Пистолетын чыгара.)* Бас шушында, җаныңны җәһәннәмгә җибәрәм хәзер шушы сүзләрең өчен!

Кара Дус. Гөлчәһрә! Мин шаярттым гына. Сынап кына карыйсым килде.

Гөлчәһрә. Бас! Бер, ике...

Кара Дус *(алдына тезләнеп, үрмәләп килә)*. Тукта... Тәкташ шулай кушты... Сынап кара, диде. Шаярттым гына... Тукта...

Ишектән Ак Дус кереп, карап тора.

Ак Дус. Бу нинди комедия тагы?

Кара Дус сикереп торып, Ак Дусның артына барып баса.
Гөлчәһрә бала караваты янына борыла.

Кара Дус. Әнә! Мәскәүдән бөтенләй котырып кайткан! Тезләнеп ялындым, Тәкташ белән арагызны бозмагыз дип. *(Ак Дусны читкә тартып, әкрен генә.)* Әле миңа

әллә нәрсәләр тәкъдим итте... «Дустымның хатыны белән алай эшли алмыйм»,—дип кенә котылдым. Син дә кылларын чиертеп кара әле. Капмасмы... Хи-хи-хи!

Ак Дус *(күлмәк якасыннан алып)*. Мин синең үзеңне каптырам хәзер, кара җан! Менә монысы Такташ өчен! *(Яңагына суга.)* Менә монысы Гөлчәһрә өчен! *(Икенче яңагына суга.)* Бар, хәзер ычкын! Дөньяны сасыт!

Кара Дус *(тешен кысып)*. Ярар... Ярар! Күрербез! Күрсәтербез! *(Чыгып китә.)*

Ак Дус. *(Гөлчәһрәнең иңнәреннән сыйпап)*. Елама, Гөлчәһрә. Аның монда башка эзе булмас.

Гөлчәһрә. Соң Такташ барыбер шулар арасында кала бит! Шулар арасында, шулар кулы астында. *(Елап, Ак Дусның күкрәгенә каплана.)* Әллә барысын да ташлап, кайтыйммы икән? Әйт бер сүзеңне, Ак Дус?! Мин хәзер сиңа гына ышанам.

Ак Дус. Ашыкма, Гөлчәһрә. Үзең әйткән идең бит, болар белән көрәшер өчен белем кирәк, дигән идең. Ашыкма, күп калмады... Мин дә Мәскәүгә баргалап йөрермен.

Ишектән атылып Такташ килеп керә.

Такташ. Димәк, дөрес... *(Гөлчәһрә сискәнеп башын күтәрә.)*

Гөлчәһрә *(аңа атылып)*. Һади! Һадием!

Такташ. Тукта! Карама миңа алай итеп, карама! *(Йөзен читкә борып, бала караваты янына килеп утыра.)* Менә нәрсә, Гөлчәһрә! Синең турыңда монда инде ничә еллар төрле сүз, гайбәт йөри. Мин һаман ышанмый килдем. Инде үз күзләрем белән күрдем! Кит!

Ак Дус. Такташ, туктале, син ни сөйлисең?

Такташ. Икегез дә чыгып китегез. Моннан соң берегез — хатын, икенчегез — дус түгел. Чыгып китегез... *(Бала караваты өстенә каплана.)*

Гөлчәһрә. Һади! Нишләвең бу, Һади?! Мин бер генә төнгә кайттым. Сине, улымны күрермен, дип кенә кайттым. Ни сөйлисең син?!

Такташ. Мин сиңа ышанмыйм! Мин сине яратмыйм! Мин сине күралмыйм! Кит.

Ак Дус. Их, Такташ! Чынлап та, сукыр икәнсең син! Киттек, Гөлчәһрә! Суынсын бераз даһи башы.

Гөлчәһрә. Нишләп синең белән китим мин?! Сез әле Гөлчәһрә Хәмзинаны белмисез! *(Такташка.)* Ут вакытымны күрдең, таш вакытымны да татырсың! *(Пистолетын алып, чыгып китә.)*

Ак Дус. Гөлчәһрә! Үзенә берәр нәрсә эшләсен тагы! Гөлчәһрә! *(Чыгып йөгерә.)*

Караватта бала елаган тавыш ишетелә. Такташ башын күтәрә.

Такташ. Кемгә ышаныйм?! Кемгә?! Тирә-ягым ялган, гайбәт, каралык, талантсызлык белән тулы. Кем бар шагыйрь хәлен аңларлык? Кем?

Караңгылык.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

1929 ел, 27 январь. Татар мәдәнияте йорты. Яшь язучылар түгәрәге җыелышында Такташның «Югалган матурлык» пьесасы тикшерелә.

Такташ *(пьесаның ахырын укый).* «...Галия. Газиз... Газиз... Син йоклыйсың? *(Пауза.)* Ул арып йокыга киткән... Газиз, минем хәлем бик авыр. *(Аяк өстендә тора алмый, хәлсез генә җиргә утыра.)* Сөекле дустым, юк, юк, мин синең мине алдавыңа ышанмыйм... Син миңа яхшы ир идең. Син бөтен көчең белән мине югалтмаска тырыштың... Син миңа яхшы иптәш идең. Шуның өчен дә... *(Ютәлли.)* Шуның өчен дә өзелеп яраттым... Син әйт миңа. Мин сиңа ике сорау белән киләм. Мин үземнең исәнлегемне югалттым. *(Буылып ютәлли.)* Мин үземнең, мин үземнең аналыгымны югалттым... Мин бөтен матурлыгымны югалттым. Әйт, әйт, мин кешелек дөньясы ал-

дында беренче ана булырга тиешле идемме яки җәмгыять эшчесеме? Син әйт миңа!» *(Ул үксеп елый башлый, аның үксүе тыела алмаслык ютәлгә әйләнә. Иреннәре буенча кан елгалары ага. Ул күкрәген тотып җиргә каплана. Скрипка тавышы һаман ишетелә. Газиз тын гына йоклый. Бераздан бүлмә тынлыгы эчендә Галиянең соңгы авыртулы ыңгырашуы ишетелә. Пәрдә әкрен генә төшә.)* Иптәшләр, пьеса тәмам. Сездән чын иҗат кешеләречә фикер көтәм. Моңа хәтле минем әсәрләремнең идеологиясен тикшереп җанга тияләр иде, бәлки бу юлы әдәби эшләнешенә, образларга игътибар итәрсез. Чөнки бу нәрсәләр минем алга таба үсүем өчен дә бик кирәк.

Яшь артист *(урыныннан)*. Минем Такташка бер соравым бар. «Югалган матурлык» әле 18е көнне генә татар театрында уйналды. Аннан Такташны «Кызыл Татарстан»да бик каты тәнкыйтьләп чыктылар. Шушы тәнкыйтьтән соң да нигә ул пьесаны безнең алда укырга уйлаган?

Такташ. Чөнки, минем уйлавымча, рецензия очраклы бер кеше тарафыннан язылган. Ул хәтта үзенең фамилиясен дә күрсәтергә курыккан — мәкаләсенең ахырына «Бис» дип кенә куйган. Мәкалә бик бер яклы, тенденциоз характерда язылган. Ул мине сәяси наданлыкта, сукырлыкта гаепли. Соң, җаным, лозунг ыргытып та, шуны үтәлде дип, авыз күтәреп йөри икән, ул үзе сәяси надан. Безнең әле күп лозунгларыбыз һавада эленеп тора. Кем сукыр соң монда? Мин — булган кимчелекләрне күреп, әйтеп биргән өченме, яки күреп тә күрмәмешкә салынып йөргән, башкаларны да күрмәскә өйрәтә торган «ялган авторлар» гаепleme? Каршылыклар күп...

Алып баручы *(кыңгырау шалтыратып)*. Мәсьәләдән читкә кителде. Такташ, пьесаң турында гына сөйлә.

Такташ. Мин шул турыда сөйлим дә. Я, тагы кемдә нинди фикер бар? Миңа сезнең бүгенге фикерегез бик мөһим. Чөнки мин «Югалган матурлык»ның бу бәя белән генә калуын теләмим.

Яшь шагыйрь. Такташ, үзең ничек уйлыйсың — хатын-кыз ана булырга тиешме, җәмгыять эшчесеме?

Такташ. Икесе дә. Ләкин җәмгыять эшчесе булу аның ана булуына зыян китерергә тиеш түгел. Начар ана икән, аның яхшы җәмгыять эшчесе булуының кирәге юк.

Урыннан тавышлар. Долой! Буржуй җыры. Ул хатын-кызны өйгә бикләп куярга куша! Аның үзен бикләп куярга кирәк! Ха-ха-ха! Чит элемент!

Алып баручы кыңгыравын шалтырата.

Матур кыз. Такташ, сезгә бер сорау. Сезне хатыныгыз ташлап чыгып киткән, диләр. Бу пьесаны да шул ачудан язгансыз, ди. Шул дөресме?

Такташ. Туташ! Гаиләмдәге шәхси эшләрне мин биредә сөйләргә җыенмыйм. Ә пьеса мәсьәләсенә килгәндә, Галия кебек эш белән гаилә арасында бәргәләнеп йөрүче хатыннар — мең вә миллионнар! Мин алар турында яздым. Мин аларның язмышы, киләчәге өчен борчылып яздым. Шул ук вакытта сезнең язмыш өчен дә.

Яшь журналист. Нигә бөтен коммунистлар, комсомоллар сезнең пьесада кире типлар? Сез нәрсә, моның белән безнең политик стройга кизәнәсезме?

Астан тавышлар. Әйе, җавап бирсен! Нигә барысы да кара?! Эчкечеләр дә алдакчылар! Нигә җүнле кешеләрне алмаган?!

Такташ. Җавап бирәм. Әсәрдә җүнле кешеләр дә бар. Ләкин Алар менә шушы черек мещаннар сазлыгында берничә генә. Хәзергә әле аларның тавышлары күмелеп китә. Аның өчен башта менә бу сазлыкны чистартырга, баш миләренә ачыклык кертергә кирәк! Коммунистларның — коммунист урынында, аналарның ана урынында булуы кирәк!

Астан сызгырулар, кычкырулар.

Матур кыз. Такташ, сез «Азат хатын» журналында эшлисез икән. Хатын-кызга карата шушындый черек, ме-

щанский караштa торганда, сез ул журналда эшләргә хаклымы соң? Сез бит коточкыч куркыныч тип!

Астан. Долой! Долой! Эштән куарга!

Алып баручы. Туктатыгыз! Бу Такташка суд түгел! Фикер алышу гына. Калганын башка урында хәл итәрләр. *(Кара Дуска.)* Сезнең берәр фикерегез юкмы?

Кара Дус. Иптәшләр! Бераз гына басылыйк әле. Суыныйк. Уйлыйк. Менә без бүген Такташның пьесасын укып чыктык. Төрле фикерләр ишеттек. Кызып китүчеләр дә булды. Минем үземә килгәндә, пьеса шактый четерекле мәсьәләләрне күтәрергә тырышкан. Плюслар да, минуслар да бар. Әйе, үсеп килә торган социалистик җәмгыятьтә әле төрле типлар очрый. Әмма шулай булуга карамастан, безнең илебез гөрләп чәчәк ата! Татарстан кырларына техника үтеп керде. Кызыл яулык бәйләгән хатын-кызларыбыз завод-фабрикаларда җырлап тимер кыралар!

Ак Дус *(астан)*. Син пьеса турында сөйлә! Әллә үзеңне актив җыелышында дип белдеңме?

Кара Дус. Сөйлим! Пьеса турында да сөйлим... Кайда калдым әле? Әйе, илебез гөрләп чәчәк ата! Иптәшләр! Мин бүгенгесе көннән шагыйрь Такташны, вак буржуа арасыннан чыккан Такташны үз тәрбиямә алам! *(Астан кул чабалар.)* Ул пролетариат шагыйре булырга тиеш. Җитте аңа черек тормыш баткагында казынырга! Ул — талантлы шагыйрь! Даһи!!! Ул әле илнең менә дигән җырчысы булачак! Сез шагыйрьне бер дигәндә үтереп ташларга ашыкмагыз, әле аны җырлатырга кирәк! Бугазына басып, чүкеч тавышы астында җырлатырга кирәк!

Астан кул чабулар.

Мин беренче булып, үзем аңа ярдәм кулы сузам.

Ак Дус. Соң синең үзеңә ярдәм кирәк бит! Син көчәнмичә ике юллык шигырь дә яза алмыйсың бит! Әле Такташка ярдәм итмәкче! Тәрбиягә алмакчы! Түрә булганга гына шулай түш киереп сөйлисең бит син...

Кара Дус. Такташ, мин чын күңелдән, бөтен халык алдында әйткән идем бу сүзләремне. Алай булгач, үзеңә кара. Мин синең юлыңнан китәм.

Такташ. Дус, тукта! Кабул итәм мин синең сүзләреңне! Ярдәмеңне дә кабул итәм. Арыдым мин... Синең ярдәмең бик кирәк.

Ак Дус *(үтеп барышлый)*. Такташ, башка кыйблага сәждә кыласың.

Такташ. Мин сиңа теге көнне соңгы сүземне әйткән идем инде. Ышанмыйм мин сиңа, аңлыйсыңмы, ышанмыйм! Кермә арага, миңа үземчә яшәргә ирек бир. Үземчә яшәргә ирек бирегез миңа! *(Чыгып китә.)*

Кара Дус. Ишеттеңме? Бу — аяк астында буталып йөрмә, дигән сүз. Талантыңнан көнли ул синең.

Ак Дус. Шаһитлар күп, концерт күрсәтер идем инде мин сиңа... *(Чыгып китә.)*

Яшьләр дә таралып бетә.

Яшь журналист. Сез мактап сөйли башлагач, башта бик гаҗәпләнгән идем...

Кара Дус. Тс-с-с! Күп сөйләшмә. Шулай кирәк. Мәкаләң башта сөйләшенгәнчә булсын. Тозлап-борычлап.

Яшь журналист. Үрле-кырлы сикертәбез Сыркыды мишәрен! Ник Казанга килгәненә үкенерлек булсын!

Кара Дус. Талантыңны кызганма. Эшеннән алдырырлык булсын. Эшеннән чыкса, икенче көнне үк шартлап сына ул. Казанда калмаслык итәбез без аны.

Яшь журналист. Ә нигә сез тәрбия, ярдәм дип маташкан булдыгыз соң?

Кара Дус. Анысы син аңларлык нәрсә түгел... Мин әле аның шагыйрь буларак та таркалып, үз иҗатын үзе бетерүен телим! Менә үзе теләмәгән, үзе яратмаган нәрсәләр турында язып карасын әле ул! Күрербез аннары, даһилыгы нишләр! Миңа ышануы кирәк аның! Һәм минемчә язуы кирәк!

Яшь журналист. Ну баш сездә! Юкка гына шундый урында утырмыйсыз шул.

Кара Дус. Син дә утырырсың! Мәкаләңне генә яз! Кара аны, үзем күзәтеп торам, озакка сузма.

Яшь журналист. Чыгармасалар? Аны яратучы, яклаучылар да күп бит.

Кара Дус. Син яз гына. Чыгару — минем эш.

Яшь журналист. Язам! Такташ ник туганына үзе үкенерлек итеп язам!

Караңгылык.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Такташ бүлмәсе. Такташ Гөлчәһрәгә хат яза. Хатның эфирдагы тексты.

«Гөлчәһрә!

Теге вакыттагыдан соң гаилә тормышы, бигрәк тә синең белән тормыш, матур тормыш төзүгә бөтенләй дәрт бетте. Аңлыйсыңмы? Бөтенләй, бөтеп нәрсә безразлично булып китте. Икебез өчен дә күңелле бер нәрсә тудыруга яки эшләүгә ышаныч та сүнде, дәрт тә бетте. Казандагы бүгенге минем эш мәйданым талантсыз кешеләр белән тулы. Алар бөтен пычраклыклары белән минем юлыма киртә салырга телиләр. Минем әдәби гомеремне Есенин дарына илтеп терәргә телиләр.

...Миңа каршы кешеләр — үзләренең туулары белән революция әдәбиятына бәхетсезлек китергән кешеләр. Партия, сукыр рәвештә, кызыл, җансыз, алдаучы сүзләренә карап, аларны яклый. Ул кызыл, җансыз, алдаучы хамелеоннарны, яки тупас, талантсыз иҗат итүче типларны еллар күмәр. Минем алдаусыз хисләрем һаман, һаман шулай калыр. Менә шуның өчен бөтен тупас бәйләнүләрне күтәрергә тырышам. Киләсе югары еллар мине яклар...»

Кара Дус керә.

К а р а Д у с. Хатлар язабызмы? Я, я, яшермә, барыбер күрәм бит! Һаман шуңа хат язасың. Нәрсәсе белән сихерләгәндер үзеңне, шаккатам.

Т а к т а ш. Башка язар кешем булмаганга язам... Инерция буенча, туктала алмыйча йөгерәм.

К а р а Д у с. Шигырь язганың да күренми.

Т а к т а ш. Язам! Алай да күңелнең ачылып-ачылып киткән вакытлары була. Менә, тыңла! Шәп, якты шигырь яздым. *(Укый.)*

Урам ташларына карлар ява,
Кар томалый чана юлларын,
Кардан шуа-шуа Алсу килә,
Җиң эченә тыккан кулларын...
Җилгә каршы бөдрә сулышлары
Туңып бөдрә чәчен ак ясый...
Юл буена аны тирги-тирги,
Сүгнә-сүгнә кайта Газзәсе:
— «Алсу, тукта инде, акыллым,
Абау,
Тагын карга батырдың!» —
Ул үпкәләп читкә китә. Аны
Алсу тагын ялынып чакыра:
— «Кил, уйнамыйм, бетте...
Кил инде!»
Үзе — килсә, карга батыра.
Салкын карга басып Алсу килә:
Үзе көлә,
Үзе сөйкемле,
Үзе усал,
Үзе болай бер дә
Усал түгел кебек шикелле...

К а р а Д у с *(туктатып)*. Булды. Аңлашыла. Тагын үз хатының турында. Синең башка язар нәрсәң калмады бугай инде.

Т а к т а ш. Дөрес әйтәсең, авыр, дустым. Кайвакытта очраклы нәрсәләр турында шигырь язам. Пьесалар белән

дә әнә нәрсә килеп чыкты. Прозага күчеп карыйм. Роман яза башладым.

Кара Дус. Роман?! Нәрсә турында?

Такташ. Анда барысы да булачак. Үткән көннәр дә, киләчәк тә. «Таң җиле» дип атала. Кешенең үз-үзен, үз кыйбласын эзләве турында.

Кара Дус. Табамы соң?

Такташ. Һичшиксез, табачак! Кыйблаңны тапмасаң, яшәүдән мәгънә дә юк.

Кара Дус. Безнең кыйбла — илнең алга баруы.

Такташ. Ярый, ул сүзләреңне монда калдырып тор әле.

Кара Дус. Такташ, үпкәләмә, сине вак буржуа дип белеп сүккәннәр бит теге вакытта. Гел кирегә сукалап утырасың бит. Менә газетага да синең турында бик куркыныч итеп язганнар. Кара, һаман мин яклап кала алмам сине.

Такташ. Тагы? *(Газетаны ала.)* «Югалган матурлык» турында? *(Укый.)* «Татар әдәбиятында чит идеология. Кызылга төрелгән чит фикерләр турында». *(Газетаны читкә ташлый.)* Тәмам буржуй ясадылар миннән! Редакторларын әйтер идем. Соң бу бит судка бирелә торган нәрсә! Тоталар да миннән чит идеология эзлиләр. Ә мин — шагыйрь, бары татар шагыйре! Ә алар, тоталар да миннән чит идеология эзлиләр.

Кара Дус. Үзең гаепле. Син генә илдәге проблеманы күрәсең дә, без күрмибез. Без дә күрәбез. Дәшмибез. Шулай яхшырак.

Такташ. Кем өчен?! Сезнең үзегез өчен яхшыракмы? Әй! *(Кул селти.)* Тагы тирәнгә керәбез. *(Газетаны алып карый.)* Кара, теге яшь журналист малай язган. Әйтәм теге көнне политический сораулар биреп утырган иде. Ул үзе кемнеңдер йомышчысына охшаган. Да, политик яктан суктырган бу, мишәрлектә генә гаепләмәгән.

Кара Дус. Син нәтиҗәсен укы, нәтиҗәсен.

Такташ. Так, нәтиҗә. *(Укый.)* 1) «Югалган матурлык» хәзерге көндә активланып, каты көрәш алып бара

торган вак буржуазия, кулак идеологиясенең татар матур әдәбиятына керүен күрсәтә, «Югалган матурлык» — шуның документы.

2) Электән дә идеология ягында тотанаксыз булган Такташ хәзер ачыктан-ачык чит идеология лагерена тәгәри.

3) Безгә матур әдәбиятка һәм аны тудыручыларга нык күз салырга кирәк». Юк, бу аның үз кулы, үз фикере түгел. Ул малайның андый нәтиҗәгә килерлек үз башы юк. Моның артында кемдер тора.

Кара Дус. Ул чагында бигрәк тә начар. Димәк, сиңа каршы зур бер кампания күтәрелеп килә.

Такташ. Ул 23 нче елдан бирле күтәрелә инде. Мин ул кампаниянең исемен, анда кемнәр торуын да беләм.

Кара Дус. Кемнәр?

Такташ. Талантсызлар! Талантсызларга һәрвакыт талантларны юкка чыгарып торырга кирәк. Талантлар янәшәсендә аларның талантсызлыклары ачык күренә бит.

Кара Дус. Я, ташла әле вак фәлсәфәңне. Әнә, Мәскәү газетасында да сине сүгеп язганнар!

Такташ. «Эшче»дәме?

Кара Дус. «Эшче»дә шул. Сине яңа тормышны бозып күрсәтүдә гаеплиләр, әсәреңнең художество ягыннан түбән булуын әйтәләр. Сәхнәдән алуны таләп итәләр! Сине ленинизмга ревизия ясауда гаеплиләр.

Такташ *(сызгырып)*. Менә кая барып җиттеләр! Да, бу инде җитди гаепләү.

Кара Дус. Менә нәрсә, Такташ. Бүген югарыда сүз булды. Сине эшеңнән алырга җыеналар...

Такташ. Нәрсә, журналданмы?

Кара Дус. «Югалган матурлык»тан соң сиңа хатын-кыз журналында эшләү турында уйларга да ярамый. Бу юлы мин сине яклый алмам кебек. «Ялчы» гәзите дә сине судка бирергә йөри икән.

Такташ *(уйланып)*. Мине яклау кирәкми, дустым... Монда яклаудан узып бара инде. Менә эш мәсьәләсе ге-

нә... Бала бар бит, кулда бер тиен акча юк... Их, шагыйрь, шагыйрь...

Кара Дус. Алай бик борчылма, Такташ, без исән бит әле. Эшчеләр арасына чыгып китәрсең, яңа тормышны өйрәнерсең. Яңача язарга кирәк сиңа, бөтенләй яңача! Соң, бер ай эчендә миллионерга әйләнәсең бит безнеңчә язсаң! Макта, Ура! кычкыр, ышан, ышандыр. Сип кызыл сүзләрне! Сиңа нәрсә тора ул?! Их, үз кадереңне үзең белмисең! Язып ятасың шунда җыен черек нәрсә!

Такташ. Тукта! Башка илһам килде!

Һәр заманның үзенең чире була,
Һәрбер чирнең була докторы;
Һәр дәвернең була үзенә күрә
Сволочы (каһәр суккыры!..)
Һәр хәзрәтнең була фидиясе,
Һәрбер җинаятьнең — статьясы,
Һәрбер судның була судьясы.
Һәр бакчаның чүбе булган кебек,
Йолкып ташлый торган кул була;
Килеп кергән ишек күп вакытта
Сөрелеп чыгу өчен юл була...

Кара Дус. Буталчык! Кемне мактыйсың, кемне сүгәсең — һични аңлашылмый... Маташма, тагы контрлык табарлар.

Такташ. Нәрсә языйм соң, нәрсә языйм?!

Кара Дус. Әнә, ташлап киткән хатыныңа хат яз. Йөрәкне бастыру өчен ярый ул.

Такташ. Ха-ха-ха! Дөрес әйттең, дус! Баш исән бит әле, җан исән. Я, хуш, калдыр мине Гөлчәһрәм белән.

Кара Дус. Вот, дивана. Юк, һични алмый сине... Үлем дә алмас сине... *(Читкә.)* Каян көч ала? *(Китә.)*

Такташ *(Гөлчәһрәнең фотосын алып)*. Я, Гөлчәһрә, тагы ялгыз калдым. Ишеттеңме, мине эштән чыгаралар, судка бирергә йөриләр, әсәрләремне басмыйлар, контр, дип язалар, тагы әллә нәрсәләр! Тик бер нәрсәдән туктата алмаслар, ишетәсеңме, Гөлчәһрә, җен кызы?! Язудан тук-

тата алмаслар. Язуымнан туктата алмаслар! Кулларым исән, баш исән, җан исән, иманым исән! Утыр, Такташ, яз шигырь-поэмаларыңны! Үзеңчә яз! Дөресен яз!..

Утыра. Яза башлый. Тирә-ягы тагы кәгазь белән тула. Караңгылык.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

1929 елның көзе. Бакча. Ялапбаш, кулына таяк тоткан Такташ үтеп китә. Ялгызы эскәмиягә барып утыра да шигер укый башлый. Бер төркем егетләр, кызлар керә.

Бер кыз. Кызлар, үләм, әнә шагыйрь Такташ утыра!

Егет. Такташ шул! Их, егетләр, дөньяда тагы шундый шагыйрь бармы икән?

Уйчан кыз. Урысларда Маяковский бар. Ул да Такташ кебегрәк яза.

Матур кыз. Такташ аның кебек яза диген! Ә дөресен әйткәндә, Такташның язганнары бик томанлы, идеологиясе черек.

Егет. Син, чибәр кыз, әдәби түгәрәкләргә еш йөрисең ахры. Гел алар сүзен сөйлисең. Такташны дөрес аңлар өчен аның шигырьләрен укырга кирәк, аның турындагы тәнкыйть мәкаләләрен түгел.

Уйчан кыз. Ул тәнкыйтьчеләр бер дә кемнең кем икәнен чамаламыйлар микәнни?

Егет. Чамалыйлар!.. Просто үзләрен акыллырак күрсәтәселәре килә. Янәсе, нинди шагыйрьне тетеп салалар. Бушбугазлар!

Матур кыз. Карагыз әле, кызлар, аны хатыны ташлап киткән ди. Хи-хи-хи! Шундый матур шагыйрьне! Мескен!

Уйчан кыз. Сиңа шул гайбәт кенә булсын! Шагыйрь, артистлар турында бер гайбәтне дә калдырмыйсың инде! Үзе ишетер дип тормый.

Матур кыз. Әйдә исәнләшкән булып, янында гына үтеп китик әле?

Егет. Шулай иткән, ди. Болай да Такташның башына җитә яздыгыз. Сезнең заттан үзебез саклыйбыз аны хәзер. Марш бу тирәдән!

Чыгып китәләр. Уйчан кыз гына кала.

Уйчан кыз. Әминем, нигәдер, барып аның хәлен беләсем килә! Шул хәтле кызганам мин аны! Аның күзләре бигрәк сагышлы, көлгәндә дә сагышлы. Я, ходаем, бу якка карый... Я тагы әллә ниләр уйлар. *(Чыга башлый.)* Юк, барыбер исәнләшәм, яныннан узам. *(Такташ янына килә.)* Исәнмесез, Такташ абый!

Такташ *(башын күтәрми генә)*. Исәнме, сеңелем...

Уйчан кыз. Башын да күтәреп карамады! *(Чыгып йөгерә.)*

Такташ *(ялгызы)*. Яшьләр!.. Көләләр... Каядыр йөгерәләр. Хыялланалар, нидер көтәләр. Минем хәзер бар көткәнем — Гөлчәһрәдән ихлас бер хат. Алты хатыма бер җавап юк. Барысының да бетүеме бу? Хәбәрләр дөрес булып чыктымы? Янына барып кына кайтыр идем — бер тиен акча юк. Менә ярты ел инде эшсез йөрим. Муеннан бурычым... Баганага сәлам биргән чаклар була. Сына башлавың шушымы икәнни, Такташ?!

Кара Дус керә.

Кара Дус. Такташ! Сөенче! Эш булды сиңа!

Такташ. Чынлапмы, дустым?! Кайда?

Кара Дус. 15 нче октябрьдән «Чаян»да эшли башлыйсың!

Такташ. Аһ, дустым! *(Кочаклап ала.)* Син мине бик авыр хәлләрдән коткардың! Эш бар — димәк, барысы да булачак! Акчасы да, фатиры да, ризыгы да, утыны да! Менә бит бәхет!

Кара Дус. Тегендә үзем сөйләштем. Булды, җитте, шагыйрь акылга утырды, дидем. Аның дальнейший нәрсә язарына үзем җавап бирәм, дидем. Ну син дә мине подводить итмисең!

Т а к т а ш. Булды. Бу алты ай эшсез, бер тиен акчасыз йөрү минем соңгы шашкын уйларымны бәреп чыгарды. Язам! Хәзер ни кирәк — шуны язам. Эшчеләр арасына китәм, шахтерлар тормышын өйрәнәм. Только болай йөрергә генә язмасын.

К а р а Д у с. Шулай, Такташ, шулай. Шул кызудан тагы бер хәл итәсе мәсьәлә бар. Безнең теге футурист шагыйрь белән синең араң ничек?

Т а к т а ш. Теге вакытта бераз эләгешеп алган идек. Соңгы вакытта күргән юк. Татуланасы булыр, болай үпкәләшеп йөрү ирләр эше түгел.

К а р а Д у с. Ашыкма! Ул бит күзәтү астында!

Т а к т а ш. Кит аннан?! Газеталарда шаулаганнар иде шул. Мин чираттагы гайбәт, дип кенә карадым.

К а р а Д у с. Эшләр бик җитди, Такташ. Укыгансыңдыр, алты кеше ниндидер яшерен политик оешма төзегәннәр. «Җидегән» дип атала. Безнең футурист та шулар арасында. Башкортстан белән ике арада. Эш Солтангалиевләргә барып төртелә. Оешмада җиде кеше булырга тиеш, ди. Җиденчесенә синнән шикләнәләр.

Т а к т а ш. Миннән?! Соң миндә политика кайгысы булдымыни соңгы вакытта?! Контр дип печать суктыгыз да, тәки контр ясыйсыз бит миннән! Төрмәгә утыртып куясыгыз гына калды инде.

К а р а Д у с. Син кызма әле. Без сине тиз генә бирмәбез. Ну теге дустан публично халык алдында ваз кичәргә туры килер сиңа.

Т а к т а ш. Юк, мине бутама. Мин аның контр икәненә ышанмыйм! Ышанмыйм!

К а р а Д у с. Ышанырсың! Алар белән бергә үзеңне дә утыртып куйсалар, ышанырсың! Эш мәсьәләсен дә кире уйларга туры килер. Сине яклыйм дип, үземнең утырыр хәлем юк. *(Китә башлый.)*

Т а к т а ш. Тукта... Ник гел шушындый хәлгә куясың син мине, дустым? Сез бит миңа икегез дә бик якын. Нигә мин әйтергә тиеш аңа соңгы сүзне?! Нигә?!

К а р а Д у с. Үзеңне яклар өчен. Гомер буе синең өчен үз күкрәгемне куймам! Бүген монда шигъри митинг була. Үз сүзеңне шунда әйтерсең.

Т а к т а ш. Уйларга ирек бир.

К а р а Д у с. Уйла, Такташ! Алар — ил дошманнары. Илне, халыкны сатарга җыенучылар. Андыйларга карата икеләнеп торырга да кирәкми. Туган атаң булса да төртеп күрсәтә торган вакыт.

Т а к т а ш. Син хаклы. Үз борчуларыма күмелеп, мин тормыштан артта калганмын ахры. Илдәге сыйнфый көрәшне күздән ычкындырганмын. Мин бүген үз сүземне әйтергә тиеш! *(Яза башлый.)*

Бакчага яшьләр җыела башлый. Уйчан кыз да алар арасында.

У й ч а н к ы з. Һаман яза. Иелгән дә, һаман яза. Нәрсәләр яза икән ул? Ничек арымый икән? Сары чәчләреннән бер генә сыйпарга иде шуның...

Ак Дус керә.

А к Д у с. Такташ!

Такташ сискәнеп сикереп тора.

Мин сине дөнья бетереп эзләп йөрим. Миңа синең ярдәмең бик кирәк, Такташ!

Бер-берләренә таба килә башлыйлар. Кара Дус ашыгып араларына керә.

К а р а Д у с. Такташка кагылма! Сезнең кебекләр бәйләнеп йөреп, Такташ ничә ел кеше арасына керә алмый. Сүгелә. «Контр» исеме алды. Җитте! Ул синең юлдан бара торган кеше түгел. Кит, комачау итмә!

А к Д у с. Татарга тылмач кирәкми. Ну, бутыйсың дөньяны! Я, бүген мине төрмәгә утыртырсың, иртәгә — аны! Берүзең калырсың әдәбият мәйданында! Шуңа омтыласыңмы?!

Кара Дус. Шантаж! Эш башындагы кешегә яла ягу! Такташ, шаһитым булырсың, ул бу сүзләре өчен дә җавап бирәчәк.

Такташ башын иеп басып тора.

Ак Дус. Их, Такташ, кайчаннан бирле үз фикереңне әйтми башладың син?

Такташ. Әйтермен... Барысын да әйтермен... Калдырыгыз мине! *(Читкә китә. Язуын дәвам итә.)*

Бакча яшьләр белән тула. Алып баручы ачык эстрада сәхнәсенә менә.

Алып баручы. Иптәшләр! Политик митингыбызны башлыйбыз. Ил кискен көрәш көннәре кичерә. Авылларда кулаклар баш калкытып чыга, шәһәрләрдә төрле яшерен политик оешмалар ачыла. Ул оешмаларның максаты — илебезнең политик нигезен какшату. Без аларга отпор бирергә тиеш! Арабыздан себереп түгәргә!

Кызганычка каршы, илдәге контр политик оешмалар эчендә татар шагыйрьләре барлыгы беленде. Аларга шигъри протест сүзен шагыйрь Һади Такташ әйтсен!

Кул чабулар.
Такташ сәхнәгә менә. Ак Дуска карап, «Син дошманым минем» шигырен укый.

СИН ДОШМАНЫМ МИНЕМ

Очраганда хәзер синең белән
Исәнләшмәм,—
Үпкәләүдән түгел бу минем,
Һич юк...
Газетада исмең күрдем синең,
Үткән көрәш юлың карадым,
Укып чыктым Үзәк комиссиянең
Синең хакта булган карарын.
Ә беләсең,

Шул ук газетада
Бер хәбәр бар,
Кыска гына итеп язылган:
Бер авылда яшь бер комсомолның
Канлы тәне кырда табылган...
Укыгансыңдыр...
Ул эшне мин синең кулың белән
Эшләнгән эш диеп карадым;
Һәркөн булып торган шундый корбаннарны
Синең корбаннардан санадым.
Чөнки,
Син, хамелеон, төсең алыштырып,
Безнең арабызда калгансың;
Кулакларны яклап һәр эшеңдә
Җимерү юлын алып баргансың.
Без көрәштә булган һәр уңышны
Йөрәк каны биреп алганда,
Мең авырлык белән, ял итмичә,
Соңгы җиңүләргә барганда,—
Син кулыңны биреп, оялмыйча
Солтангалиевтәй этләргә,
Көрәшкәнсең,
Һәрбер адымыңда
Таяк тыгып безнең эшләргә.
Без бүгеннән дошман!
Дуслыгымны саклар өчен
Йөрәгемдә бер хис тапмадым;
Бел!
Бүгеннән соң
Син һәм синең кебекләргә
Пуля саклап йөри башладым.

«Җимерү юлын алып баргансың»,— дигәндә, Ак Дус битен каплый. Такташ укып бетерә. Кул чабулар. Сәхнәдән төшә. Кара Дус килеп, кулын кыса, кочаклап ала.

Кара Дус. Молодец, Такташ! Күрсәттең кем икәнеңне! Шәп әйттең, безнеңчә әйттең.

Ак Дус *(Такташ янына килеп)*. Их, Такташ! Мин сине акыллырак дип уйлаган идем. Менә болар уйлап чыгарган уйдырма бит ул оешма дигәннәре! Шуны аңларга башың җитмәде. Хуш, Такташ! Менә хәзер син минем өчен чынлап та юк инде. Үлдең. *(Китә.)*

Кара Дус. Таралдык, җегетләр! Булдырдыгыз, молодцы! Без киттек, Такташ! Иртәгә бер әйләнерсең әле. Сиңа яңа заказ булыр. *(Китәләр. Бер читтә уйчан кыз гына кала.)*

Такташ *(башын тотып, эскәмиягә барып утыра)*. Иртәгә яңа заказ булыр... Яңа заказ... Ә миңа инде барыбер. Кая, бирегез заказларны, тагы кемне суярга, юк итәргә?! Сатарга! Ха-ха-ха! *(Утыргыч култыксасына таянып, әллә елый, әллә көлә.)* Такташ заказ белән шигырь яза! Такташ заказ белән дусларын юк итә...

Уйчан кыз *(йөгереп килеп)*. Такташ абый, сезнең хәлегез начармы әллә? Бөтенләй агарынгансыз, калтырыйсыз? *(Читкә.)* Әллә елый да инде?..

Такташ *(бераз утыргач)*. Син кем, сеңелем?

Уйчан кыз. Гөлчәһрә.

Такташ *(сикереп торып)*. Гөлчәһрә?! Син — Гөлчәһрә?! Дөньяда башка исем юкмы соң әллә, сеңелем?!

Икенче Гөлчәһрә. Белмим, Такташ абый.

Такташ. Ә син мине кайдан беләсең?

Икенче Гөлчәһрә. Сезне бөтен кеше белә бит. Мин Сезнең һәр шигырегезне, һәр мәкаләгезне укып барам.

Такташ. Ошыймы соң?

Икенче Гөлчәһрә. Ошый. Тик...

Такташ. Нәрсә, сеңелем, әйтеп бетер.

Икенче Гөлчәһрә. Тик... Өзгәләнү күп сезнең шигырьләрдә. Нигәдер, кызганам мин сезне... Юатасым, яклыйсым килә.

Такташ. Рәхмәт, сеңелем. Үзеңчә дөрес аңлагансың.

Икенче Гөлчәһрә. Такташ абый! Сезне хатыныгыз ташлап киткән, диләр. Шагыйрь кешене шулай ташлап китеп буламыни?

Такташ. Юк сүз ул, сеңелем, Мәскәүдә укый ул. Ә впрочем, белмим. Үзем дә берни белмим. Адаштым мин соңгы вакытларда...

Икенче Гөлчәһрә. Такташ абый, мин сезгә берәр ничек ярдәм итә алмыйммы соң?

Такташ. Син? Рәхмәт, сеңелем! Мин үзем дә белмим әле миңа нинди ярдәм кирәген. Рәхмәт. *(Китә.)*

Икенче Гөлчәһрә. Нинди кеше! Ә шуның башы иелгән! Күзләре гел моң гына. Ничекләр ярдәм итәргә сиңа, шагыйрь абыем? Бер генә бәхетле көнең өчен гомеремне дә җәлләмәс идем. Син генә бәхетле бул идең...

Караңгылык.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

1930 елның язы. Такташ бүлмәсе. Такташ ялгыз.

Такташ. Менә бу — минем тема булырга тиеш. Җитте, Такташ! Ничә еллар адашып йөрдең, ничә еллар бәргәләндең. Әйтер сүзең һаман әйтелмәде. Син соңгы вакытта кемнәрдер кушканга гына яза башладың. Ә менә монысы — үз сүзең. Бу шигырең үлемсез булачак, Такташ! *(Укый.)*

Сез бу хатны минем укыганда,
Мин бик күптән үлгән булырмын...
Еллар бер-бер артлы үткән булыр,
Исемем сезгә җитмәс — онытылыр...
Теләкләрем минем сезнең чорда,
Сезнең кырда чәчәк атачак.
Җансыз гәүдәм шушы теләкләргә
Азык булып җирдә ятачак...

Их! Менә бу шигырь ичмасам! Шушы рухта дәвам итәчәкмен. Бу минем киләчәккә атап язылган хатларым булыр. Аһ, шигырьләр белән генә яшәсәң иде! Менә бу тормыш ваклыклары, алдау, хыянәтләр булмаса иде...

(Өстәлдәге хатларын ала.) Менә болар барысы да синең турыда, Гөлчәһрә... Кемнәр генә, нәрсә генә язып җибәрмиләр! Ир кешегә ничек авыр икәнен белсәң иде боларны ишетүе! Аңласаң иде... *(Хат язарга утыра. Эфирда хат тексты.)*

«Гөлчәһрә!

Мин сиңа ике озын хат җибәрдем. Бәлки синең рухыңның төшкән вакытында ул хатларны җибәрмәү яхшырак булган булыр иде... Ләкин һәр очраган кешенең синең хакта кабахәт нәрсәләр сөйли һәм бөтен уйларымны чуалтып, синең алар теленә яңадан-яңа хәбәрләр бирүең мине ул хатны язарга мәҗбүр итте.

Мин бу соңгы хатым белән сине ачыктан-ачык сөйләшергә чакырырга телим.

Ни дисәң дә мин синең ирең булып саналып килдем. Бит, бер нәрсәнең дөрес булуына ышанган вакытта гына гакыллы бер карарга килергә мөмкин. Шөбһә-шик дәрәҗәле кешеләрнең дә аякларын бәйли. Бертөрле адым атларга комачаулый. Мин сине биш ел яраттым. Биш ел иң якын иптәшең булуым исеменә, синнән ачык булуыңны, мине томанлы, газаплы шөбһәләрдән коткаруыңны сорыйм... Ачык сөйләүнең беренче минуты гына авыр булыр. Ә соңыннан мин бертөрле карарга килә алырмын. Бәлки безнең гаиләнең корылышын, аерылып торуларны күзгә алып, сине гафу итәрмен. Синең белән тормышны дәвам иттерергә көчем җитәр. Бит мин консерватор түгел. Инде аерылырга дип карар итсәм дә, син ирегеңне чикләүче иреңнән генә котылырсың. Ант итәм, сиңа авыр булырлык бер генә эш тә, бер генә хәрәкәт тә ясамам.

Тормышыбызның шулай булуы синең өчен дә матурлык хәзерләми. Син университетны бетергәндә бу мәгънәдә тагын да ачыграк була аласың. Син әле икенче гаилә корып та бәхетле була алырсың. Ә минем турыда уйлама. Минем бу мәсьәләне хәл итәргә салкын канлылык җитә...» *(Озак кына битен каплап утыра.)* Нәрсә язам мин? Бу бит инде барысы да бетте, дигән сүз... Барысы да бетте...

Киләчәккә беренче хатны язган көнне үткәннәргә соңгы хатымны язам... Дөрес язаммы? Белмим... Белмим...

Ишек шакыйлар.

Керегез, ишек бикле түгел.

Икенче Гөлчәһрә керә.

Ә, сеңлем! Уз әйдә, утыр. Нинди җилләр ташлады үзеңне ялгыз шагыйрь йортына?

Икенче Гөлчәһрә. Бүген иптәшләрегезне очраткан идем. Авырып тора, диделәр. Үзегез дә күренмәдегез.

Такташ. Да, авырулар ешаеп китте шул соңгы вакытта. Узган ел да шушы вакытта баш белән клиникада яткан идем, быел да туры килер ахры. Баш сызлый, чыдарлык түгел...

Икенче Гөлчәһрә. Күп эшлисез, Такташ абый. «Чаян»да гел сезнең язмалар, журналда романыгыз басылып ята...

Такташ. Шигырьләр генә юк. Сизәсеңме, Гөлчәһрә, шигырьләр юк. Шагыйрьлек бетте.

Икенче Гөлчәһрә. Алай димәгез, Такташ абый. Сез әле әллә нәрсәләр язачаксыз! Әлегә сез арыган...

Такташ. Анысы да бар инде. Их, сеңелем, бер каракаршы утырып чәй эчәр идек — өстәлдә берни юк...

Икенче Гөлчәһрә. Борчылмагыз, Такташ абый! Мин барысын да алып килдем. Авылдан әни килгән иде — нәрсә генә юк монда *(өстәлгә бушата)*.

Такташ. Ай-яй-яй! Көн саен килсен иде ул әни, әйеме, Гөлчәһрә?

Көлешәләр. Гөлчәһрә чәй әзерли. Такташ сокланып карап тора.

Икенче Гөлчәһрә. Утырыгыз, Такташ абый.

Такташ. А, юк, сеңелем! Син минем кунагым — түремдә бул.

Кара-каршы утырып чәй эчәләр.

Такташ. Нинди хозурлык! Нинди саф тынычлык! Я, хода! Гомер буе шулай гына яшә идең...

Икенче Гөлчәһрә. Такташ абый, хатыныгыз кайтмыйммы соң әле?

Такташ. Ул... кайтмас инде, сеңелем. Шулай тоела. Ә алай да, белмим әле... Берни белмим.

Кара Дус килеп керә.

Кара Дус. Әһә! Менә Такташ! Менә мулла песие! Ай, Такташ! Кара син аны, хатыны югында Казанның икенче бер гүзәле белән кара-каршы чәй эчеп утыра бит! Ха-ха-ха!

Гөлчәһрә, уңайсызланып, чыгарга бара.

Такташ. Тукта, сеңелем. Табынны алай ташлап китмиләр. Шагыйрь абыең шаярта гына ул.

Кара Дус. Әлбәттә, шаярттым гына. Такташка да бер бәйрәм кирәк бит инде... Такташ! Эш белән килгәнием. Сине киләсе җәйгә Донбасс якларына җибәрәбез. Шахтерлар тормышыннан яңа әсәрләр алып кайтырга! Күрсәт әле үзеңнең кемлегеңне, кайсы якта икәнеңне.

Такташ. Сез һаман шикләнәсезмени әле? Инде сезнең заказ буенча гына язам бит! Ура! кычкырып язам.

Күп заводлар безнең күптән инде
Планнарны тутырып ташлады,
Алгы өчен эшли башлады!
Кызыл байрак алып җиңеп чыккан
Эшче полклар һаман арталар,
Артып тора кызыл такталар.

Я, шигырьме бу? Мин — Такташ — шуны язам! Син мактый-мактый бастың. Я, сеңелем, әйбәт шигырьме бу?

Икенче Гөлчәһрә. Мин шигырьне бик үк аңлап бетермим...

Такташ. Аңлыйсың... Яхшысын тиз аңлыйсың. Ә монысын мине кызганганга гына әйтмисең.

Кара Дус. Я, беттеме? Кызып алмасаң, Такташ булмый калырсың. Соң, башкача яза алмагач, шунысына риза буласың инде.

Такташ. А, юк... Күмеп куярга ашыкмагыз әле! Язам! Яздым! Менә тыңла:

Сез бу хатны минем укыганда,
Авыр еллар үткән булырлар;
Җирдә коммунизм булган булыр,
Безнең дәвер халкы онытылыр...
Безнең хисләр сездә кабатланмас,
Сез ул хисләр белән янмассыз,—
Безнең бөек чорның каршылыклы
Кешеләрен аңлый алмассыз.
Без — үткәннең каты җиңелүе,
Бүгенгенең җиңеп килүе
Көрәшендә
Артык ашкынулы
Хисләр уты белән янабыз;
Без яңа җир,
Яңа кеше өчен
Җирдә зур дау алып барабыз...

Кара Дус *(бүлдереп)*. Юк! Юк!! Юк!!! Мондый шигырь булмый. Болай дәвам итсәң, тагы провалга очраячаксың... Юк, юк, мондый шигырь булмый.

Такташ. Нинди була соң? Мин сине аңламый башладым, дус. Кешеләр өчен сөенә белмисең син. Их, Ак Дус булса! Аңлар иде ул минем бу шигырьне...

Кара Дус. Юк ул салам сыйрак! Бетте. Төрмәдә утыра. Син неужели үзеңне кемнәр алып калганын хәтерләмисең?

Такташ. Хәтерлим... Син аны онытырга ирек бирәсеңме соң?..

Кара Дус. Менә, ит яхшылык, көт явызлык шушы була инде ул. Мин тагы сине сөендерергә дип килдем...

Такташ. Я, дус, үпкәләмә. Соңгы вакытта кәеф китеп тора, шуңа гына ул...

Кара Дус. Хәзер кәефеңне күтәрәм, алайса. Киләсе елга синең әсәрләреңнең тулы җыентыгын чыгара башлыйбыз. Беренче томга әйберләреңне әзерлә.

Такташ. Дустым! *(Кочаклап ала.)* Син бит мине коткарасың! Бурычларымнан да, ачлы-туклы яшәүдән дә... Барысын да әзерлим, барысын да...

Кара Дус. Барысын да әзерлә. Тик кечкенә генә бер кереш сүзең кирәк булачак.

Такташ. Язабыз! Зурысын да, кечкенәсен дә язабыз, дус! Их, син булмасаң, нишләр идем мин?!

Кара Дус. Үзең беләсең, соңгы вакытта сиңа теш кайраучылар күп. Шуңа күрә кереш сүзне бик чамалап язарга кирәк. Без анда уйлаштык — син беренче чор шигырьләреңнән публично ваз кичәргә тиеш.

Такташ. Тукта, ничек була соң әле ул? Үзең чыгарырга, дисең, үзең — ваз кичәргә?.. Ваз кичәрлек булгач, чыгармаска гына кирәк аларны.

Кара Дус. Чыгарырга кирәк. Гыйбрәт өчен. Сабак өчен.

Такташ. Әһе, шагыйрь Такташ кем иде — кем булды? Аңлашыла башлады...

Кара Дус. Аңлашылса, шул. Башта үзеңнең вак буржуа шагыйре икәнеңне әйтәсең, ничә еллар черек идеология белән иҗат иткәнеңне әйтәсең. Аннан ничек итеп безнең сине тәрбияләвебезне әйтәсең. Әйе, гаҗәпләнмә, без, тәрбияләп, сине шагыйрь иттек. Һәм син шуны халыкка әйтергә тиеш.

Такташ. Юк, мин риза түгел! Мин беркайчан да вак буржуа булмадым! Минем идеологиям, иманым дөрес иде. Минем беренче чор шигырьләрем — иң яхшы шигырьләрем! Аларда мин — Шагыйрь, ә боларда...

Кара Дус. Мин сиңа файда булсын өчен әйткән идем. Үзеңә мөнәсәбәтне беләсең. Заманның нинди икәнен дә беләсең. Үзең чамаларга тиеш идең. Анда синең исемне ишетергә дә теләмиләр. Кермәгән ишегем калмады. Сиңа ышаныч юк, Такташ.

Такташ. Ә нигә юк? Уйлый белгән өченме? Ә нигә миңа гына шундый шартлар? Берегезне дә болай газапламыйлар бит! Нигә миндә генә шушындый кыенлыклар, каршылыклар?! Нигә, сеңелем?!

Икенче Гөлчәһрә. Чөнки сез талантлы, Такташ абый. Сезне талантыгыз өчен яратмыйлар.

Такташ. Сеңелем... Күзләрең акыллы синең. Сакларга иде сине... *(Кара Дуска.)* Мин уйлармын, дус, уйлармын...

Ишектә Беренче Гөлчәһрә күренә.

Беренче Гөлчәһрә. Каршы алучы да юк! Астан күпме кычкырдым, тәрәзәгә таш аттым! Ну, Такташ! Син хатларың белән бирәсең минем кирәкне! Җавабын бирергә үзем кайттым! *(Кочагына ташлана.)*

Такташ *(читкә этәреп)*. Ашыкма, Гөлчәһрә, кешеләр бар.

Беренче Гөлчәһрә. Шулаймыни?! Исәнмесез һәм сау булыгыз! Мине чабаталы даһием белән калдырыгыз.

Такташ. Гөлчәһрә, әдәпсезләнмә. Болар минем иң якын дусларым.

Беренче Гөлчәһрә. Аһ, шулаймыни?! *(Кара Дуска.)* Монысын күптән беләм. Курыкма, курыкма, бу юлы пистолетым юк. Алай да, Такташ аңламаган икән әле сине... *(Икенче Гөлчәһрәгә.)* Ә син кем буласың, чибәр кыз?

Икенче Гөлчәһрә. Гөлчәһрә.

Беренче Гөлчәһрә. Гөлчәһрә?! Мин дә Гөлчәһрә бит! Аһ бу Такташның зәвыгы! Хатлар аша мине тиргәп яткан була тагы.

Такташ. Гөлчәһрә, ул турыда сөйләшмибез.

Беренче Гөлчәһрә. Ә нигә сөйләшмәскә? Безнең турыда инде бөтен дөнья әлләниләр сөйли... Мин сине алырга кайттым, Такташ.

Такташ. Алырга?! Кайда?!

Беренче Гөлчәһрә. Мин университетны тәмамладым бит, Такташ җаным! Бүгенге көннән мин — югары

белемле юрист! Менә диплом! Кайсы якка китсәк тә — дөнья безнеке! Бергә китәбез! Телисеңме, Кырымга, Кавказга, Урта Азиягә?! Тик Казан гына түгел!

Кара Дус *(мыскыллап)*. Бар, бар, Такташ, прокурор хатыны булып яшәрсең. Шигырь язып тамак туйдырмассың.

Икенче Гөлчәһрә. Китмәгез, Такташ абый!

Такташ. Җитте. Юк сүз сөйләмә, Гөлчәһрә. Мин — татар шагыйре, ир кеше. Синең арттан китә алмыйм мин. Тем более, Казаннан. Син моны яхшы аңларга тиеш идең.

Беренче Гөлчәһрә. Бөтен тормышыбызны агулаячак бит алар! Күралмыйм мин аларны. Күпме гайбәт ишетәсең монда!..

Кара Дус. Намусың чиста булса, ишетмәс идең!

Беренче Гөлчәһрә. Син! Кара җан! Кызганыч, пистолет юк. Ике дә уйламый, маңгаеңа пуля утыртыр идем. Һади! Син миңа шушы бәндәдән шундый сүзләр әйттереп торасыңмы?

Такташ дәшми.

Ник эндәшмисең?!

Такташ дәшми.

Син дә миңа ышанмыйсыңмы? Нигә эндәшмисең, Һади?! Ярар, син килмәсәң, мин китәм. Мин синең бу ачулы дөньяңда кала алмыйм. *(Әйберләрен җыя башлый. Икенче Гөлчәһрәгә.)* Чибәр кыз! Кил әле бире! *(Гөлчәһрә килә.)* Син Такташны яратасыңмы? *(Гөлчәһрә дәшми.)* Уңайсызланма, әйт. Минем өчен бу бик мөһим.

Икенче Гөлчәһрә *(пышылдап)*. Яратам...

Беренче Гөлчәһрә. Бик яратасыңмы?

Икенче Гөлчәһрә. Бик...

Беренче Гөлчәһрә. Барыбер минем кебек яратмыйсың!!! Ләкин минем аның каршында ышанычым югалды! Мин горур, Такташ. Мин синең шикләнүләреңне күтәрә алмыйм. Аягыма егылганда гына кичерермен мин сине.

Икенче Гөлчәһрә. Такташ аякка егыла торган кеше түгел.

Беренче Гөлчәһрә. Нәрсә дидең?! Син... син шактый дөрес аңлагансың аны. Бәхетле ит үзен! Хуш, Такташ!

Икенче Гөлчәһрә. Китмәгез! Мин китәм, сез калыгыз.

Беренче Гөлчәһрә. Бәхетеңә аркылы төшмә, сеңелем! Такташны сакла! *(Чыгарга бара.)*

Такташ. Гөлчәһрә, тукта әле! Ашыкма! *(Омтыла.)*

Кара Дус *(Такташның кулыннан тота.)* Ир бул! Җебемә! Киткән хатын артыннан чапмыйлар.

Беренче Гөлчәһрә. Дөрес, Кара Шагыйрь! Тот Такташны! Тотынырга янында башка кешесе калмады аның. *(Китә.)*

Кара Дус. Менә шәп булды! Котылдың. Борчылма, Такташ. Донбасска җибәрәбез үзеңне! Пролетариат турында язарсың! Төкер бу мещан хатынына.

Такташ. Кирәкми, дус... Берни әйтмә... Әллә нәрсә сынды... Җимерелде... Бетте...

Кара Дус. Ярый, ярый, мин киттем. Әйтәсен әйттем. *(Китә.)*

Икенче Гөлчәһрә. Әллә ничек килеп чыкты... Без монда булмасак, бәлки хатыныгыз китмәс тә иде... Аңлашыр идегез...

Такташ. Китәр иде, сеңелем... Син аны белмисең... Бәлки ул инде миннән күптән киткән булгандыр...

Икенче Гөлчәһрә. Мин дә китим инде, Такташ абый...

Такташ. Бераз гына утыр әле, сеңелем... Син дә китсәң, бу дөньяда бөтенләй ялгыз калам бит мин. Бераз гына утыр әле.

Янәшә утырып калалар.
Караңгылык.

СОҢГЫ КҮРЕНЕШ

Бүлмә бераз яктыра. 1931 ел. Декабрь. Такташ баш күтәрми язып утыра. Икенче Гөлчәһрә әкрен генә керең-чыгып йөри. Менә ул теге яктан яшь бала күтәреп чыга, аны караватка сала. Кинәт тәрәзәдән җил-давыл бәреп керә дә, Такташның бөтен язганнарын туздырып ташлый. Яшь бала елап җибәрә. Такташ бар көченә гаилә-караватын югарыга этеп алып менә башлый. Туктап, сулыш алган вакытларда, тезенә кәгазен куеп яза. Язган берен давыл очыра бара. Инде Такташ тормышының түбәсенә менеп җиттем, дигәндә генә, кинәт башын тотып егыла... Моңарчы куркып бер читтә торган Икенче Гөлчәһрә йөгереп янына бара.

Икенче Гөлчәһрә. Һади, бәгърем, нишләдең?!

Такташ *(торырга итеп)*. Менеп җитеп булмады, канәтым... Менеп җитеп булмады... *(Егыла.)*

Икенче Гөлчәһрә. Һади!!! Ярдәм итегез, Һади үлә! Ярдәм итегез!

Ишектә Кара Дус күренә.

Кара Дус. Нәрсә булды?

Икенче Гөлчәһрә. Һади үлә... Башын тотып егылды.

Кара Дус. Үлә?! *(Такташ янына килә башлый.)*

Икенче Гөлчәһрә. Тик, зинһар, борчый күрмәгез. Бәхәсләшә күрмәгез. Башы бит... Мин врачка гына барып килэм. *(Китә.)*

Кара Дус *(читкә)*. Ниһаять. Сынды. Такташ үлә... Ничә еллар минем даныма, талантыма аркылы ятты ул! Халыкның күзен томалады. Менә хәзер карарбыз, халык кемне укыр?! *(Такташ янына килә.)* Нихәл, Такташ? Нигә болай ятасың әле? Килешми сиңа, килешми...

Такташ. Киләчәккә... хатларым язылып бетмәде. Чакыр Ак Дусны, алсын язылып беткәнен...

Кара Дус *(читкә)*. Һаман Ак Дус?! Үлгәндә дә миңа түгел, аңа тапшыра!!! *(Такташка.)* Ак Дустың бөтен Казан буенча синең китапны мыскыллап йөри. «Такташ социализм койрыгына ябышып шагыйрь булмакчы!» — дип сөйләп йөри.

Такташ. Дөрес мыскыллый. Ул кереш сүз белән мин үз-үземә... соңгы хөкем чыгардым...

Кара Дус. Ну үзең дә арттырып җибәргәнсең инде. Вак буржуа икәненне дә әйткәнсең. Черек икәненне дә! *(Китапны ала. Укый.)* «Шулай итеп, бу том белән үткәннәргә ишекләрне ябып, социализм экономикасы ачып килгән яңа ишекләр алдына миллионнар белән бергә яңа, бөек теләкләр белән килеп басам». Ха-ха-ха! Ятам диген. *(Иелеп.)* Ишек төбендә сузылып ятам, кертмиләр, диген.

Такташ *(аягүрә торып баса)*. Басып торам!!! Киләчәк каршында аягүрә басып торам! *(Чайкалып, өстенә килә башлый.)* Ә син... мине үтердем дип сөенмә... үтерә алмыйсың... Шигырьләрем кала... Такташ дигән исемем кала... Синнән ни кала?! *(Өстенә килә. Кара Дус ишекнең теге ягына чыгып кача да ишекне арты белән тери.)* Үз-үземнән ваз кичтем... Шигырьләремнән ваз кичәргә мәҗбүр булдым... Киләчәктә дөрес аңларлармы? Иң кадерле кешеләремне... саттым... Гөлчәһрә... Гадел дустым... Кайда сез?.. Ачыгыз бу тимер ишекләрне! Ачыгыз...

Такташ тимер ишеккә барып каплана. Югарыда, ак каеннар арасында, бер ир баланың йөгереп килгәне күренә. Ул — Такташның бала чагы. Менә ул йөгереп килә дә, күкрәге белән зур тимер ишеккә барып бәрелә. Әкрен генә җиргә чүгә башлый. Бу вакытта Такташ та тимер ишек буенча әкрен генә аска шуып төшә. Еракта сабый бала елап җибәрә. Бу — Такташның үлеме.

Ишекнең бу ягы.

Ашыгып, Ак Дусның килгәне күренә. Ул ишеккә арты белән сөялгән Кара Дус янына килеп җитә. Аны күргәч, Кара Дус ишеккә аркылы баса.

Ак Дус. Кит юлдан! Такташның хәле авыр дип ишеттем. Мин аны күрергә тиеш.

Кара Дус. Сиңа анда керергә ярамый? Сиңа аның янына юл юк! Син аның дошманы!

Ак Дус. Кем аркасында?! Кит юлдан, кара җан!!! *(Бугазыннан алып, ишектән читкә алып китә.)*

Ул арада Икенче Гөлчәһрә йөгереп кайта. Ишекнең теге ягына кереп китә. Аның ачыргаланып кычкырып җибәргәне ишетелә. Икенче Гөлчәһрә атылып бу якка чыга. Ике Дус та, ашыгып, ишек янына киләләр.

Икенче Гөлчәһрә. Такташ үлгән... Такташ үлгән... Ишекләрен япкан... Мәңгегә... Барыгыз да... Китегез... Сез генә үтердегез аны... Йөрәгенә басып җырлаттыгыз... Сез генә үтердегез. Саклый алмадым каралыктан... Өлгермәдем...

Елап, ишек төбенә сыгылып төшә. Ике дус, башларын иеп, икесе ике якка чыгып китәләр.

Пәрдә төшә.

САНДУГАЧНЫҢ БАЛАЛАРЫ...

Драма 6 күренештә

Әфганстанда кан койган якташларыма — татар егетләренә багышлыйм бу әсәремне.

КАТНАШАЛАР:

Сандугач — ике бала анасы.
Габделхәй — аның ире.
Илһам — олы уллары.
Зиннәт — кече уллары.
Роза — укытучы кыз.
Бәкер — авыл советы председателе.
Авыл халкы, авыл яшьләре,
милиция работнигы, военком,
Политик эшлекләләр.

Вакыйга 80 нче елларда татар авылында бара.

Пәрдә ачыла. Эчке пәрдәгә дөнья картасы ясалган. Берничә нокта ут кебек янып тора. Бигрәк тә Көнчыгыш илләрендә, Әфганстанда ут көчле. Өстә, уен барасы мәйданнан өстә, бер-берсенә каршы ике Политик эшлекле утырган. Алларында — шахмат тактасы. Абстракт ил (Развивающаяся страна) вәкиле безгә бераз яны белән утырган. Тамашачыга каршы утырганы — безнең ил вәкиле (анда Брежнев төсмерләрен күрергә була). Алар калку урында утыралар. Шахмат фигуралары да гадәттән тыш зурлар. Уен бара. Эфирда сөйләшү.

Абстракт ил вәкиле. Тагы бер партия, Брежнев әфәнде.

Брежнев. Рәхим итегез, Советлар Союзының анлык кына рәте бар. Онытмагыз, безнең ил дөньяда иң бай, иң көчле, иң гадел, иң, иң, иң, иң ил.

Абстракт ил вәкиле. Солдатларыгызга куркыныч, иптәш Брежнев. Без аларны үзебездә янган ут астына кертергә мәҗбүрбез. Уенның тәртибе шундый.

Шартлау, сугыш тавышлары.

Брежнев. Безнең солдатлар иң көчле, иң батыр, үлемгә иң әзер солдатлар.

Абстракт ил вәкиле. Солдатларыгызны юлдан алып ташларга туры килә, Брежнев әфәнде.

Шартлау, сугыш тавышлары.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Авыл яшьләренең кичке уен урыны. Май башы. Бер төркем егетне армиягә озаталар. Егетләр җырлап әрәмә буйларын әйләнәләр. Яшьләр арасында кызлар да бар.

Без урамнан үткән чакта
Күтәрелде томаннар,
Дөнья хәлен белеп булмый,
Сау булыгыз, туганнар.
Утырдым вагон читенә,
Киттем Әфган иленә шул.
Әфган илләре ком да таш,
Ниләр күрер газиз баш...

Озату яшьләренең кичке уены белән кушылып китә. Бәкер белән Роза керәләр. Карап торалар.

Роза. Тагы китәләр... Авылга инде ничә табут кайтты. Һаман китәләр...

Бәкер. Ир-атның эше шул инде аның, сеңелем. Без, ил кайда куя, шунда булырга тиеш. Чөнки безнең ил иң-иң көчле, иң-иң гадел, иң-иң бай ил...

Роза. Ярар, Бәкер абый... Арыдым мин. Без монда үзешчән сәнгать аркасында килдек бит. Менә безнең авылның үзешчән сәнгате шушы инде.

Бәкер. Бик дан түгел икән шул... И-и, без яшь чакта... Тау битенә генә сыймыйча, әрәмәләргә төшеп китә торган идек. Берьюлы биш-алты урында бара торган иде уен...

Роза. Без яшь чакта көзгеләр матур итеп күрсәтә торган иде, дигән бер карчык та...

Бәкер. Син безнең авылныкы түгел шул... Хәтерләмисең ул чакларны... Егетләре дә әллә ниткән пешмәгәннәр. Кара инде эленке-салынкы биюләрен! Татар егетләре шундый буламы инде? Боларны ничек оештырып районга җибәрергә инде?

Роза. Кирәк, Бәкер абый, бер-ике номер булса да оештырып җибәрергә кирәк. Аның иң асыллары армиягә китә бит... Сездән әйтү булсын, калганын мин үзем карармын.

Бәкер. Авыл советына да бик исләре китми хәзер. Менә колхоз председателе әйтсә ичмаса... Акчасы да аның кулында, тегесе-монысы да...

Роза. Чәчү бетмәгән. Кул гына селтәде. «Такмак әйтеп торырга кирәкмиме тагы?» — ди. Ничек чыгып киткәнемне дә белмәдем.

Бәкер. Ул шулай... тәртип булмаса — авыл советы гаепле. Берәрсе асылынып үлсә — авыл советы гаепле. Инде мактарга дисәләр — что син! — колхоз председателе күкрәк киереп алга чыгып баса. Ул шулай...

Роза. Барып, бер-ике сикереп кайтырбыз инде. Шушы уенны булса да күрсәтербез. Уен җырлары модада хәзер. Их, Илһам булса!..

Бәкер. Тс-с-с! Илһамны телгә алма инде син. Юк Илһам. Кайда икәне дә билгесез.

Р о з а. Солдатка киткән җиреннән кеше юкка чыксын инде... Хәзерге заманда... Сугыш түгел, ни түгел — ә кеше юк.

Б ә к е р. Алай түгел ул, сеңелем... Солдат өчен һәрвакыт сугыш. Бигрәк тә — Әфганда. Илһамның кайда эләккәнен белдек бит.

Р о з а. Кайтыр вакыты килеп җиткәч кенә бит. Былтыр бу вакытта кайта иде бит инде ул... исән булса...

Б ә к е р. Исәнлеген-үлгәнлеген белгән кеше юк. Военкомат ул сиңа шутка түгел. Аларның — секрет. Хәбәрсез югалды и все тут. Әфган ягына чыкканмы, плен төшкәнме, качканмы — беркем белми.

Р о з а. Сез бигрәк инде, Бәкер абый — «качканмы», «чыкканмы». Кайтыр вакыты җиткәндә Илһам нигә андый башсызлык эшләсен. Монда ата-анасы, туганнары көтә... Мин көтәм...

Б ә к е р. Хәзерге яшьләрне белмәссең. Чит ил тормышына кызыгырга мөмкин. Ә нәрсә? Әнә күпме качалар бит. Мин авыл советы. Минем эшем — тикшерү, күзәтү, җәвит итү... Авылда күренү белән тотып бирү.

Р о з а. Сез бигрәк инде, Бәкер абый. Кеше турында гел начар гына уйлап торасыз икән.

Б ә к е р. Эшем шундый. Син аның йөргән кызы, шуңа күрә гел яхшыны гына уйлап тор, яме. Ә без службада! Это не шутка сиңа.

Сандугач керә. Ул биләүсәгә баласыман нидер төргән.
Яшьләр янына утә, алар арасыннан кемнедер эзли.

Р о з а. Сандугач апа тагын монда килгән! Көн саен шушында килә. Үләм! *(Битен каплый.)*

Б ә к е р. Бөтенләй җиңеләйгән, бичара. Нинди хатын иде бит, әй! Тирә-якка данлыклы Сандугач иде. Ул моң, ул гәүдә, ул хыялыйлыклары дисеңме... Кайгы бетерә кешене...

Р о з а *(Сандугачны алып килеп)*. Сандугач апа, Илһам юк монда, юк. Кайтмаган әле Илһам...

Сандугач. Кайтмагандыр шул... Кайтса, өйгә керми калмас иде... Менә, гармун тавышын ишеттем дә, йөгердем әле. Баланы чак төреп өлгердем.

Бәкер. Нинди бала күтәреп йөрисең соң син, Сандугач? *(Барып карый.)* Я, хода! Утын тумраны тоткан!

Сандугач. Белмәгән кебек кыланма инде, Бәкер. Илһамның улы бит бу. Яңа туды. Менә әтисе дә юк, әнисе дә. *(Розага.)* Бәрәч, әнисе син булырга тиеш идең бит аның. Нишләп өйгә кайтмыйсың, кызым? Балаң елый да елый, елый да елый...

Роза *(үксеп)*. Сандугач апа! Бир үземә, бир, утын тумраны булса да бир. Илһамның улы дип тәрбияләрмен. Безгә утын тумраннарын назларга гына калгандыр инде!

Бәкер. Үзеңне кулга ал, Роза! Укытучы кеше бит син! Нигә авыл хатыннары кебек кыланасың. Сандугачка килешә ул. Аңа ут та юк, суд та. Ул — җүләр.

Сандугач. Нишләп җүләр булыйм ди мин? Мин барысын да беләм. Улымның патша хезмәтендә икәнен дә беләм. Егерме биш ел хезмәт итәсен дә беләм. Аны сез генә хәбәрсез югалды, дип йөрисез бит. Ә мин — беләм! Ул патшага хезмәт итә.

Бәкер. Бу контр сүзләр дә ычкындырып ташлый икән. Моның белән бәлале булырсың. Патша хезмәте, ди бит. Кара син аны, җүләр генә димәссең.

Сандугач *(Розага)*. Син дә җылама, нәнәм. Хәзер мин сиңа җыр җырлыйм. Мин аны Илһамыма атап чыгардым. Әле Илһам кечкенә иде, шулай бервакыт йөгереп кайткан. Кулында — сандугач баласы. Үлгән. Оясыннан егылып төшкәндер инде. Әй Илһам елый, әй елый. «Әни, син дә сандугач бит, ди, мин дә синең балаң бит, ди, мине дә шулай үтерерләрме икән», — ди. Менә шуңа җыру чыгардым әле, тыңлагыз әле. *(Җырлый.)*

Сандугачның, мескенкәйнең, баласын үтергәннәр.
Баласын үтерәбез дип, анасын үтергәннәр.
Белмәгәннәр аткан укның анасына тиясен.
Белмәгәннәр бала белән анасы да үләсен.

Сандугачның балалары
Ике була, өч була.
Кайларга гына барсаң да
Таң ата да кич була.

Менә мине алып барыгыз районга, мин матур жырлыйм бит, иеме, Бәкер? *(Жырлый.)* Сандугачның балалары
Ике була, өч була...

Зиннәт йөгереп керә.

Зиннәт. Әни! Әни, өйгә кайтыйк! Әни, жырлама! Жырлама, әни!

Сандугач һаман жырлый.

Бәкер абый, Роза апа, әйтегез әле, жырламасын.

Бәкер. Нишләп, матур жырлый бит. Жырласын.

Сандугач. Мин әле бии дә беләм. Биимме, Бәкер?

Бәкер. Бие, Сандугач! Бие! *(Такмак әйтә.)*

Роза *(Сандугачка барып асылына)*. Сандугач апа! Әнә Зиннәт килгән. Әйдә, өйгә кайтыйк, Сандугач апа... Илһамнан берәр хәбәр юк микән?

Сандугач. Әйе шул. Озак тордым. Бала кайда соң әле?

Роза *(утын тумраның тартып алып)*. Менә, Сандугач апа. Әйдә кайтыйк.

Сандугач. Әйдә, улым! Минем Зиннәт улым бар бит әле. Зиннәтле улым. Минем балаларым зиннәтле, кыйммәтле, дөньяда берләр.

Зиннәт белән Сандугач китәләр. Яшьләр дә тарала.

Бәкер. Яшьләрне куркытты бу Сандугач. Жүләр, жүләр шул инде.

Роза. Үзегез бит — жырла да жырла, бие дә бие... Аңламый бит инде ул. Нигә аны алай мыскыл итәсез?

Бәкер. Итәрсең аларны мыскыл... Алардагы мин-минлек... Без инде урында утырабыз — безгә шәбәергә дә була. Алар кем инде? Ә шуңа карамый баш нинди текә, ә?

Караш нинди? Алар гомер буе шундый булдылар. Нәселләренә бәйләнмәвең хәерле. Авылда җегет бетмәгән.

Роза. Мин соңрак кайтам, Бәкер абый. Кайта торыгыз.

Бәкер. Әйе, үзеңә кара. Иртәгә кичкә клубка җый бу салам сыйракларны. Бөтенесен куарбыз да чыгарырбыз сәхнәгә. Нәрәд белән. Нибуч, чыгарлар. *(Китә.)*

Роза. Туйдым. Нинди авыл бу? Авылмы соң бу? Нигә кешеләр шулай берсен-берсе күралмыйлар? Нигә кеше кайгысына сөенәләр? Кайда чакырып китердең син мине, Илһам? Үзең кайда син?.. Бер генә күрен күзләремә?!.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнә караңгыланып ала. Шул ук әрәмә буе, кичке як. Розаны җитәкләп, Илһам керә.

Илһам. Безнең авыл менә шушыннан башлана инде, Роза. Әни әти белән шушында очрашкан, без шушында үстек. Сине дә шушында алып килдем.

Роза. Матур урын. Такыраеп кына беткән.

Илһам *(көлә)*. Биегәннән ул. Монда ничә гасыр инде яшьләр кичке уен биләр. Менә күрерсең әле! Ул безнең авылдагы уен көйләре! Башка бер җирдә юк андый көйләр!

Роза. Сезнең авылда гына инде! Бары тик сезнең авылда гына!

Илһам. Чын, Роза! Көлмә. Мин сиңа моны музыкант буларак әйтәм.

Роза. Диплом алганыңа бер көн — инде музыкант! Ашыгасың, Илһам!

Илһам. Вакыт ашыктыра, Роза гөлем! Мин бит диплом да алдым, армиягә китәргә повестка да.

Роза. Повестканы да үзең ашыктырдың, дипломын да. Үзең теләп Әфганстанга китәргә сине берәү дә мәҗбүриләми...

Илһам. Мәҗбүриләми... Безнең группадан кайбер егетләр анда эләкмәс өчен, беләсеңме, ни генә эшләмәделәр? Хәер, анысы сиңа кирәкми инде. Мин дә китмәсәм, башка да китмәсә... Армия хезмәте бит инде ул.

Роза. Ә мин берни дә әйтмим. Мин сиңа берни дә булмасын беләм. Ил-һам бит син... Җыр бит син...

Илһам. Көтәрсеңме, Роза?

Роза. Менә, авылыңа кайтарып куйдың бит инде. Тау арасына. Моннан кая китә алыйм инде мин?

Илһам. Их, килен итеп алып кайта алмадым бит үзеңне! Вакыт! Әти-әни янында да бер көн куна алмыйм. Бүген кичкә үк военкоматта булырга кирәк. Синең белән туй алай ашык-пошык кына булырга тиеш түгел, Роза гөлем! Атылып барам хезмәткә, атылып кайтам, син көт кенә!

Роза. Беләсеңме, Илһам... Мин көтәрмен... Мин гомер буе да көтәрмен. Ләкин синдәге кебек шашкын хисләр юк бугай әле алар миндә. Уянып өлгермәгән әле... Миңа синең белән рәхәт, бик рәхәт... Тыныч. Ярату әллә шушымы икән инде?

Илһам. Роза гөлем! Бала шул әле син. Гөнаһсыз сабыем. Синең әле яратып караганың да юк. Ләкин син мине яратачаксың, Роза гөлем! Һичшиксез, яратачаксың. Эшкә урнашырсың, көтәрсең.

Роза. Миңа училище белеме белән башлангычларны гына бирерләр инде.

Илһам. Әле минем энекәш тә тугызга бара быел. Мин аңа әйтеп калдырыйм әле, күз-колак булыр үзеңә.

Роза. Син бигрәк инде... Минем укытучы кеше икәнне онытма!

Илһам. Их, син, бер атналык укытучы! Диплом алганыңа кайчан әле?

Роза. Бер атна.

Илһам. Шул-шул менә... Их, Роза гөлем, дөньяда бездән бәхетле кеше булмас әле! Шушы тау битләрендә безнең балаларыбыз йөгерешеп йөрер. Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү...

Роза *(бүлдереп)*. Тукта, бик күп санадың түгелме? Алары безнекеләр түгел бугай?

Илһам. Безнекеләр. Алтау, җидәү, сигез, тугыз, ун! Ун бала! Барысы да безнеке!

Роза. Ун бала? Дөрес санадыңмы, Илһам? *(Аңа сыена.)*

Илһам. Дөрес, бәгърем! Унберенчесе — син, бантиклы сабыем. Ә мин сиңа атап җыр чыгардым, Роза.

Роза. Әйтми дә...

Илһам. Нәкъ шушында җырларга уйладым. Бу таулардан, әрәмәләрдән башка җырның моңы булмас иде. *(Гитарасын алып, әкрен генә җырлый башлый.)*

Таш каланың ташлы туфрагында
Син гөлемне күрдем,
«Минем гөлем!» — дидем.
Күнелеңдәге нурны, мәрхәмәтне
Бер карауда сиздем,
Бер карауда сиздем.
«Бу дөньяның бөтен гүзәллеген
Аңа бирәм!» — дидем.
Ул бит — минем тиңем!
Ул бит — минем тиңем, бердәнберем,
Мәңгелегем, дидем,
Мәңгелегем, дидем.

Йөгереп Сандугач керә.

Сандугач. Ышанмаган идем! Илһам бер кызны җитәкләп, тау битеннән кайтып килә, дигәч, ышанмаган идем! Тавышыңны таныдым! Улым! *(Килеп кочаклый.)*

Илһам. Әни! Өйгә кайта идем инде. Менә, таныш бул, әни — Роза.

Сандугач. Әллә киленемме? Нихәл, балам?

Роза. Юк-юк, апа... Мин килен түгел, мин — укытучы.

Илһам. Булачак киленең, әни. Менә армиядән кайтуга, шаулатып туй ясарбыз.

Сандугач. Әле бу яз алмыйлардыр бит, улым? Укып бетергәч дигән идең бит?

Илһам. Укулар бетте, әни. Бер кулда — диплом, икенчесендә — повестка.

Сандугач. Ничек, повестка? Кайчанга?

Илһам. Син, әни, борчылма инде. Үзең әйтә идең бит, ир бала солдат хезмәтен үтәргә тиеш дип. Менә, безгә дә җитте чират.

Сандугач. Кайчан?

Роза. Бүген кичкә военкоматта булырга тиеш ул. Әле сорап кына китте. Сезнең белән хушлашырга, дип кенә.

Сандугач. Бүген кичкә? Солдатка шулай китәләрмени, улым? Нәрсә була инде бу? Атаң да һаман алып кайтмый көтүен...

Илһам. Мин махсус шулай эшләдем, әни. Шау-шу ясамыйча гына китәргә дә, ике елдан әйләнеп кайтырга! Белми дә калырлар иде авылда.

Сандугач. И, улым, алай гына буламыни инде ул?.. Армия хезмәте бит ул... Ялгышрак иткәнсең шул, бала... Әнә Зиннәт тә болайга таба йөгерә. Тизрәк атаңны алып кайтсын ичмаса.

Йөгереп Зиннәт керә. Розаны күреп, катып кала.

Улым, күреш тә, тиз генә атаңны алып кайтырга йөгер. Әнә абыең армиягә китә икән бүген. И, улым, улым.

Зиннәт *(Роза янына килеп)*. Исәнмесез. Зиннәт булам.

Роза. Ә мин — Роза. Сиңа Роза апа булам.

Зиннәт. Абый, исәнме? *(Күрешәләр.)* Әфганстанга укмы әллә? Анда шулай ашыгыч җыялар икән.

Илһам. Шулайрак, энем. Син күп шаулама инде, яме.

Зиннәт. Үзең теләп?

Илһам. Үзем теләп.

Сандугач. Әфганстанга?! Үзең теләп?! Ай, балам, нигә шулай ашыктың?

Илһам. Хезмәт — кайда да хезмәт инде ул, әни. Аннан фаҗига ясарга кирәкми.

Сандугач. Йөрәк-бавырларым өзелеп төште. *(Утыра.)* Аякларымның хәле бетте. Бар, улым, атаңны чакырт тизрәк.

Илһам. Энекәш! Матайны да карый тор. Илтеп ташларсың шәһәргә.

Сандугач. И, бала... Кем солдатка шулай китә инде. Мәҗлес ясап озатыр идек. Аның йоласы шул бит.

Илһам. Мин китәрмен дә, кайтырмын да, әни. Менә сез монда Розага ярдәм итегез. Роза, торуын, бәлки, бездә генә торырсың?

Роза. Юк, юк, алай килешми. Берәр әбигә генә керермен.

Сандугач. Анысы, торырга урын табылыр. Син борчылма, балам. Безнең авыл халкы әйбәт, киң күңелле. И, алла, яшьләр уенга да җыела башладылар. Кайтыйк, балалар. Бер чынаяк булса да чәй эчеп китәрсең.

Илһам. Болай булгач, бер биемичә киттем юк инде, әни. Анда әллә биеп була татарча, әллә юк! Уйна әле, яшьти!

Уртага чыгып, җилкенеп бии башлый. Розаны чакыра. Парлап биләр. Яшьләр аларга атап җыр җырлыйлар.

Аякларың бик чылаган
Агыйдел кичтең мәллә,
Мәхәббәтле булыр өчен
Дарулар эчтең мәллә.
Ай-ли баланым,
Түгәрәгем, кызыл бит,
Җаның сөйгән, теләгәнең
Белән тигез гомер ит.
Карурманда кар тирән,
Итәгеңә кар тигән.
Һәр китапны укып барам,
Сөйгәнеңне ал дигән.

Зәңгәр чәчәк ата торган
Гөлләр дә була икән;
Дөнья булгач бик сагынган
Көннәр дә була икән.

Уен дәвам итә. Ашыгып Бәкер белән Габделхәй керә.

Бәкер. Вәт бу яшьләрне! Исендә дә юк. Рәхәтләнеп биеп йөри. Бөтен военкоматтан аны эзләтәләр!

Габделхәй. Биесен, кордаш! Кайчан шулай бии ул тагын... Үз теләге белән... Әфганстанга язылган ди бит.

Бәкер. Әйтәм, җирле, югарыдан сөйләшүләр бөтенләй башка... Вәт, Илһам! Вәт, молодец! Авыл данына тап төшермәс безнең якташ!

Сандугач. Башы исән булсын...

Габделхәй. Башы исән булсын...

Бәкер. Әллә килен дә алып кайтканмы?

Сандугач. Авылга укытучы булып килгән кыз. Илһам кайткач, шаулатып туй ясарбыз, алла боерса...

Бәкер. Кая, егетләр, болай булмый инде. Авыл советымы мин, юкмы? Егет Әфган хәтле Әфганга китә. Әйтим бер сүз, туктагыз.

Яшьләр туктый.

Шулай, значит. Иптәшләр! Якташыбыз Илһам Галимуллин Совет Армиясе сафларына хезмәт итәргә китә. Ягъни, бөтен авыл белән без аны озатабыз. Якташыбыз үзе теләп Әфганстанга, дошманнар белән көрәшергә, әфган халкына ярдәм итәргә китә. Молодец, энем! Кем дигәндә, безнең авыллар, дисеннәр. Герой булып, күкрәгеңә орден тагып кайт. Безнең йөзгә кызыллык китермә!

Габделхәй. Рәхмәт, кордаш!

Сандугач. Рәхмәт, Бәкер...

Илһам. Хуш, Бәкер абзый, яхшы сүзләрең өчен рәхмәт. Рәхмәт, авылдашлар. Бер-берегезне саклагыз.

Бәкер. Шулай, значит, энем, синең китәр вакытың да җиткән икән. Шулайрак икән...

Илһам. Беләм, Бәкер абзый. Әни! *(Коча.)* Чәеңне кайткач эчәрбез инде, яме! Самавырың гел гөрләп торсын. Әти! Хуш! Хуш, Роза! Бергә яшәгез, тату яшәгез!

Зиннәт керә.

Синең белән хушлашмыйк әле, энем, шәһәрдә хушлашырбыз.

Сандугач. Карапкына бар инде, балам. Төнгә каршы...

Зиннәт. Йөргән юл бит ул, әни, борчылма.

Бәкер. Авыл советының машинасы да юк бит аның, ичмаса. Шул, сүз сөйләргә генә инде.

Илһам. Борчылма, Бәкер абзый! Йөрмәгән юл түгел. Кузгалдык, егетләр!

Егетләр-кызлар гармун белән аны озата баралар.
Роза ялгызы басып кала.
Сәхнә караңгыланып кала.
Роза ялгызы.

Роза. Кайда калдырып киттең син мине, Илһам? Өч ел көтәм бит, өч ел инде бөтенләй хәбәрең юк, кайда икәнеңне дә белмиләр. Синең хакта ямьсез сүзләр йөри. Синең кайгыдан әниең җүләрләнде. Атаң кешегә күтәрелеп карый алмый. Ә мин нишлим? Кемем бар минем биредә? Нәрсә тота мине биредә? Туйдым, ишетәсеңме, барысыннан да туйдым! Соңгы вакытта хатларың да бик салкынайган иде. Сугышта күңелең каткандыр, дидем. Авылыгызны ташлап китәргә намусым җитмәде. Ә син әйткән мәхәббәт барыбер кабынмады, Илһам, булганы да сүнә генә бара... Үзең юк... *(Чыгып йөгерә.)*

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сандугачлар өе. Зиннәт ялгызы. Ишеккә арты белән утырган. Әкрен генә гитарада Илһам калдырган көйне уйный.

Таш каланың ташлы туфрагында
Син гөлемне күрдем,

«Минем гөлем!» — дидем.
Күнелеңдәге нурны, мәрхәмәтне
Бер карауда сиздем,
Бер карауда сиздем...

Роза керә. Әсәрләнеп тыңлап тора да Зиннәткә ташлана.

Роза. Илһам! Мин белдем бит синең исән-сау кайтасыңны! *(Зиннәт икәнен күреп.)* Я, ходаl Инде мин дә җүләрләнәм ахры. *(Мичкә капланып елый.)*

Зиннәт. Еламагыз, Роза апа. Абый барыбер кайтачак ул. Менә әйтте диярсез. Армия хезмәтендә төрлесе булырга мөмкин. Кайтуын барыбер кайта ул.

Роза. Син бу җырны кайдан беләсең, Зиннәт?

Зиннәт. Теге вакытта абыйны Казанга мин озаттым бит. Юл буе шушы җырны җырлап барды. Ике ел буе мин аны исемә дә төшермәгән идем... Менә хәзер... Көнтөн башымда шул.

Роза. Мин моннан китәм, Зиннәт.

Зиннәт. Китәсең?!

Роза. Башка түзәр хәлем калмады. Җаныма урын таба алмыйм. Беркемем дә юк минем биредә!

Зиннәт. Ә мин?! Ә... эти-әни?

Роза. Сез — әйбәт кешеләр. Ләкин...

Зиннәт. Мин сезгә нәрсә дип әйтим, Роза апа... Роза... Әле сез монда булганда, абыйның исәнлегенә ышаныч зуррак иде. Бергәләп көтә идек. Инде сез дә китkәч...

Роза. Яшем 21 гә җиткән, Зиннәт. Син үзең дә инде мәктәп баласы түгел, җиткән егет, аңла...

Зиннәт. Сөйләмәгез... Авыр миңа...

Роза. Юк, син аңларга тырыш, Зиннәт. Минем өчен синең аңлавың бик мөһим... Мин... рәнҗемә... абыеңны... Илһамны... яратып өлгерә алмадым бугай... Монда мине мәхәббәт түгел, намусым гына тота...

Зиннәт. Һәм... өч ел буе шулай яшәдегезме?

Р о з а. Өч ел буе шулай яшәдем. Шулай яшәгәнемне хәзер генә аңладым. Аңла... Минем дә тормышка чыгып, балалар үстерәсем килә.

З и н н ә т. Аңлыйм, Роза апа... Роза. Аңлыйм! Безнең яшь арасы ике генә ел бит. Ә мин, нигәдер, әни авыргач, сез безгә күчеп килерсез дип уйлаган идем...

Р о з а. Сезгә? Минем, нигәдер, башыма да килмәде...

З и н н ә т. Мин авылчарак уйлыйм бугай шул. Артык беркатлы. Тормыш андый булмый бит инде ул, булмый!

Р о з а. Мин нәрсә эшли алам соң? Тормыш үзенекен итә... Болай да яшәп булмый...

З и н н ә т. Сез укытучы булмасагыз икән! Сез бит гел дөреслек, матурлык турында гына сөйли идегез! Сезнең һәр сүзегезне мин Коръән сүзе кебек кабул итә идем! Сез минем өчен фәрештә идегез! Изге фәрештә! Фәрештә җиргә төшеп, мондый йортларга кереп утыра аламы соң инде?!

Р о з а *(аның җилкәсенә кулын салып)*. Зиннәт, мин сине аңламыйм — нигә шундый сәер сүзләр сөйлисең син миңа? Синең күңелне рәнҗетерлек мин берни дә эшләмәдем кебек?

З и н н ә т. Нәрсәдер җимерелде. Абый юкка чыкты. Әни акылга җиңеләйде. Инде сез дә китсәгез... Бу дөньяда кап-караңгы кала бит. Шуны да аңламыйсызмыни?!

Габделхәй керә. Тамак кыра.

Г а б д е л х ә й. Улым, анаң кайда?

З и н н ә т. Аны өйдә тотып булмый бит, әти. Машина тавышы килсә дә чыгып йөгерә, самолет тавышы ишетсә дә...

Г а б д е л х ә й. Суга-фәләнгә төшә күрмәсен, бар, табып кайт.

Зиннәт чыгып китә.

Су сөлеге кебек хатын иде бит... Апаңны әйтәм... Сандугачны... Бер ел эчендә алышынды да куйды. Артык

яратты шул балаларны... Хәвефләнеп, әсәрләнеп яратты... Алай ук ярый идемени соң? Бигрәк тә ир балаларны. Безнең кулдамыни алар... Аңламады шуны Сандугачым...

Роза. Габделхәй абый, мин китәрмен инде.

Габделхәй. Ярар, кызым... Тукта, китәрмен дип...

Роза. Әйе, моннан китәрмен. Шәһәрдә урын бар. Яңа уку елы башланганчы, урнашырга кирәк.

Габделхәй. Үзең беләсеңдер, кызым. Ә Илһам... безнең малай... барыбер кайта ул... Менә әйтте диярсең. Сандугач апаңны күрмичә китмә инде... Юксыныр, эзләнер. Җүләр дигәч тә, барысын да аңлый, сизә бит ул...

Бәкер керә.

Бәкер. Саулармысез! Өйдә туры килүең ару булды әле. Зиннәтне чакырталар.

Габделхәй. Кайда?

Бәкер. Син, кордаш, башыңны җүләргә салма инде, Сандугач түгелсең. Хи-хи-хи...

Габделхәй. Әле төнге көтүдән генә кайтып кердем. Аңышып җитмәвем дә бар. Кайда чакырталар?

Бәкер. Военкоматка. Бер яз, бер көз алып калдык бит инде. Больше булмас кебек.

Габделхәй. Алып калдык, дип... Анасы авыру, абыйсының хәбәре юк. Калып торуның сәбәбе шул инде. Бераз башымны төртеп торам. *(Артын куеп ята.)*

Роза. Аңлашылды бугай, Бәкер абый?

Бәкер. Ә?! Шулай, димәк... без сиңа совет власте исеменнән — дәүләт эше белән, син безгә — артың белән? Әле хатын-кыз барында, укытучы барында?

Габделхәй. Нәрсә кирәк соң сиңа? Эшең булмаса, әнә, минем урынга малларны көтеп тор.

Бәкер. Нәрсә?!

Габделхәй. Җибәрербез дидем бит. Повестка килгән — җибәрербез. Аны бездән сорап та тормаячаклар. Без үстереп бирүче генә.

Бәкер. Әле син совет властена каршы коткы таратып ятасыңмы? «Алып китәрләр», «үстереп бирүчеләр...» Әнә, бер үстергәнеңнең эзен таба алмыйлар, тиз кыякладыы егетең, ә?

Габделхәй. Авызыңны чамалап ач, кордаш. Әле Илһамның язмышын беркем белми. Бәлки ул, ил өчен берәр батырлык эшләп, плен төшкәндер, яралангандыр?

Бәкер. Шаярма... Ил өчен батырлык эшләгәннәргә орден-медаль бирәләр, ил буенча милиция белән эзләтмиләр. Дезертир синең улың, әйтмичә генә торгач та...

Габделхәй. Шулай дисең инде... *(Кисәк сикереп торып, аның бугазына ябыша.)* Ә син нәрсә белән исбатлый аласың аны, ә?! Может ул, кан эчендә, үлем белән тартышып ятадыр, ә?!

Роза. Габделхәй абый! Бәкер абый!

Бәкер *(гырылдап)*. Җибәр... Мин службада... Дәүләт эшендә... Башың белән җавап бирерсең...

Габделхәй. Бирермен. Инде башымны да бирермен. Бер улымны алдыгыз, икенчесенә килеп җиткәнсең. Синең уллар әнә, Саратовтан, Куйбышевтан ары китми бит. Ә безнекеләр Әфганда юкка чыга. Әйтмичә йөргәч тә... әйтеп ни файда... шуңа гына дәшмим. Синең жаныңны җәһәннәмгә җибәрәм мин, совет исеме белән спекуляция ясап йөрисең, рәхәтеңне җайлап.

Роза. Туктагыз! Туктагыз?!

Бәкер. Сеңелем, Рузы, кеше чакыр! Кычкыр! Үтерәләр... үтерә-ә... *(Үрмәләп китә.)*

Габделхәй. Дәшмә, кабахәт җан! Менә балта, башың белән бергә телеңне дә чабып өзәм. Ә улларымны бирмим! Башта берсен кире кайтарыгыз, аннан икенчесенә килерсез! Бирмим!!! *(Повестканы ертып ташлый.)*

Зиннәт белән Сандугач кайтып керәләр.

Зиннәт *(әтисенә барып асылына)*. Әти! Нишләвең бу?! Ташла балтаңны!

Габделхәй *(үксеп)*. Бирмим...

Бәкер. Шаһит булыгыз... Сеңелем, син шаһит булырсың. Төрмәдә черетәм мин сине, контр, син совет властена каршы балта күтәрдең. Менә бу кәгазь кисәкләрен дә алам, черетәм...

Габделхәй. Мин болай да төрмәдә... Минем мал көтүдән башкага хокукым юк. Бар, барып әйт. Патшага да шулай дип кабатлармын.

Бәкер. Нинди патша, ахмак! Кайсы заманда яшәгәнеңне дә белмисең... Әллә монысы да хатыны артыннан китеп бара инде? Психка яптырам мин сине, төрмәдә черетәм.

Сандугач. Баланы уяткансыз, уяткансыз да, ашатмагансыз. Ничә еллар инде балам ач... *(Бәкер каршына килә.)* Бер генә кабымлык ризык бирче. Сине авылда иң бай кеше диләр, ә без — ярлы көтүчеләр, ашарыбызга юк. Мин сиңа шуның өчен җыр җырлар идем...

Сандугачның, мескенкәйнең...

Роза битен каплап чыгып йөгерә.

Бәкер *(Зиннәткә)*. Военкоматка чакыртканнар сине. Бер яз, бер көз алып калдым, больше ярамый.

Зиннәт. Әни авыруга күрә калдырып тордылар мине. Китәргә икән — китәрмен.

Сандугач. Кая китәрсең?! Ә синең балаңны кем карар? Мин ул балаларга нәрсә ашатырмын? Атаң көтүче генә бит ул. Тагы байлар каршына барып бил бөгәргә туры килә икән, ходаем...

Габделхәй *(Сандугачка)*. Елама, әнисе. Зиннәт солдат хезмәтенә генә китә бит, үләргә түгел.

Сандугач. Илһамны да шулай дип әйткән идегез...

Габделхәй *(Бәкергә)*. Ә син — ычкын моннан. Бүтән бу йортка аяк басып керәсе булма.

Бәкер. Карарбыз әле, кем ычкыныр. Минем шаһитым бар, мин бу эшне болай гына калдырмыйм. Мин сине психта черетәм, мин сине төрмәдә черетәм! *(Чыгып китә.)*

Зиннәт. Аның белән саграк булырга кирәк иде, әти. Аның бит авылга милиция чакыртудан башы чыкмый. Юк кына нәрсә өчен күпме кешегә штраф салды, күпме кешене утыртты.

Габделхәй. Абыеңны... Дезертир дип атады. Йөрәгемә генә килеп кадалды шул сүзе. Кызып киттем.

Зиннәт. Ул аны авылда күптән шулай дип сөйли икән инде. Минем сезгә әйтәсем генә килмәгән иде.

Сандугач *(кычкырып җибәрә)*. Урядниклар килә! Урядниклар! Камчылы казаклар килә! Качыгыз! Харап итәләр.

Зиннәт. Әни, тукта. Тукта, әни җаным... Милиция ул. Самогончыларны тикшереп йөриләр иде. Теге хайван барып әйткән ахры — туп-туры безгә таба киләләр.

Сандугач. Качыгыз! Йорт астына төшегез! Мин сезне көтүдә, диярмен. Тапмыйча китәрләр, качыгыз!

Габделхәй. Алардан качып кына котылып булмас. Элеккеге заман түгел бу, авылдан-авылга качып йөрергә. Алдан кәгазең йөри.

Милиционер, Бәкер, Роза керәләр.

Бәкер. Менә, миңа, ягъни совет властена балта күтәрде. Малаен солдатка бирмим диде. Повесткаsuccessfully ертып атты. Менә, менә *(кәгазь кисәкләре күрсәтә)*.

Милиционер *(Габделхәйгә)*. Балта күтәрүегез хакмы?

Габделхәй. Олы улым солдат хезмәтендә юкка чыкты. Шуны дезертир дип атады. Йөрәгем түзмәде — балта күтәрдем.

Милиционер. Сез аңа хезмәтен башкарганда һөҗүм иткәнсез. Салкын корал белән. Моның өчен статья бар, агай.

Габделхәй. Бардыр. Хәзер бар нәрсәгә дә статья бар. Һава сулаган өчен дә статья чыгар әле.

Бәкер. Менә, менә, ишетәсезме? Көтүче дип, башын җүләргә салып, күрәсезме, нинди сүзләр сөйли? Ә? Ярлы кеше, имеш. Хәзер бай-ярлы юк! Бөтенебез бертигез.

Милиционер *(Розага)*. Сез боларның барысын да күреп тордыгызмы?

Роза битен каплап елый.

Бәкер. Күрде, күрде! Аларның... ни... дезертир малайларының хатыны буласы иде шул. Шуңа дәшми. Күрдең бит! Күрдең бит! *(Өстенә килә.)*

Габделхәй. Газаплама баланы... Мин баш тартмыйм бит. Әйе, күтәрдем мин сиңа балта. Совет дәүләте синең кем икәнеңне белми, сине түренә утыртты. Авыл советына түгел, мал көтәргә дә куймас идем мин сине. Чөнки хайван белән дә кешечә сөйләшергә кирәк. Ә син кешеләр белән дә хайванча сөйләшәсең.

Бәкер. Совет власты... Алыгыз! Я требую! Ул совет властын хурлый!

Милиционер. Бу бик четерекле... политик факт. Әле үзара талашып, балта күтәрешсәгез, кул да селтәр идем. Ә бу — политик факт. Моны болай гына калдыра алмыйбыз. Җыеныгыз.

Зиннәт. Мине... Армиягә алып китәләр. Әни... авыру. Аны кем белән калдырыйк? Бәкер абый! Әти кызулык белән әйткән. Кичер бер юлга, кагылма карт кешегә.

Габделхәй. Ялынма, улым. *(Розага.)* Кызым, аягыңа егылып сорыйм — ташлама апаңны. Без кайтырбыз. Илһам да кайта ул, менә күрерсең.

Роза. Борчылмагыз, Габделхәй абый. Сандугач апаны мин үзем карармын.

Сандугач *(кулларын чәбәләп)*. Габделхәй дә патша хезмәтенә китә! Габделхәй да патша хезмәтенә китә! Аңа анда кызыл мундир бирәләр! Кылыч бирәләр! Ул авылга кайта да революция ясый! Байларның башын чаба! Бәкернең башын чаба! Ха-ха-ха!

Милиционер. Монысы нинди коткы тагы?

Бәкер. Җүләр аның анысы. Кәгазьле җүләр. Җүләр булса да болар сүзен сөйли. Контр сөйли.

Габделхәй. Хуш, анасы. Розаны тыңла инде, ярыймы? Су буйларында бик йөрмә. Хуш, улым...

Зиннәт. Мин сине озатам, әти. Алай гына кешене утыртмыйлар ул. Районда үзем сөйләшеп карармын.

Бәкер. Сөйләште ди, бар. Факты по-ли-ти-чес-кий. Аңладыңмы. Барыгызга да ярый бу статья.

Милиционер. Күп сөйләшәсең, агай. Әйдәгез, кузгалдык, калганын районда карарбыз.

Сандугач *(артларыннан ташлана)*. Үзем барам патшага! Патша янына барам. Ак патшадан ярдәм сорыйм! Бирегез миңа улларымны?! *(Кулын күккә күтәреп тезләнә.)* Ишетәсезме?! Бирегез миңа иремне?! А-а-а!!! *(Ава.)*

Роза аны юатмакчы була. Үзе дә кушылып елый.
Өстәге күренеш.

Абстракт ил вәкиле. Офицерларыгызны да алдык, Брежнев әфәнде, атларыгызны да алдык. Тагы нәрсәгез калды?

Брежнев. Бездә иң зур байлык — кешеләр. Алар ил өчен утка да, суга да керергә әзер. Кешеләр, кешеләр, кешеләр! Барысы да кешеләр өчен!

Абстракт ил вәкиле. Уен кырында ялгыз калып барасыз. Мат куярлар дип курыкмыйсызмы?

Брежнев. Бирәү — меңнәр өчен, меңнәр — бирәү өчен. Безнең илдә кеше ялгыз була алмый. Без бер-беребез өчен стена булып басабыз. Күрәсезме, анда күпме халык җыелган? Алар ил өчен бүген утка керергә әзерләр.

Абстракт ил вәкиле. Шах, Брежнев әфәнде.

Брежнев. Чигенер урын юк. Безгә алга барырга кирәк. Безгә бөтен дөнья карый. Безгә дәрәҗәне төшерергә ярамый. Алга, алга, иптәшләр!

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шунда ук — Сандугачлар өендә бара. Яшьләр Зиннәтне озату мәҗлесенә җыелганнар. Роза белән Сандугач та монда.

Зиннәт. Тәки үзеңнекен иттең, әни! Тәки мәҗлес җыйдырдың!

Сандугач. Абыең да урамнан китте. Шул гел күңелем өстендә торды...

Зиннәт. Әни, син бүген бигрәк матур күренәсең! Сәламәтлегең дә яхшырган кебек.

Сандугач. Күземнән... пәрдә төшкән кебек булды. Әллә нинди куркыныч йокыдан айнып киттем — карыйм — олы улым юк, ирем юк, син китәргә торасың... Нәсел җебем өзелергә тора... Шул хәвеф айнытты...

Зиннәт. Сиңа да рәхмәт инде, Роза... Өй эчләре яктырып китте... Ул җандагы нурны әйткән дә юк...

Роза. Габделхәй абый ничек соң, Зиннәт?

Зиннәт. Әти... калды әле. Бәкер абзый әллә нәрсәләр язып бетергән анда. Бөтенесен бергә өйгән, имеш, абый чит илгә качкан, без монда совет властена каршы коткы таратабыз.

Роза. Ул җүләр сүзләргә ышана торган заман түгел бит инде, Зиннәт. Габделхәй абыйны кем белми инде? Гомер буе көтү көтте бит ул!

Зиннәт. Мин дә шундый ышаныч белән китәм — озак тотмаслар әтине! Эш судка да барып җитмәс әле.

Сандугач. Кая, улым, кунаклар җыелып бетте бугай.

Зиннәт. Әйдәгез әле, егетләр, утырышыйк әле алайса. Абый белән икебезгә уртак мәҗлес булсын. Сыздыр әле, яшьти, гармуныңны!

Гармун тартып җибәрәләр. Яшьләр җырлый.

Басу капкасын чыккач та
Күтәрелде томаннар.
Дөнья хәлен белеп булмый

Сау булыгыз, туганнар.
Басу капкасын чыккач та,
Уңга каерылгач та,
Рәхәт яшәгез, дусларым,
Миннән аерылгач та.

. . . .

Алмаз кайчыларыгыз, шул,
Киләсе ел бу вакытта
Булмас кайсыларыбыз...

Зиннәт. Их, егетләр, болай да йөрәкләр яна! Әйдә, башка көйләрне җырлыйк әле! *(Җырлый.)*

Сандугачым, гүзәлем,
Тибрәтмә тал үзәген;
Кеше гүзәлем дигәндә
Нихәл итеп түзәрмен.
Алмагачның алмасын
Алып өләшер идем;
Һавалардан очып төшеп
Күреп сөйләшер идем. *(Өстәлгә каплана.)*

Роза. Син алай бетеренмә әле, Зиннәт. Әниең янында мин калам. Алай бетеренмә, өйләнерсең дә кайтырсың.

Зиннәт. Их, Роза апа, Роза, Роза-гөл! Белмисең. Йөрәк яна бит! Мең төрле ут арасында калдым, син дә аңламыйсың шуны! Апа түгел син миңа, түгел! Җырла әле бер, ичмасам, җырыңны алып китәрмен.

Роза. Җырлыйм, Зиннәт... Тик... алай карама син миңа, зинһар, алай карама... Мин җырлый да алмам... *(Җырлый.)*

Бу нинди язмыш, бу нинди тормыш,
Сагыштан тора көннәрем тулып.
Бер көнлек ярым, бер көнлек парым,
Мәңгегә калдың язмышым булып.
Бу нинди язмыш, бу нинди тормыш,
Изге хисләрне каплап калырлык.
Кайдан көч алыйм каршы торырлык,
Мәхәббәтеңне саклап калырлык.

Сандугач. Ә мин беләм! Барысын да беләм! Мин нишләргә кирәген беләм. Мин җүләр түгел.

Зиннәт. Әни, җаным, тынычлан, зинһар...

Сандугач. Улым, син минем өчен курыкма хәзер. Миндә хәзер *(югарыга күрсәтә)* алар белән бәхәсләшерлек көч бар. Без бүген туй ясыйбыз, балалар.

Зиннәт. Ничек — туй? Кем туен?

Сандугач. Роза белән синең туйны ясыйбыз, балам!

Роза. Сандугач апа! Зинһар, туктагыз!

Сандугач. Юк!!! Туктамыйм, кызым. Мин бу көнне 25 ел көттем, 25 ел бит! *(Елый.)*

Зиннәт. Әни, бәгърем, елама! Елама, әни...

Сандугач. Әйтеп бетерим. Күңелем сизә — Илһам абыеңа нидер булган. Төшләремә гел ыңгырашып керә. Туналмаган җире юк. Инде син дә китәсең. Дөнья тыныч түгел. Минем бүтән балам юк. *(Розага.)* Кызым! Аягыңа егылам. *(Тезләнә.)* Киленем бул! Мин бит күреп торам — улым сине ярата. Яратмаслык та түгел шул син. Бул киленем?! Тынычлап үлим? Кызым, балам?!

Роза. Сандугач апа, зинһар торыгыз! Зиннәт, ярдәм ит, Зиннәт?

Зиннәт. Әни... хаклы, Роза...

Роза. Син!.. Син нәрсә, Зиннәт?!

Зиннәт. Әни хаклы. Менә... Беренче күрүдән үк яраттым мин сине. Беләм! Кыргыйлык икәнен дә беләм! Абый белән яратыштыгыз. Абый белән болай булып бетмәсә, үзем белән үлә иде бу серем. Киткән булыр идем авылдан, качар идем синнән! Менә язмыш шулай китереп чыгарды. Мин дә ут эченә китәм. Сине югалтачакмын. Син монда калмаячаксың. Риза бул, Роза?!

Роза. Мин... мин моның шулай буласын сизенгән идем, Зиннәт. Шуңа күрә гел синең белән очрашмаска тырыштым. Чөнки син Илһамның энесе идең. Син минем тиңем идең — ләкин син Илһамның энесе идең.

Зиннәт. Миңа синнән башка тормыш юк, Роза...

Роза. Илһам кайтса, ни дип әйтербез?

Зиннәт. Исән кайтса, аңлар иде әле. Исән генә булсын иде!

Сандугач. Кызым, син риза, балакаем?! Балалар, туй итәбез, газизләрем! Их, Габделхәй абыегыз гына юк. Ничек сөенер иде, мескенем...

Зиннәт. Без аңа иртәгә әйтә китәбез, әни. Шулай бит, Роза гөлем? Язылышуын да иртәгә районда язылышырбыз. Солдат кешегә тоткарлык юк бит ул. Бәкер каршына бармыйбыз инде, шулай бит, Роза гөлем?!

Роза. Шулай итәрбез, Зиннәт...

Сандугач. Әйттем бит мин — безнең урамда да бәйрәм булыр, дидем. Туй итәбез бит, балалар! Ашагыз, балакайларым, эчегез, уйнагыз, җырлагыз. Безнең өйгә дә бәхет керде. Бер төн булса да, күңел ачып калыгыз, балакайларым.

Яшьләр уйнап-җырлап утыралар.

Роза кызым, кил әле. *(Роза килә.)* Үземнең туй күлмәгем исән. Кыз чагымнан калган ап-ак ефәк шәлем бар. Киенеп чык, кызым. Зиннәтнең күңеле булыр.

Кереп китәләр. Яшьләр җырлый. Бераздан Роза ак күлмәктән, ак ефәк шәлдән чыга. Зиннәт йөгереп килеп аны күтәреп ала.

Зиннәт. Менә хәзер чын килен син! Минем Роза гөлем син. Әй, кордаш, уйна әле бию көен, парлап биик әле Роза гөлем белән!

Салмак кына парлап биләр. Бу биюдә сагыш та, ярату да, тыенкы ярсу да, моң да, чарасызлык та — барысы да бар. Сандугач бер читтән сагыш белән карап тора.

Абстракт ил вәкиле. Бер солдат һәм бер король калды, Брежнев әфәнде.

Брежнев. Әмма ул совет иле солдаты! Сез безнең халыкны белмисез! Ул көрәш өчен туган, сугыш өчен туган. Һәм ул соңгы тамчы канына хәтле сугышачак.

Абстракт ил вәкиле. Шах.

Брежнев. Иптәшләр! Иптәш... Солдат! Ватан өчен, ил өчен — үлемгә! Алга!

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук йорт. Кышкы кич. Тышта буран. Сандугач белән Роза ялгыз. Роза авырлы.

Роза. Әнкәй, Зиннәттән бүген дә хат юкмы?

Сандугач. Килер, балакаем, килер, солдат кеше бит ул. Ул яклардан хатлар гел шулай озак йөри бит инде. Әле бүген почта да килә алмагандыр — буран бит.

Роза. Ике ай бит инде! Әфганстанда булса да, көн аралаш хаты килеп тора иде. Ичмаса, әткәйне да һаман чыгармыйлар. Военкоматка булса да барып кайтыр иде.

Сандугач. Сиңа борчылырга ярамый, кызым. Бүген-иртәгә бәби табарга торасың. Балаңа зыян килер, борчыла күрмә. Нишлисең, ир-атның язмышы шул инде аның. Кем уйлаган бит аны, картайган көнендә әткәң дә төрмәдә утыра менә. И, тормыш...

Роза. Әткәй белән артык каты кыландылар шул. Бу Бәкер абый кеше түгел икән. Әллә нәрсәләр сөйләп бетерде судта да.

Сандугач. Простой кешене утыртуы җиңел ул, кызым. Бәкерләр генә һәр заманга яраклаша алалар. Үзгәрергә кушкан саен үзгәреп кенә торалар.

Роза. Әткәй кызганыч. Ике улын солдатка биреп... һич дөрес түгел инде.

Сандугач. Илһамның болай булып чыгуы да җайсызрак булды шул. Халык әлләниләр сөйли бит. Безнең солдатлар чит илләрдә качып яталар икән, дип тә...

Роза. Хезмәт срогы тулганга да ике ел була бит инде.

Сандугач. Суга төшкәндәй юк булды бала. Уйласам, күз алларым караңгыланып китә. Тагы җиңеләермен дип куркам. Әле дә ярый син булдың, балакаем. Ходай

безнең нәселне саклап калу өчен җибәргәндер сине, балакаем...

Каты итеп ишек döбердәтәләр.

Ай, алла, бу буранда кем йөрер икән? Җүнле хәбәр генә булса ярар иде, ходаем... *(Чыга.)*

Роза *(тыңлап)*. Әллә нинди ир-ат тавышлары. Бәкер абый тавышы да бар... Теге вакыттагы милиционер тавышы... Ай, алла, әнкәй нигә кычкыра ул? *(Ишеккә таба атлый да бөгелеп төшә.)* Ах, әнкәй... Әллә нәрсә булды... Билем... *(Караватына барып каплана).*

Атылып Сандугач керә. Аның артыннан Бәкер, милиционер, военком керәләр. Кулларына иидер күтәргәннәр. Ишек төбенә 'коляска кертеп куялар.

Сандугач. Кызым... Илһам...

Роза. Ах... Юк, юк!!! Юк! Ах, әнкәй... Үләм... Илһам... Зиннәт... Үләм...

Бәкер. Туктагыз әле, бака туе ясамагыз монда. Герой кайтты авылга, герой! Советлар Союзы Героена тәкъдим ителгән бит Илһам! Ә сез — «үләм», «бетәм»...

Милиционер. Абзый, син бераз читкә китеп тор әле, җыелышта түгелсең. Мин синең башкача сайраганыңны да хәтерлим әле. Монда хәлләр шактый авыр...

Бәкер. Авыры артта инде, артта. Кая, герой үзе кайда соң?

Военком. Монда авырлы хатын бар.

Бәкер. Энесенең хатыны ул. Колак какты геройдан, ахмак кыз. Хәзер эчеңне кочаклап утыр инде менә, герой хатыны буласы урында.

Сандугач. Җитте. Улым кайда? Кайда улым?! Күрсәтегез! Газапламагыз мине артык. Дүрт ел ут йоттым! Кайда улым?!

Военком. Апа... Сез борчылмагыз... Улыгыз бераз яралы... госпитальдә яткан...

Сандугач. Мең ярасы булса да терелтермен! Кайда ул?!

Коляскаңы идән уртасына куялар.

Военком. Менә, апа, улың...

Сандугач. Улым?! *(Аңа ташлана. Коча. Капшый. Әсәрләнеп сикереп тора.)* Аның куллары кайда соң?!

Военком. Куллары юк, апа..., дошман кискән...

Сандугач *(капшап)*. Ә аяклары?.. Аяклары кайда?!

Военком. Аяклары да юк, апа, дошман кискән.

Сандугач *(улының башын кочып)*. Башы... гел марляга уралган... Нигә бер сүз дә эндәшми соң ул?!

Военком. Теле дә юк апа... телен дә кискәннәр...

Сандугач. Телен дә кискәннәр?! Балам... Төшләремә гел җәрәхәт белән кергән идең шул... Ишетәсеңме мине, балам, нинди хәлдә булсаң да, син минем балам. Ишетәсеңме мине, улым?

Военком. Ишетми дә ул, апа... Ишетми дә... Колакларын да кисеп алганнар, бәдбәхетләр...

Сандугач. Күзләре?! Күзләре исәнме? Ачыгыз йөзен, күрсен мине, аңласын, нинди хәлдә дә ул минем йөрәк парәм, иң-иң кадерлем, иң-иң газизем... Ачыгыз йөзен...

Военком. Улыгызның... күзләре дә юк, апа... Бер йөрәге исән... Бер йөрәге исән! Кайда гына хезмәт итмәдем — мондый хәлне күргәнем булмады... *(Читкә китә.)*

Бәкер. Бәлки ул... безнең Илһам түгелдер дә әле? Ә? Кем белә аның кем икәнен? Алай бер җире дә булмагач, дим инде... Танырлык булмагач?

Военком. Алай булырга да мөмкин. Алар пленга биш кеше төшкәннәр. Исән калучысы шушы гына. Калганнары җәзага түзә алмый үлгән. Каберләре дә билгесез. Без бу гәүдә белән дүрт җирдә булдык инде... Аналары танымады... Бишенчесе — шушы йорт. Сезнең дә алмаска тулы хакыгыз бар. Без ул чакта аны дәүләт тәрбиясенә тапшырырбыз.

Сандугач. Юк!!! Юк!!! Йөрәгем сизә — минем балам. Минем... Мин аның шушындый хәлдә икәнен дә белдем,

шушылай кайтарасыларын да белдем. Минем улым! Инде берегезгә дә бирмим. Үзем кеше итәм. Үзем...

Ишек шакылдаталар. Бәкер чыга.

Роза *(авыр-авыр сулый)*. Әнкәй... Илһам бу! Илһам... Гәүдәсеннән таныйм... Үзем карармын, әнкәй... Гаебем зур аның каршында... Шуның җәзаларыдыр бу...

Кулына кәгазь тотып, Бәкер керә.

Бәкер. Иптәш военком, сезгәме соң бу язу? Сезгә дә дигән кебек, боларга да. Зиннәт турында бугай бу язу? *(Кәгазьне военкомга бирә)*.

Роза. Зиннәт?! *(Язуга үрелә.)* Бирегез миңа?! Зиннәт? Ни булган Зиннәткә?

Военком. Бу язуны... монда ашыгычлык белән җибәргәннәр.

Сандугач. Ни булган минем улыма?! Инде монысына да?! Я, ходай? Нигә минем нәселемне генә рәнҗетәсең син?! Нигә?!

ӨСТӘГЕ КҮРЕНЕШ

Абстракт ил вәкиле. Соңгы солдатыңны алам, король!

Брежнев. Ашыкма, синең өчен бер солдат нәрсә инде? Син хәзер үзең бездән көчле. Кагылма соңгы солдатка.

Абстракт ил вәкиле. Уенның законнары катгый, мәҗбүри. Юк солдатың! Мат!

Кинәт Роза ачы итеп кычкырып җибәрә.

Роза. Үтерделәр! Үтерделәр!.. Зиннәтне... үтерделәр!

Сандугач. Кызым?! Балам?! Чү, балам, хәзер... Кайгы күзне томалаган... Син бар бит әле... Әйдә теге якка... Барыгыз, берәрегез фельдшер чакыртыгыз. Бар, Бәкер, йөгер. Әйдә, кызым, әйдә.

Теге якка кереп китәләр.

Военком. Ни булса да, ир-ат күрә. Ир-ат күргәнне хатын-кыз йөрәге, җаны аша үткәрә. Нинди түзем, олы җанлы сезнең татар хатыннары! Менә шушындый хатыннар үстерә инде арысландай ир-егетләрне... Ә Зиннәт... Зиннәт Галимуллинны... үтергәннәр Әфганстанда... Гробка салырлык та гәүдәсе калмаган...

Кинәт бала елап җибәрә.

Ә тормыш барыбер дәвам итә, егетләр... Барыбер дәвам итә...

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Беренче күренештәге картина. Әрәмә буе, көн кичкә таба. Яшьләрнең кичке уены башланып кына килә. Сәхнәгә инвалидлар колясĸасы тотып, Сандугач чыга. Янында — Роза. Розаның кулында яшь бала. Сандугач — актан, Роза карадан киенгән.

Сандугач. Җир кипкәнне тилмереп көттем. Шушында алып килсәм, гармун тавышларына колагы ачылыр кебек. Бөтенесен аңлый бит инде ул, аңлый, әйтә генә алмый. Минем бармакларымны сизә. Мин үз баламны танымыйммы соң инде? Тәнендәге бөтен миңнәрен таптым.

Роза. Әнкәй, аны Мәскәүгә, операциягә алып барырга кирәк. Теге вакытта военкоматтан әйткән иделәр бит.

Сандугач. Менә, әткәң чыксын инде. Кул-аякларын да эшләтербез. Җаны исән бит әле аның, йөрәге исән. Барысын да аңлый бит ул...

Роза. Мине дә таный микән, әнкәй?

Сандугач. Таныйдыр, балам, таныйдыр. Гакылы, йөрәге исән бит аның.

Роза. Миңа рәнҗидер инде?

Сандугач. Рәнҗесә дә, сиңа түгелдер, кызым. Мондый утны-суны, газапларны кичкән ир бала хатын-кызга

үпкә саклап торырмы икән? Рәнжеше зурректыр анын: башкаларгадыр... Синең безнең йортта калганны белгәч, сөенер генә әле.

Роза. Зиннәт турында әйтми торырбыз инде...

Сандугач. Нишлисең, вакыты җиткәч, анысын да белер инде. Берсенең ярты тәне калды чит җирләрдә, икенчесе бөтенләй ятып калды. Кемнәр шулай каргады безнең нәселне, милләтне?!

Роза. Әнкәй, кем ул бирегә таба йөгерә?

Сандугач. Әткәң бит! Әткәң! Габделхәй!

Габделхәй керә.

Габделхәй *(коляскага ташлана)*. Улым! Илһам улым! Әйттем бит, барыбер кайта ул дип! Минем улым кайтмыйммы соң?! Улым, үз улым бит ул!

Сандугач. Исәнме, атасы?

Габделхәй. Исәнме, анасы?

Күрешәләр.

Исәнме, килен?

Күрешәләр.

Сандугач. Менә, әтисе, кечкенә улыбыз — Зиннәт.

Габделхәй *(баланы кулына ала, елый)*. Әй, балам... Әй, сабыем, гөнаһсыз нарасыем... Синең язмышыңа да эләкте бит бу мәгънәсез сугыш... Рәхмәт, кызым, нәселебезне саклады. Гомер буе сиңа рәхмәтле булып яшәрбез.

Роза. Үзең дә бик бетеренгәнсең, әткәй... Чәчләрең агарган...

Габделхәй. Төрмә бит ул, кызым... Балалар кайгысы да бик бетерде. Мин барысын да ишетеп яттым бит анда... Илһам герой булып кайтмаса, чыгу юк иде әле миңа аннан... Төрмә ул...

Ашыгып милиция работнигы, военком, Бәкер керәләр.

Бәкер. Без аларны дөнья бетереп эзлибез — алар сәхрәдә йөри икән! Соң, бүген клубта Илһамга йолдыз тапшырабыз бит, йолдыз!

Габделхәй. Нихәл, кордаш, исән генә яшәдегезме мин юкта? Илдә иминлекме? *(Күрешәләр.)*

Бәкер. Иминлекме, дип... Яшәдек инде... Миңа төрттерәсең инде, ә, кордаш? Төрттер, төрттер, син хәзер герой атасы. Хи-хи-хи...

Габделхәй. Төрттермим, кордаш. Баш исән булсын... Исән кеше бер кайта. Син — кечкенә кеше... Син бездән дә кечкенә кеше шул. Сиңа кая үпкәлисең инде...

Военком. Абзый, апа, без клубка бара торабыз. Анда бүген Казаннан да кешеләр киләсе. Кинога да төшерәчәкләр. Сез озакламагыз инде.

Сандугач. Юк, юк, энем, без хәзер килеп җитәрбез... Менә улымны... улларымны... быел беренче тапкыр әрәмә буена алып чыктым. Тәннәренә сихәт булсын, дим...

Бәкер. Илһамга йолдызны үзебез тапшырырбыз, Габделхәй! Авылдаш бит. Анда әле кинога да төшерәләр икән...

Милиционер. Син, абзый, бераз читтә торырсың инде, яме. Аста гына утырырсың. Бәхетең, авылдашларың изге күңелле икән. Мин булсам, кул да бирмәс идем сиңа. Киттек, егетләр.

Китәләр.
Сәхнәдә Габделхәй, Сандугач, Роза калалар.

Сандугач *(яшьләргә)*. Әй, балалар, уйнагыз әле үзебезнең уен көйләрен! Ишетсен Илһам абыегыз! Туган җирендә икәненә тәмам ышансын! Җилләрен таныды инде ул аның, таныды! *(Зиннәтне кулына ала.)* Син дә күр, балам. Менә бу синең туган җирең була — атаң җире. Без — шушы җир кешеләре — татар балалары. Безнең нәсел монда мең ел яши инде. Өзеләм-өзеләм дигәндә дә ялганып китә. Безнең нәселне ялгаучы — менә син хәзер. Менә бу моңнарны да син сакларсың, телебезне дә син

сакларсың. Яулар килсә, атаң, абыең кебек, татар илен дә син сакларсың. Дөньяда күп авыр хәлләр, сугышлар татар егетләре язмышы аша да үтә. Татар егетләренең сөякләре дөнья буйлап сибелгән. Без, аналар, уллар үстерәбез. Арыслан кебек егетләр үстерәбез. Мәгънәсез сугышларда һәлак булмасыннар иде алар. Сиңа тыныч тормыш насыйп булсын иде, улым!

Сандугачның балалары сугыш өчен генә түгел, үз телендә сайрар өчен дә туган бит. Җырлап яшәр өчен туган. Ул җыр сиңа насыйп булсын иде, улым, соңгы юанычым...

Җыр-бию дәвам итә.

ӨСТӘГЕ КҮРЕНЕШ

Уен кырында фигура-кешеләр чәчелеп ята. Өсләренә кызыл җәймә капланган. Кыр буш. Дөнья картасында әле башка утлы нокталар яна.

Пәрдә

ВАКЫЙГА ҖҮЛӘРЛӘР ЙОРТЫНДА БАРА...

Трагикомедия

(Өч күренештә)

КАТНАШАЛАР:

Тиленәр:
«Баш» тиле.
Тиле Даһи.
Тиле Түрә.
Тиле карт.
Тиле Ир.
Тиле Хатын.
Милләтче.
Демократ.
Депутат.
Шыр тиленәр.
Табиблар.

Вакыйга безнең көннәрдә җүләрләр йортында бара.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Югарыда, караңгылыкта, ялгыз лампочка-күз яна. Түбәндә — шыксыз зур зал. Почмакта телевизор. Җүләрләрнең ял вакыты. Кем телевизор карый, кем туктаусыз йөреп тора.

Тиле Түрә. Юк, син менә миңа әйт — син ничек монда килеп эләктең? Син бит җүләр түгел! Мин синең күзеңнән күреп торам — җүләр түгел син!

Тиле Даhи. Мин җүләр түгел! Мин — Даhи! Мин — гений! Мин сезнең барыгызның да минем турында нәрсә уйлаганын белеп торам. Миңа... хәбәр итәләр...

Тиле Түрә. Я, алайса, мин нәрсә уйлыйм, я, әйт?

Тиле Даhи. Мине җүләр дип уйлыйсың.

Тиле Түрә. Менә тиле, вәт тиле! Соң әле генә әйттем бит мин — син җүләр түгел, дидем.

Тиле Даhи. Хәзер җүләр, дисең.

Тиле Түрә. Хәзер җүләр, дим... Син нәрсә, мине җүләргә саныйсың?! Кем дип белдең син мине? Әйт, син тилеме, мин тилеме? Әйт!

Әйткәләшә, тарткалаша башлыйлар.
Сәхнә алдыннан Тиле Ир белән Тиле Хатын үтеп китәләр.

Тиле Хатын. Ә без нинди бәхетле!

Тиле Ир. Безнең икебезгә бер баш, бер йөрәк...

Тиле Хатын. Без нинди ирекле! Ниhаять, без хыялланган тормыш! Һәркемнең үз эше! Монда беркем беркемне гаеп итми! Нинди ирек!

Тиле Ир. Ә безнең ачышыбыз! Онытма, без — кешелек дөньясының соңгы ачышы. Ләкин кешелек дөньясы аннан курыкты. Без — күкләрнең соңгы тәҗрибәсе...

Тиле Хатын. Безнең икебезгә — бер баш, икебезгә — бер йөрәк.

Тиле Ир. Әмма бу серне без үзебез белән күкләргә алып китәбез. Без кешелекне коткара алмадык.

Тиле Хатын. Әйе, без кешелекне коткара алмадык.

Тиле Ир. Бәлки әле җае чыгар? Бәлки без ачышыбызны аңлатып китә алырбыз?

Тиле Хатын. Ә бәлки... берәрсенә ачылып карарга кирәк? гадыр?

Үтеп китәләр.
Сәхнә алдыннан Милләтче һәм Демократ үтеп баралар.

Д е м о к р а т. Менә, ханым, без дә сезнең белән бер йортка эләктек! Әлбәттә, Сөембикә һәм Иван Грозныйны бер йортта күрү минем үзем өчен дә сәеррәк. Әмма без барысын да кызык иттек — сез милләтче булып йөрдегез, ә мин демократ булып кыландым *(көлә)*. Башта барысы да ышандылар. Аннан... менә шушы йорт. Безнең илдә генә үз патшаларына карата шушындый вәхшилеккә барырга мөмкиннәр.

М и л л ә т ч е. Империядә, диегез, әфәндем, империядә генә мөмкин.

Д е м о к р а т. Мин бу хакта бәхәс куертмас идем. Мин, ярар, сезнекеләр өчен биредә чит элемент, сез әйткәнчә, ялган демократ инде. Мине бирегә тыксыннар да ди. Сезне, милләтчене, үзегезнекеләр ничек бирегә китереп кертте соң? Әллә ычкынуыгыз да хакмы?

М и л л ә т ч е. Бәлки, бәлки...

Д е м о к р а т. Ә сез юкка көрәштегез. Бу империя — дөньяның үзәге. Бөтен дөнья безнең аяк, то есть, кул астында булырга тиеш. Чөнки без — Иваннар — дөньяда иң акыллы халык. Безгә бу миссия... югарыдан бирелгән. Без — дөньяның кендеге! Мин — Иван Дүртенче!

М и л л ә т ч е. Һәм шушы тиле фикер сезне җүләрләр йортына китерде дә инде. Халкыгызны — һәлакәткә.

Д е м о к р а т. Әмма бу вакытлы күренеш. Безнең йолдызыбыз мәңге сүнмәячәк. Ә мин сезне кызганам, Сөембикә ханбикә. Сезне милләтегез күзен дә йоммый сатып җибәрде.

М и л л ә т ч е. Азатлык хакына алыштырды. Тынычлык хакына.

Д е м о к р а т. Азатлык бөек милләтләргә генә хас! Тынычлык — хайваннарга! Без азатлыгыбызны кылыч белән алдык, кылыч белән тотабыз! Моны Иван Грозный әйтә!

М и л л ә т ч е. Бәлки бу юлы сез хаклысыздыр да...

Үтеп китәләр.

Т и л е к а р т *(телевизор яныннан)*. Саталар! Тагы саталар! Илне! Ә сез анда: син тиле дә мин тиле, дип

тарткалашасыз! Сатып бетерәләр бит инде! Мәскәүне саттылар, Казанны саттылар. Хәзер безнең йортка да житәләр. Шуның өчен кан койдыкмы без? *(Елый.)* Их, иптәш Ысталин булсамы? Иптәш Ыста-лин! *(Үкереп елый.)*

Тиле Түрә. Син нәрсә үкерәсең, карт тиле?! Ил күптән юк бит инде! Энәсен дә калдырмый таратып бетерделәр.

Тиле Даһи. Элемтә! Элемтә! Уйларыңны күрәм! Илне талаучы безнең арада утыра! Контакт! Контакт! Хәбәр итәләр. Койрыгына баса башлагач, башын тилегә салып, монда кереп качкан. Аннан кара нур килә! Кара нур! Качыгыз! *(Идәнгә егыла.)*

Тиле Түрә. Тиле, валлаһи, шыр тиле! Кара, нәрсә сөйли бит! Нинди кара нур килсен миннән? Ябасызмы шуның авызын, юкмы, ә?! Табиблар кайда?! Җүләрләр йорты дигәч тә, җүләр дигәч тә, нигә кешегә теләсә нәрсә әйтәләр? *(Акырып.)* Судка бирәм!!!

Тиле Даһи *(башын күтәреп)*. Тилегә суд юк.

Табиб керә.

Табиб. Нинди тавыш? Нәрсә бүлешә алмыйсыз?

Тиле карт. Илне саталар әнә. Мин тиле башым белән аңлап торам — кычкыртып саталар. Безне монда китереп яптылар да, хәзер ни теләсәләр шуны эшлиләр. Җүләрләр йортын да сатсалар, мин кая барыйм ди хәзер? *(Елый.)*

Табиб *(телевизорны барып сүндерә)*. Ничә әйттем сезгә, ул депутатларны карарга ярамый, дип! Аларны карап, акыллың да тилерер. *(Тиле Картны юатып.)* Син елама. Җүләрләр йорты һәрвакыт кирәк булыр ул. Алга таба, бигрәк тә.

Ике Табиб Депутатны кертәләр.

Депутат. Мин протест белдерәм! Мин запрос ясаячакмын! Мин — халык депутаты, миңа кагылырга хакыгыз юк!

1 - Т а б и б. Тынычланыгыз зинһар! Сез бит интеллигент кеше. Үзегезнең тиле түгел икәнне, но... сәламәт икәнне исбат итүгә сез моннан чыгарсыз. Сезне... югарыдан да, врачлар да даими күзәтеп торачаклар.

Д е п у т а т. Тиле түгел икәнне?! Нәрсә, сез дә мине алар кебек *(телевизорга күрсәтә)* ычкынган дип уйлыйсызмыни?! Регламент! Мин жалоба бирәчәкмен!

2 - Т а б и б *(беренчесенә)*. Сез Депутат әфәндегә дөресен әйтеп бетермисез кебек? Аның монда махсус җибәрелүен...

1 - Т а б и б *(аны бүлеп)*. Аңа барысын да белү мәҗбүри түгел! Ул монда вакытлы — анысы факт. *(2-Табибка.)* Сез баш врачның әйткән сүзләрен онытасыз!

2 - Т а б и б. Әмма ул дөресен белсә, яхшырак булачак. Аннан шунысын да онытма — безнең язмыш та шушы йорт белән бәйләнгән.

1 - Т а б и б. Әйе. Әмма без моннан кайчан теләсәк, шунда чыгып китә алабыз, ә болар — мәңге монда. *(Китәләр.)*

Д е п у т а т. Мәңге монда?! Сез нәрсә, әфәнделәр, сез нәрсә?! Нигә барысын бер чыбыктан сөрәсез? Регламент! Мине бүлдермәгез! Миңа, мәсәлән, исбатлап торырга да кирәкми — мин тиле түгел! Ә әнә андагылар *(телевизорга күрсәтә)* барысы да ычкынганнар. *(Эчен тотып көлә башлый.)* Телисезме, лутчы мин аларның ычкынган икәнен исбат итәм? Мин бит тегендә аларны юри сыныйм, көн саен, сәгать саен яңа мәсьәлә күтәреп торам. Көтүләре белән минем арттан баралар!

Т и л е к а р т. Мин аны таныдым! Мин аны сакалыннан таныдым! Әйт, сине монда кем җибәрде?! Йөрәгем сизә — аны монда махсус җибәргәннәр — безне да сатарга! Тегендә сатып бетергән дә, хәзер монда килгән! Мин Маршал Советского Союза — команда бирәм — окружать!

Тиленәр Депутат өстенә килә башлыйлар.

Т а в ы ш л а р:

— Тилегә суд юк!

— Тилегә закон юк!
— Мин аны сакалыннан таныйм — ул да анда төп буталучы!
— Бир кирәген, йолык сакалын!
— Аны монда махсус җибәргәннәр! Махсус!
Тиле Даһи. Туктагыз! Хәбәр килә! Элемтә! Элемтә! Бу кешедә нидер бар! Хәтта мин дә бутала башладым — тегендә ул тиле булып күренә, монда — акыллы! Әйт, син кем?!
Депутат. Әфәнделәр! Әфәнделәр! Соң, күрмисезмени — депутат мин, де-пу-тат! *(Телевизорга күрсәтеп.)* Алар мине сынамакчы булдылар — алар уйлаганча, мин чынлап та тилеме, әллә... бөек акыл иясеме? Әле моны беркем белми. Мин биредә вакытлы гына, әфәнделәр!
Тиле Даһи. Без барыбыз да биредә вакытлы гына. Әмма күңелем сизә — аның белән нидер бәйләнгән! Ул биредә вакытта нидер булачак. Безгә хәзер аның кем икәнен ачыкларга кирәк.
Тиле Түрә. Берәр хәбәр килмиме соң шунда?
Тиле Даһи *(күккә карап)*. Дәшмиләр. Хәлиткеч мизгел. Кешелек үзе хәл итәргә тиеш. Коточкыч җаваплылык! *(Башын тотып, бөгәрләнеп ята.)*
Тиле карт. Ә мин беләм! Карт тилене алдый алмассың! Син хәзер безгә исбатларга тиешсең — безнең кебек үк тилеме син, әллә... Кремль шпионымы?! Ә?!

Тиләләр гөжләшеп алалар.

Депутат. Әфәнделәр! Нинди бәхәс булырга мөмкин? Әлбәттә, мин исбатларга әзер. Әмма мин моны болай гына эшли алмыйм. Кайда монда секретариат, кайда монда халык вәкилләре, радио, телевидение?! Миңа аудитория кирәк! Публика!
Тавышлар:
— Үзем публика булам!
— Ә мин — телевизор! Барысын да халыкка күрсәтәм!
— Мин депутат булам! Депутат!

Депутат. Монда барыбер кворум юк! Барыгыз да тавыш бирү хокукына ия түгел!

Тиле Түрә. Ә без кем? Әллә син һаман үзеңне бездән акыллырак дип беләсеңме?

Депутат. Сез... гафу итегез... сез бөтенләй башка!

Демократ *(кычкырып җибәрә).* Кеше хокуклары кайда монда?

Тиле Түрә. Без да синең кебек үк гражданнар! Паспортыбыз да бар, пропискабыз да! Гражданнармы без?!

Барысы да: «Гражданнар без, гражданнар!» дип кычкырыша башлыйлар.

Депутат. Шулай, шулай, әфәнделәр! Тынычланыгыз! Сез — гражданнар, без — гражданнар, алар — гражданнар. Кеше хокуклары ягыннан килеп караганда — без барыбыз да тигез!

Тиле карт. Ә без нәрсә дибез?! Башыңны тилегә салып торасың. Кворум дигәннәре бар, секретариат урынында утыра, микрофоннар эшли. Исбатла — тилеме син, юкмы?

Депутат. Әлбәттә, әлбәттә, монда хәзер тәртип бар. Әмма... рәис юк! Кем алып барыр сессияне? Ә?!

Тиләләр шаулашып алалар.

Тавышлар:

— Дөрес! Дөрес әйтә!

— Рәиссез булмый! Баш кирәк!

— Иң акыллы җүләр рәис булсын!

— Монда җүләрләр юк — барыбыз да акыллы!

Тиле Даһи. Туктагыз, тавыш кылә! *(Идәнгә ятып тыңлый.)* Безгә ярдәм итәргә телиләр. *(Бар да тынып кала.)* Алар әйтәләр — кем дә кем монда чыгып үзенең иң акыллы җүләр икәнен исбатлый ала, шул рәис булыр, диләр. Әмма хак дөресен сөйләргә кирәк, безне... югарыда тыңлап торалар.

Тиле Түрә. Барысын да чакырырга кирәк! Соңыннан тавыш чыгарлык булмасын. Күрше палаталардан да керсеннәр.

Берничә тиле чыгып йөгерә. Бераздан зал ти.:ләр белән тула башлый.

Тиле Хатын. Бәлки серне бу депутатка ачаргадыр?

Тиле Ир. Әмма ул бит — тиле!

Тиле Хатын. Шуны исеңнән чыгарма — монда тиләләр юк. Монда башка төрле уйлаучылар гына бар.

Тиле Ир. Анысы да дөрес. Ул парламентта бу мәсьәләне күтәрер иде.

Тиле Хатын. Искиткеч фикер! Юкка гына безнең икебезгә бер баш түгел шул!

Тиле Ир. Ул һичшиксез безне аңлаячак! Һәм бөтен дөнья безнең арттан китәчәк!

Зал тиләләр белән тула.

Тиле Даһи. Берәм-берәм чыгып әйтегез — син кем? Нәрсә өчен бирегә эләктең? Ни өчен үзеңне иң акыллы җүләргә санадсың?

Тиле карт. Мин — Маршал Советского Союза, карт тиле. Әмма ләкин мин иң акыллы җүләр!

Демократ. Әгәр ул үзен иң акыллы җүләр, дип исбат итсә, мин бу залдан чыгып китәм!

Тиле Даһи. Ни өчен син бу йортка эләктең?

Тиле карт. Сугышта җиңгән өчен. Берлинны аласы урында миңа Мәскәүне алырга кирәк булган. Шул башсызлыгым өчен хәзер монда утырам.

Тиле Даһи. Ә ни өчен үзеңне иң акыллыга санайсың?

Тиле карт. Чөнки мин телевизорны күп карыйм. Мин — иң карт тиле.

Бар да «аһ!» итә, «дөрес!» диләр.

Депутат. Регламент! Бер минут вакыты калды.

Тиле карт. Мин бөтен депутатларның исемнәрен беләм. Нәрсә әйтәселәрен беләм. Нәрсә әйтмичә калдырганнарын да беләм.

Тиле Даһи. Нәрсәне әйтмичә калдыралар инде алар?

Тиле карт. Ә, мине тиле дип белдеңме әллә дәүләт серен ачарга? Менә илне сатып бетерсеннәр әле, ул чагында әйтермен.

Тиле Даһи. Һи, карт тиле! Сатылып беткәч, синең әйтүеңнән ни файда? Утыр, тилелегеңне исбатладың.

Тиле Түрә. Мин үземне бик үк акыллы дип әйтмәс идем әйтүен...

Тиле Даһи. Алайса, нигә бастың?

Тиле Түрә. Ничек шушы тиленәрне хуҗа итәсең инде? Йөрәк түзми. Дилбегәне тагы үз кулыма алмый булмас.

Депутат. Тиле Түрә үзен иң акыллы дип исбат итсә, мин бу залдан чыгып китәм!

Тиле Даһи. Сөйлә, Тиле Түрә! Кем син, кайдан килдең, кая барасың?

Тиле Түрә. Мин — Первый! Аңлыйсызмы — Первый!

Тиле карт. Мин — второй!

Демократ. Ә мин — четвертый! Җитмәсә — Иван! Миңа сүз бирегез! *(Түргә менеп утыра.)*

Депутат. Регламент! Регламент! Карт тиле инде икенче тапкыр чыга! Нишләп сез сессияне җүләрләр йортына әйләндерәсез?!

Тиле Даһи. Утырыгыз! Без болай гомердә дә рәис сайлый алмыйбыз! *(Тиле Түрәгә.)* Синең чират, сөйлә! Ләкин первыеңны калдырып тор — син монда первый түгел, ә туксан тугыз! *(Чигәсен борып күрсәтә.)*

Тиле Түрә. Юк, мин туксан тугыз түгел, мин — Первый! Сез җүләрләргәме соң ул сүзнең бөек мәгънәсен аңларга! Минем каршыда барысы да биеп торалар иде! Өстәлгә бер генә китереп сугасың — тәрәзә пыялалары коелып төшә — мат перемат! Дурдом, билләһи! *(Көлә.)* Ә

ул заманнар кире кайтачак бит, барыбер кайтачак! Кайтачак!

Тиле Даһи. Утыр, шыр тиле икәнеңне күрсәттең. Җүләр булсаң да, кеше ышанмаслык сүз сөйләмә. *(Башын иеп, кайгы белән.)* Юк, сезнең арада рәис булырлык кеше юк! Барыгыз да шыр тиleләр. Ә бәлки Милләтчене Баш Тиле итеп куяргадыр? Алай дисәң, ул тилегә охшамаган?

Демократ. Милләтче рәис булса, мин сессияне ташлап чыгып китәм! Башкаларны да шуңа чакырам!

Тиле карт. Мин дә чыгып китәм! Ә чыгып, кая барабыз?

Тиле Түрә. Бу очракта мин дә тиле Демократка кушылырга мәҗбүрмен. Милләтчене рәис итсәк, барыбызны да милләтче ясап бетерә ул! Аннары, яшел байрак күтәреп, урамга гына чыгасы кала! Кирәкми безгә милләтчеләр!

Тавышлар:

— Милләтчелек кирәкми, җүләрләр булып кына калыйк!

— Ничек ул Баш Тиле булсын, ул бит башын гына тилегә сала!

— Аңа сүз әйтмәгез, ул бит патша! Ул — Сөембикә ханбикә!

— Алайса, аны Мәскәүгә сатарга кирәк!

Милләтче. Борчылмагыз, милләттәшләр! Мин Баш Тиле булырга да, тиле баш булырга да җыенмыйм. Һәркемнең үз урыны бар — хәтта җүләрләр йортында да!

Тиле Даһи. Ул хаклы. Әмма Баш Тиле юк! Күкләр дә дәшми. *(Бөгәрләнеп ята.)*

Депутат. Үзенә рәис тә сайлап куя алмаган парламентны, гомумән, таратырга кирәк. Парламентны таратырга!

Демократ. Отставка! Отставка!

Тиleләр: «Отставка!», «Отставка!» дип кычкыра башлыйлар.

Тиле карт. Туктагыз! Әнә телевизор эшләп тора, безне бөтен ил карый. Хурлык! Позор! Шундый бөек илдә рәис булырлык кеше юк.

Тиле Түрә. Бәлки... Менә бу икесенә бер башны рәис итеп куяргадыр? Чүтеки, икесенә бер баш, икесенә бер йөрәк, икесенә бер тел...

Тиле Ир. Ике...

Тиле Хатын. Ике...

Тиле Түрә. Нәрсә... ике?

Тиле Хатын. Телебез... ике. Йөрәгебез — бер, башыбыз — бер.

Тиле Даһи *(урыныннан торып)*. Ничек инде ул — бер башта — ике тел? Сез дә... тегеннән килдегезме әллә? Элемтә! Элемтә! Элемтә юк.

Тиле Ир. Сез аңламыйсыз! Безне тегендә дә аңламадылар! Ачышыбыз дөньяга таралмасын дип безне бирегә китереп яптылар.

Тиле Даһи. Биредә нәрсәдер бар. Сез бу мәсьәләне бүген күтәреп чыкмакчы буласызмы?

Тиле Ир. Әйе, без инде чыгыш ясарга язылдык.

Депутат. Ничек, язылдыгыз? Ә регламент? Ә рәис? Гомумән, без нәрсә өчен җыелдык монда?! Көн тәртибе кайда, көн тәртибе?!

Тиләләр шаулаша башлыйлар.

Тавышлар:

— Мине дә языгыз, беренче итеп!
— Милли мәсьәләне кайчан карыйсыз?
— Нинди милли? Баш турында уйларга кирәк монда!
— Ашау начар! Шул турыда сөйләгез!
— Бу җүләрләр йортын таратыр вакыт җитте.

Тиле Түрә. Соң, кайда язылasыз сез?! Әллә моны Югары Совет дип белдегезме? Җыелышны алып барырга рәис юк бит, рәис!

Демократ. Тарихның сәгате сукты! Миңа үз сүземне әйтер вакыт җитте! Сүзем шул — я бу бөек утырышны

таратырга туры киләчәк, моның нәтиҗәсе ни булыр — үзегез беләсез, я сез мине рәис итеп сайлыйсыз!

Депутат. Альтернатива бармы? Берничә кеше арасыннан сайларга кирәк!

Тиле карт. Ул бит инде болай да — дүртенче! Дүртнең берсе арасыннан сайлыйбыз да куябыз. Ләкин дүртенчесен түгел, беренчесен!

Демократ. Юк, мин — Дүртенче Тиле, то есть, Дүртенче Иван! Куркыныч Иван!

Тиләләр куркышып бер почмакка өеләләр.

Әмма мин Демократ Иван. Мин тиләләргә тимим.

Тиле карт. Демократ Иван диме?

Тиле Түрә. Демократ, ди, де-мо-крат.

Тиле Даһи. Я, әйт, алайса, син рәис булсаң, җүләрләр йортында яшәүчеләргә ирек бирәсеңме?

Демократ. Күпме телисез, шул хәтле ирек алыгыз! Тик җүләрләр йорты кысаларында!

Тиле Түрә. Ничек инде ул — җүләрләр йорты кысаларында?

Демократ. Шулай. Ирекле буласыз, әмма җүләрләр йортында каласыз.

Тиле карт. Безне җүләр дип белдең инде син, ә?! Соң, моның нәрсә икәнен җүләр дә аңлый бит — җүләрләр йорты булсын да, ирек тә булсын! Юк, моны рәис итәргә ярамый. Кычкыртып сатачак бу безне рәис булса, йортыңниең белән сатып җибәрер.

Демократ. Монда минем намусыма кагылалар! Мин залны ташлап чыгарга мәҗбүр булачакмын! Сезне дә шуңа чакырам! *(Ишеккә юнәлә.)*

Кинәт югарыда лампочка-күз яна.

Тиле Даһи. Күз яна! Күз!

Барысы да идәнгә егылалар. Югарыдан җүләрләр арасына тагы бер җүләр төшерелә. Аның авызы, күзе бәйләнгән. Йөзендә битлек сыман нәрсә.

Тиле Даһи. Күктән төште! Бу — хәбәр! Монда нидер бар! Күңелем сизә — ул иң акыллы җүләр!

Тиле Түрә. Әмма ул... телсез!

Тиле Даһи. Бәлки бу яхшыгадыр да? Акыллының башына теле җитәр.

Тиле карт. Әмма ул... сукыр да!

Тиле Даһи. Җүләр күп күрмәс. Иң акыллы җүләр — сукыр, телсез, чукрак җүләр. Җүләрләрнең рәисе дә нәкъ шундый кеше булырга тиеш. Тик ул... тимер кебек салкын. А-а-а! Мин өшим, туңам!

Депутат. Әмма, әфәнделәр, бераз сәеррәк бу! Сүз минс хөкем итү турында бармаса, бәлки мин дә ризалашыр идем. Әмма монда минем язмышым хәл ителә!

Демократ. Сез борчылмагыз, депутат әфәнде! Аның шулай телсез, чукрак, сукыр булуы безнең өчен файдалырак та. Безгә нәкъ шундый кеше кирәк иде! Югарыда кемне төшерәсен яхшы беләләр. Аның эше — утырып тору, ә хөкемне без үзебез чыгарырбыз.

Тиле Даһи. Аның өстән төшкәнен дә онытмаска кирәк. Ул рәис эшен генә башкара ала. Аны хәзер беркая куеп булмый. Әмма... ул тимер, тимер! Мин өшим...

Демократ. Караласы мәсьәләләр күп. Рәис — бар. Җүләрләр кворумы — бар. Көн тәртибе — бар. Утырышыбызны башлыйбыз. Көн тәртибендә беренче мәсьәлә...

Баш Тиле аңа язу тапшыра.

Көн тәртибендә беренче мәсьәлә... при-пра-кум...

Депутат. Әфәнделәр! Көн тәртибендә беренче мәсьәлә — при да түгел, пра да түгел, минем мәсьәлә!

Тавышлар:

— Юк, минем мәсьәлә!

— Мин кичә үк язылып куйдым!

— Минем мәсьәлә! Минеке!

Демократ. Рәис сүзе сүзме, сезнең сүз сүзме?! Монда бик ачык итеп әйтелгән — көн тәртибендә беренче мәсьәлә — при-пра-при-ва-ти-за-ция!

Тиле карт. Анысы нәрсә тагын?! Пи-ра-па-ра-паразитация?! Үзебезчә әйт!

Демократ. Үзебезчә булса — көн тәртибендә беренче мәсьәлә — җүләрләр йортын сату!

Тиле карт. Сату?! Ә без кая барабыз?!

Барысы да катып кала.

Телсез сәхнә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

(Уен)

Вакыйга шул ук урында бара.

Демократ. Көн тәртибендә беренче мәсьәлә — җүләрләр йортын сату. Кемдә нинди тәкъдимнәр бар?

Депутат. Туктагыз әле, әфәнделәр! Көн тәртибендә мондый мәсьәлә юк иде бит! Без бирегә нәрсә өчен җыелдык? Минем сорау буенча җыелдык бит! Мин сезнең алда үземнең шәхесемне ачыкларга тиеш идем.

Тиле Түрә. Иптәшләр! Мин, нигездә, сатуга каршы түгел. Әмма кем сатып ала ала? Һәр җүләрнең йорт сатып алырга хакы бармы? Башта шуңа җавап бирегез.

Тиле Даһи. Һәр җүләр йорт сатып ала ала. Бушка бирсәләр.

Тиле Түрә. Бушка бирсәләр... мин алам!

Тавышлар:

— Нигә аңа бирәсез, мин алам!

— Минем дә өлешем бар бу йортта, мин монда гомер буе яшим!

— Менә бу почмагы — минеке!

— Алды, алды! Территориямне алды! А-а!

Тиле карт. Менә, башланды. Әйттем мин. Бу депутат кисәген бирегә юкка җибәрмәгәннәр, дип. Сата, әнә, кычкыртып сата!

Депутат. Мин протест белдерәм! Һәм миннән гафу үтенүләрен таләп итәм. Бу тәкъдимемне исемләп тавыш бирүгә куюыгызны сорыйм.

Демократ. Без тагы көн тәртибеннән читкә китәбез. Тынычланыгыз, әфәнделәр! Сезгә җайлы булсын өчен, җүләрләр йорты бушлай таратылмый, ә сатыла. Ә сатып алырга сезнең акчагыз юк.

Тиле Даһи. Ул хаклы! Ул искиткеч акыллы сүз әйтте! Бушка таратсалар, без сугышып бетәбез, ә сатсалар — җан тыныч, беребездә дә акча юк. Акыллы эш!

Җүләрләр барысы да Демократка карыйлар.

Демократ. Әфәнделәр, борчылмагыз! Барысы да уйланылган. Әйтик, җүләрләр йортын сатып җибәрдек, ди. Аны Америка байлары алырмы, немецлармы — анысы ачыкланыр. Әмма — нинди киләчәк! Һәр җүләр саен аерым бүлмә, компьютерлар, бассейннар! Эшләмичә ашап, мич башында гына ятасың!

Тавыш:

— Анда мич башы булырмы соң?

Демократ. Булмаса, ясарбыз. Безнең ризалык кына кирәк. Сатабызмы, әфәнделәр?!

Тиләләр барысы да «Сатарга!», «Сатарга!» дип кычкыра башлыйлар.

Тиле карт. Туктагыз әле, иптәшләр! Мин карт солдатны болай гына алдый алмассыз! Ничек безне шулай тәккә генә ашатып яткырырлар икән соң ул Америка байлары? Ә?

Тиле Даһи. Мин беләм! Мин кәгазьләрен күрдем! Һәр тиленең башы өчен бер тонна нефть бирелә! Җир астындагы бөтен байлык тиләләр санынча бүленеп беткән.

Тиле карт. Ә нефть бетсә?

Демократ. Нефть бетсә — газ бар, газ бетсә — урман бар, урман бетсә — җир бар! Җир бетсә — халык бар! Барысын да сатабыз! Моны Иван әйтә!

Депутат. Туктагыз әле, әфәнделәр! Ә мин? Минем мәсьәлә? Алайга китсә, мин сессияне өзәргә тәкъдим итәм!

Тиле Түрә. Рәис әфәнде! Сез бу тиле депутатны туктатасызмы, юкмы? Монда дәүләт, ил турында сүз бара, ә ул һаман чүпкә ярамаган нәрсәләр белән башны катыра?! Карале, демократ энем, бу йортны без үзебез генә сатып ала алмыйбызмы соң? Америкага әрәм итмәскә иде бит бу йортны. *(Кесәләрен капшый.)*

Демократ. Кем ул — без үзебез генә?

Тиле Түрә. Без дип торабыз инде...

Демократ. Ну, агай...

Депутат. Регламент буенча минем әле ике минут вакытым бар! Монда минем язмышым хәл ителә, ә сез: ил, дисез! Миңа моннан чыгарга кирәк! Ә сез теләсә нишләгез! Хет айга очыгыз җүләрләр йортыгыз белән! Минем мәсьәләне исемләп тавыш бирүгә куюыгызны сорыйм.

Тиле Даһи. Айга очу мәсьәләсен исемләп тавышка куябыз!

Тавышлар:

— Очабыз!

— Очмыйбыз!

— Очабыз!

Тиле Түрә. Бу ниткән хәл инде бер мәсьәләдән икенчесенә сикерү? Кайда бар тагы шундый хәл? Сатарга икән — сатарга! Кемгә сатасын гына хәл итик тә, беттекитте.

Тиле Даһи. Әйттем мин — син башыңны тилегә саласың, дип! Әмма... өстән барысын да күзәтеп торалар. Сыныйлар! Сыныйлар! Сыныйлар!

Тиле Ир. Әфәнделәр! Биредә һаман бер үк кешеләр чыгыш ясый. Әмма закон алдында без барыбыз да тигез бит! Без иртән үк фикер алышуга язылып куйган идек! Бу мәсьәләне бары тик биредә генә хәл итәргә мөмкин. Һәм без аны беренче итеп көн тәртибенә куюны сорыйбыз.

Тиле Даhи. Ул нинди мәсьәлә? Күкләрнең моңа ризалыгы бармы?

Тиле Хатын. Нәкъ менә күкләр бу нәрсәдән курка шул! Дөнья искиткеч ачыш алдында тора! Безнең мәсьәлә буенча бирелә тиешле закон кабул ителсә... бу дөнья бетә! Башкасы барлыкка килә!

Тиле Түрә. Алыгыз шул тиленәрне микрофон яныннан! Кем алып бара бу сессияне?! Нишләп җыен тилегә сүз бирәсез?! Шуны тыңлау өчен бирегә җыелдыгызмыни? Сатарга икән, сатарга дип документ кабул итик. Кемгә сатасын соңыннан да ачыклый алабыз.

Демократ. Дөрес! Мин дә протест белдерәм! Без инде күпме бәхәсләшәбез, ә төп мәсьәлә hаман каралмаган. Кичекмәстән, төп мәсьәләгә күчәбез!

Тиле Хатын. Юк, безнең мәсьәләгә күчүне таләп итәбез! Тавышка куегыз! Тавышка! *(Җүләрләргә.)* Тавышланыгыз! Тавышланыгыз!

Зур тавыш куба. Йөгереп Табиблар керә.

1-Табиб. Болар чын-чынлап тавышлана башладылар бит!

2-Табиб. Шулай каралган. Нишлисең, барысын да ачыкларга кирәк.

1-Табиб. Әмма җүләрләр йортында мондый хәлнең булганы юк иде әле! Тыңлап торсаң, үзең үк саташасың — кайда җүләрләр дә, кайда акыллылар.

2-Табиб. Безне күргәч, бераз тынычландылар. Кызганыч та үзләре. Әмма безнең эш — күзәтү, катнашмау. Демократия, туган. Хәтта җүләрләр йортында да. Кирәк булса, ярдәм итәрбез.

1-Табиб. Соң булмасын. Монда без дә аңлап бетермәгән уен бара кебек. Күрәсеңме аларны, әйтерсең лә, махсус ярсыталар. Ә күз күзәтә.

2-Табиб. Күз аларны гына түгел, безне дә күзәтә ул. Күп сөйләшсәң, күп күрсәң, күз ачып йомганчы болар арасында булырсың.

1-Т а б и б. Әйе, безнең эш — хәзергә катнашмау.

Чыгалар.

Д е м о к р а т. Тавышларны санадык — сезнең тавыш җиңде. Сөйләгез. Регламент буенча 5 минут вакыт бирәбез.

Т и л е Х а т ы н. Бишәр.

Д е м о к р а т. Нәрсә — бишәр?

Т и л е Х а т ы н. Бишәр минут вакыт бирәсез. Без бит — икәү.

Д е м о к р а т. Әмма сезнең икегезгә бер баш бит!

Т и л е Х а т ы н. Ә телебез — икәү.

Д е м о к р а т. Патша башың белән шушы җүләрләрне көйләп тор инде! Нинди тарихи гаделсезлек! Сөйләгез, диваналар. Халык бераз ял итәр.

Т и л е И р. Без искиткеч ачыш ясадык! Әмма аны ачсак, дөнья яшәүдән туктый.

Т и л е к а р т. Алайса, нигә монда атылып чыктың соң? Сүндерегез микрофонын.

Т и л е Х а т ы н. Юк, юк, сүндерә күрмәгез! Башта безне тыңлагыз. Безне барлык җирдән дә куалар, тыңламыйлар. Җүләрләрнең аңлавы — безнең соңгы өметебез.

Д е м о к р а т. Бер минут вакытыгыз калды!

Т и л е И р. Ничек?!

Т и л е Х а т ы н. Бер минутта моны сөйләп бетереп буламы?! Аны аңлатырга бер гомер дә җитми бит!

Д е п у т а т. Сөйләсеннәр! Мин үз вакытымны аларга бирәм.

Д е м о к р а т. Сезнең вакытыгыз күптән бетте инде, депутат әфәнде!

Д е п у т а т. Мине тилегә санамагыз! Ачыгыз да регламентны карагыз — бу мәсьәлә буенча фикер алышуда мин өч минут сөйли алам. Мин үз вакытымны аларга бирәм!

Т и л е Х а т ы н. Рәхмәт, депутат әфәнде! Сез биредә иң акыллы җүләр! Сөйлә, җаным!

Тиле Ир. Без галәмнең кешеләрдән яшерен бер серен ачтык. Кешелек дөньясының башта каралган проекты буенча, һәр кеше дөньяга үзенең пары белән килә, ягъни, һәрберебезгә туганда ук күкләр тарафыннан үз пары билгеләнеп куела. Ул иртәрәк туарга мөмкин, соңрак туарга — анысы мөһим түгел. Иң мөһиме — алар бу дөньяда вакытта бер-берләрен табарга тиешләр. Аңлыйсызмы? Башта ул шулай булган да. Әмма ләкин андый парлар бер-берсен тапкач, алар өчен бар дөнья яшәүдән туктый. Алар бер-берләреннән башка берни күрмиләр.

Тиле Хатын. Моны мин үзебездән беләм. Без берберебезне 30 ел буе эзләгәнбез! Күпме ялгышлар эшләнгән, күпме өметсезлек, гомерне бушка сарыф итү! Чөнки беләсең — син күкләр тарафыннан иңдерелгән парыңны очратмадың!

Тиле Ир. Һәм беркөнне ул очрый! Син аны меңнәр, миллионнар арасыннан танып аласың — аның йөзеннән нур бөркелеп тора. Ул нур сине үзенә тарта, сине үзенә чорнап ала, иркәли, изрәтә, елата һәм... үзеңне дә нурга әйләндерә. Син тәнеңне тоймыйсың, син үзең дә җылы нурга әйләнәсең.

Тиле Хатын. Һәм шул минуттан ни өчен дөньяда яшәвеңне аңлыйсың. Галәм сиңа үзенең бөек серен ача! Нур белән бергә, сиңа күктән җан иңә! Аңа хәтле син — тән генә, парын очратмаган кешеләрдә җан түгел, тән генә була. Җан белән бергә кешеләргә канатлар иңә. Дөньяга башка төрле күз ачыла.

Тиле карт. Нинди... күз?

Тиле Хатын. Күңел күзе ачыла. Үз парын тапкан кеше дөньяга бөтенләй башка күз белән карый башлый. Ләкин бу бер яктан — бәхет, икенче яктан — фаҗига да. Бәхет — чөнки табигатьтә барган бөек яратуны күрәсең. Иртән чәчкәләрнең тыгыз җилдән иркәләнеп ачылуларын, бәхеттән, ләззәттән тын гына елауларын күрәсең. Моны үзе дә яраткан кеше генә күрә ала. Бөҗәкләрнең, балыкларның, бакаларның, еланнарның үз парларына сарылып,

бәхеттән түзә алмыйча ыңгырашуларын ишетәсең. Табигатьтәге ярату хәтта кешеләрдә дә юк! Үз парын тапкан кеше генә шулай ярата ала!

Тиле Ир. Ләкин күңел күзе ачылуның фаҗигале ягы да бар. Кешелек дөньясының коточкыч ялгыш юлда икәнлеген, аның үз фаҗигасенә баруын күрәсең. Кешеләрнең бәхетсез, мескен икәнлекләрен күрәсең. Үз парын тапкан кешегә байлык та, дәрәҗә дә, хәтта нәсел калдыру да кирәкми. Алар бер-берләре өчен генә яшиләр.

Тиле карт. Ничек инде — нәсел калдырырга кирәкми? Ә кешелек ничек дәвам итәр?

Тиле Хатын. Менә шуны аңлап, күкләр кешеләрне бу бәхеттән, бу могҗизадан мәхрүм иттеләр дә инде. Кешеләрне байлыкка, дәрәҗәгә, нәселгә бәйләделәр, күңел күзләрен шулар белән томаладылар. Иң мөһиме — нәсел калмау белән куркыттылар. Ә табигатьтә нәсел дәвам итә бит! Дөньяга килгән һәр бөҗәк, һәр үлән, һәр киек үзе яшәр өчен тырыша!

Тиле карт. Ягъни, аларны дөньяга китерүчеләр берни өчен дә җавап бирми булып чыга?

Тиле Ир. Дөньяга китерү — үзе иң зур җаваплылык. Ата-ана гомер буе балаларының колы булырга тиеш түгел. Кемнең, нәрсәнеңдер колы булу белән кеше яшәүдән туктый. Балалар да нәсел дәвам итәргә әхлакый яктан әзер булмыйлар, чөнки алар көрәшеп яшәргә өйрәнмәгән.

Тиле Хатын. Без шундый ачыш ясадык — кеше кол булу өчен түгел, ярату өчен туган. Һәм дөньяны бары тик ярату гына коткарачак. Без моны кешеләргә аңлата башладык. Югарыдагыларга бу ошамады — аларга, дөньяны чистарту өчен, сугышлар да кирәк, кешеләрнең байлык артыннан куулары, дан-дәрәҗә өчен көрәшүләре дә кирәк — чөнки алар: көндәшлек, конкуренция дөньяны прогресска китерә, дип уйлыйлар. Алар уйлавынча, кешеләр үз парларын табып, гомерләрен бөек яратуга гына багышласалар, дөнья яшәүдән туктап, башка юнәлешкә кереп китәчәк. Ә күкләр дә, Җир дә әле моңа әзер түгел...

Демократ. Сезнең вакытыгыз бетте. Хәзер төп мәсьәләгә күчәбез.

Тиле Хатын. Ничек — төп мәсьәләгә? Ә без?

Демократ. Сезне тыңладык. Бик күңелле булды. Әмма көн үзәгендә бүген бөтенләй башка мәсьәлә.

Тиле Ир. Юк, юк, болай сөйләшеп кенә таралырга һич ярамый. Без үзебезнең ачыш буенча Закон, һич югы карар кабул ителүне сорыйбыз. Югыйсә, безгә мәңге моннан чыгу юк — барысы да безне җүләр дип уйлаячак! Без кешеләрне коткарырга тиешбез!

Тиле Даһи. Алар хаклы. Әмма моңа хәзергә күкләрнең рөхсәте юк. Болар үзләренең ачышларын нәкъ мең елга алдан ясадылар! Хәбәр иттеләр! Хәбәр иттеләр! Вакыты җитмәгән.

Тиле карт. Монда Закон кабул итү турында сүз дә булырга мөмкин түгел! Ничек инде ул — тап та ташла! Үз көнен үзе күрсен, имеш. Ә солдатларны кем табып, тәрбияләп үстерер? Кем җиңәргә, дошманны үтерергә өйрәтер? Кем Берлинны алыр? Барысы да ярату белән генә мавыкса? Моның артыннан йөргән кешеләр — шыр тиләләр. Җитте җыен җүләр сүз тыңлап утырырга.

Тиле Түрә. Соң алардан нәрсә аласың, аларның икесенә бер баш бит!

Тиле Хатын. Әйе шул, безнең икебезгә бер баш, икебезгә бер йөрәк...

Тиле Ир. Без кешеләрне коткара алмадык...

Демократ. Карар проекты әзер. Һәр җүләрнең «мин риза» дип кул куюы кирәк.

Тиле карт. Нәрсәгә... риза? Ә мин кайдан пар табыйм?!

Демократ. Әфәнделәр! Сез мине кабатланырга мәҗбүр итәсез! Бүген көне буе сүз җүләрләр йортын сату турында бара... Пар турында түгел!

Тиле карт. Юк, мин риза түгел! Мин кая китим ди, җүләрләр йортын саткач! Кара син, җүләр тапканнар, аңа гына баш эшли әле минем!

Д е м о к р а т. Сатмасаң, сатмыйм, дип кул куярсың. Бездә демократия.

Д е п у т а т. По ведению! Сүз сорыйм. Мәсьәләне көн тәртибенә куйганчы, башта референдум үткәрергә кирәк.

Тиләләр «Референдум! Референдум!» дип кычкыра башлыйлар.

Д е м о к р а т. Референдумда барлык җүләрләр катнаша аласына тулы гарантия бармы? Ә мин андый гарантия күрмим.

Д е п у т а т. Демократ әфәнде! Мин сезне танымыйм! Сез беренче булып референдум яклы булырга тиеш идегез!

Д е м о к р а т. Тиле әфәнделәр! Тиле әфәнделәр, туктагыз! Мәсьәләне референдум аша хәл иттең ни, биредә имза җыеп хәл иттең ни, аннан берни үзгәрми. Чөнки йорт инде сатылган, бары тавышка куеп, законлаштырасы гына калган.

Т и л е Т ү р ә. Ничек — сатылган?! Ә мин?

Д е м о к р а т. Соң, бергәләп хәл иттек бит! Көн буе шул турыда сөйләштек.

Т и л е к а р т. Ә мин кая барам? Мине кем сатып ала? *(Зал буенча әрле-бирле йөри башлый.)*

Д е м о к р а т. Карарның проекты белән таныштырам... «Җүләрләр йорты сатылды. Җүләрләр йортына өстәп, ул урнашкан мәмләкәт, ул мәмләкәттәге җир-сулар, ул җирдәге халык та сатып җибәрелде». Кемдә нинди фикерләр бар?

Д е п у т а т. Әлбәттә, карар проекты бик җыйнак эшләнгән. Әмма халыкны социаль яктан яклау гарантияләнмәгән.

Т и л е к а р т. Депутат башың белән шул хәтле тиле булырсың икән, әй! Соң, сатылган мал нәрсә белән гарантияләнсен? Чыбыркы да таяк, ачка үлмәс өчен бер уч он.

Т и л е Т ү р ә. Син, туган, түрдә утырасың икән, өздереп әйт. Йорт сатылгач, без кая китәбез? Шунсыз бу кәгазьгә кул куярга ярамый.

Демократ. Йорт сатылгач, без ирекле! Дөньяның кайсы почмагына телибез — шунда китәбез! Бөтен ишекләр ачыла — җүләрләр йортыныкы да, мәмләкәтнеке дә, дөньяныкы да! Менә бу демократия була инде, дивана әфәнделәр!

Тиләләр гаять шатланып, зал буенча йөри башлыйлар.

Тавышлар:
— Мин Америкага китәм! Индеец булам!
— Мин — Япония императоры!
— Мин Әтнәгә колхоз председателе булып кайтам!
— Син көтүче булырсың, син көтүчегә охшаган!

Тиләләр Демократ янына килеп, ашыгып-ашыгып кул куялар.

Демократ. Ашыгыгыз! Тарихта яңа чор башлана! Тиләләр кулы белән Җир шарын сатып җибәрәбез! Демократия! Менә сезгә демократия! Менә сезгә демократия!

Милләтче. Туктагыз! Бу уен чынга охшый башлады. Авырулар белән мондый тәҗрибә уздырырга кирәкмәс иде, демократ әфәнде! Күрәсезме, ничек ярсыттыгыз үзләрен! Бу тамашаны күзәткән саен, күңелгә шик керә бара — нигә дип җыясыз сез аларның имзаларын? Алар бит авырулар, нәрсәгә кул куйганнарын да аңламыйлар!

Демократ. Гафу үтенәм, бу нинди демагогия?! Сез кемнәрне авырулар дисез инде? Бәлки сез «җүләрләр» дип тә әйтергә теләгәнсездер әле? Ишеттегезме, милләтче сезне — үзенең милләттәшләрен — җүләрләр дип атый! Ә кеше хокуклары кайда?! Нәрсә, болар кеше түгелме?! Аларның дәүләт байлыгын сатуда катнашырга хакы юкмы? Болар халык түгелме?!

Җүләрләр ярсый башлый.

Тавышлар:
— Хакыбыз бар! Без — халык!
— Без дә тулы хокуклы гражданнар!

— Бу байлыкта безнең өлеш тә бар!
— Тиенләп бүләбез!
— Без хәзер җүләрләр түгел — гражданнар!
— Юк, син — җүләр, ә мин җүләр түгел! Граждан-ин!

Үзара сугыша башлыйлар.

Тиле Даһи. Туктагыз! Эш эшләнде — хәзер дөнья бетә! Астан тавыш килә! Гүли. Тирә-як җимерелеп килә. Тиздән безгә дә килеп җитә. Дөнья бетә! Тәүбә итегез! Тәүбә! Тәүбә!

Өстә лампочка-күз янып ала.
Йөгерешеп Табиблар керә.

Милләтче *(алар янына килеп)*. Зинһар, ярдәм итегез! Монда ниндидер мәкерле уен бара! Нигә ул җүләрләрнең имзаларын җыялар? Монда нәрсәдер бар!

Демократ *(җүләрләргә)*. Алыгыз бу милләтчене! Ул сезне ач калдырырга җыена! Ул сезнең ирегегезгә каршы! Ул милләткә түгел, мафиягә эшли! Җүләрләр йортындагы бу хәлгә ул гына гаепле! Үзегез күреп тордыгыз — халыкны ул котыртты!

Җүләрләр үкереп Милләтче өстенә килә башлыйлар.

Милләтче *(Табибларга)*. Сез бит — табиблар! Берәр чарасын күрегез! Коткарыгыз халыкны котырудан!

1-Табиб. Туктагыз! Тынычланыгыз!

2-Табиб. Сез — авырулар, сезгә кызарга ярамый! Туктагыз!

Җүләрләр Табиблар өстенә килә башлыйлар.

Тавышлар:
— Безме авырулар? Без — ирекле гражданнар!
— Әле сез безне тиле дип тә уйлыйсыздыр?!
— Сезгә безнең дәүләт эшләрендә катнашуыбыз ошамый!
— Без — халык! Мал бүләргә тулы хокукыбыз бар!

— Без дәүләтне сатабыз да өч көн тук яшибез.
— Аннан Америкага китәбез!
1-Табиб. Туктагыз! Бу — уен гына, сынау гына иде. Бернинди сату, мал бүлү юк.
Тавышлар:
— Ә, әле сез безнең белән уйнарга телисезме?!
— Безнең мал бүлүебез сезгә ошамыймы?
— Үзләренә өлеш чыкмады, шуңа шаулыйлар!
— Изегез үзләрен, бетерегез!
1-Табиб. Сезне алдадылар! Бу уен гына, уен... *(Егыла.)*
2-Табиб. Туктагыз! Без сезнең табибларыгыз! Сез безне юк итәсез икән, сезне кем дәвалар, кем ашатыр, кем карар? Сез бит — авырулар, безне юк итү белән, үзегез дә бетәрсез. Монда сезнең белән коточкыч сынау уздыралар. Бу югарыдан — Баш Палачлар тарафыннан эшләнә! Безнең бер генә гаебебез бар — белә торып, сезгә шуны әйтмәдек! Табиб була торып, шушы вәхши сынауга ирек бирдек!
Тавышлар:
— Әле алар безне сыныйлар?!
— Һаман тилегә саныйлармы?!
— Бетерегез үзләрен! Барысы өчен үч алыгыз!

Табибларны идәнгә егып, таптый башлыйлар. Идәндә аларның җансыз гәүдәләре ятып кала. Ул гәүдәләрне, аякларыннан тотып, чыгарып аталар.
Өстә лампочка-күз яна.
«Баш» Тиле битлеген сала.

«Баш» Тиле. Уен тәмам, әфәнделәр.
Тиле Даһи. Тимер телгә килде. Димәк, дөнья бетә! *(Егыла.)*

Барысы да куркып идәнгә егылалар.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

(Хөкем)

Вакыйга шунда ук дәвам итә.

«Баш» Тиле. Уен тәмам, әфәнделәр!

Тиле Даһи. Могҗиза! Ул телгә килде! Битлеген салды!

Тиле карт. Иптәш Сталин! Алла бар! — Ул аны терелтте. Хәзер бирелә тәртип булачак. Иптәш Сталин! Мин сезгә рапорт бирәм...

Тиле Түрә. Нишләп Сталин булсын ул сиңа?! Күрмисеңмени, мыегы юк? Ләкин күңелем сизә — бу безнең кеше, үзебезнең сала мужигы.

Тиле Даһи. Ятыгыз! Аннан кара нур килә! А-а-а! Кара нур килә! *(Бөгәрләнеп идәнгә егыла.)*

«Баш» Тиле. Башыгызны тилегә салмаска да мөмкин, әфәнделәр. Кемнең кем икәнлеге бик яхшы күренде бу уенда. Сиңа, халык депутаты, рәхмәт әйтергә кирәк — эшеңне яхшы башкардың.

Депутат. Миңа?! Әфәнделәр! Монда нәрсәләр бутыйлар! Мине парламенттан мәҗбүри алып киттеләр, вакытлыча, диделәр. Мин сезнең кара эшләрегездә катнашмыйм! Мине бирелән чыгаруыгызны таләп итәм!

Тиле Түрә. Карале, иптәш, кем дип әйтим соң, үзебезнең кешегә дә охшагансың. Безнең бирелә кыланганнарны алай-болай язып бармаганнардыр бит?

«Баш» Тиле. Сез бөтен дөнья каршында уйнадыгыз. Бөтен дөнья каршында җавап та бирерсез.

Тиле Түрә. Без — тилеләр! Тилегә суд юк! Муеныңнан асып куям мин сине, анаңны корт чаккыры демократ! Син бутадың бөтенесен! Сатыла, имеш, аерым бүлмәләр, имеш! Нинди аерым бүлмә буласын чамалыйсыңмы син хәзер, ә? Чамалыйсыңмы, демократ кисәге?!

Демократ. Миңа нәрсә, миңа демократия булсын! Соңыннан ник барыгызны да төрмәгә утыртып бетермиләр шунда!

Тиле Түрә. Төрмә? Ни сөйли ул?

«Баш» Тиле. Әфәнделәр! Югарыдан килгән әмер буенча, без сезнең белән сынау уздырырга мәҗбүр булдык. Почему, потому что башын җүләргә салып, бирегә килүчеләр күбәйгәннән-күбәя бара. Кем хөкемнән кача, кем үз-үзеннән. Ниһаять, бу уеннан соң кемнең кем икәне яхшы ачыкланды. Әлбәттә, күпләрегезне гадел хөкем — төрмә көтә. Әмма сез борчылмагыз — без барысын да закон нигезендә эшләрбез! Кемнең кем икәнен үзегез әйтегез, бүген бер-берегезне үзегез хөкем итегез. Почему, потому что, без демократия яклы. Барысын да халык хөкем итә.

Тиле карт *(уртага чыгып)*. Мин бу минутны гомер буе көттем! Һәм хәзер үз сүземне әйтәм. *(Тиле Түрәгә күрсәтә.)* Иң башта менә моны хөкем итәргә кирәк! Мин аны күп күзәттем. Сынадым. Мин карт төлкене алдый алмассыз! Бу адәм тиле түгел! Ул башын тилегә салып кына йөри. Тегендә барысын да сатып, урлап бетерде, хәзер монда килгән. Кара син аны, хәтта җүләрләр йортын да сатып алмакчы! Трибунал аңа!

Тавышлар:

— Трибунал! Атарга!

— Безне сатып җибәрергә уйладыңмы?!

— Мафия! Черный рынок!

— Из, сыт, бетер үзен!

Барысы да Тиле Түрә өстенә киләләр.

«Баш» Тиле. Туктагыз! Барысын да Закон нигезендә эшләргә кирәк! Ә безнең Закон буенча, аның әле бер мөмкинлеге калды — ул үзен яклап соңгы сүзен әйтә ала. Башын тилегә салган икән, аны алда төрмә, иң югары җәза көтә. Әгәр ул үзенең тилелеген, шыр тилелеген исбатлый ала икән, ул исән кала. *(Тиле Түрәгә.)* Сөйлә, кем син?

Тиле Түрә. А-а-а! Тиле мин, шыр тиле! Шыр тиле булмаган кеше бу ил мәңге җимерелмәс, мин гомер буе түрә булып калырмын, дип ышанып ятамы? Шыр тиле булмаган кеше ил җимерелгәндә җүләрләр йортына качып котылмакчы буламы?! Шыр тиле булмаган кеше, башын тилегә салып, алар белән кәмит корып йөриме?! Моннан җиңел генә чыгып котылырмын, дип уйлыймы? Тиле мин, шыр тиле, яһүд кебек, таларга-җимерергә дә качарга иде миңа бу илдән! Хәзер миллионер булып ятар идем анда! Минем бирегәге байлыгымнан ни файда — барыбер җыен җүләр кулына кала, бер атнада сатып-эчеп бетерерләр! А-а-а! Тиле мин, шыр тиле, тиле! *(Елап, идәнгә егыла.)*

Барлык тиләләр аның тирәсенә җыела.

«Баш» Тиле. Син ышандырырлык итеп сөйләдең! Синең кебек шыр тиле генә бу илдә шулай гамьсез яшәргә мөмкин. *(Кәгазь суза.)* Менә монда «мин шыр тиле» дип кулыңны куй.

Тиле Түрә *(урмәләп килеп)*. Куям, куям! Сөенә-сөенә куям! Монда мин үз тиңнәрем арасында. Мин аларның барысын да яратам. *(Кул куя. Аягүрә баса, кукрәген киерә)*. Ә менә моны *(Демократка күрсәтә)* күралмыйм! Алар бутады барысын да! Аның урыны — төрмәнең түрендә! Себердә! Гулагта!

Демократ. Консерватор! Партаппарат! Башыңны җүләргә салып котылмакчы буласыңмы! Әле, житмәсә, демократиягә тел тидерә.

Тиле Түрә. Синме — демократ? Карагыз, бу — демократмы? Аның әле кемлеген, чын йөзен беркем белми — аның милләте дә билгесез, теле дә, дине дә, кемгә хезмәт итүе дә! Моисейга хезмәт итәме ул, әллә Ивангамы? Акчаны кемнән ала — Мәскәүдәнме, әллә Израилдәнме? Ә? Менә сиңа демократ, менә сиңа кеше хокуклары! Менә шулар болгатты барысын да, менә шулар бөтен җиргә баш булып алды, менә шулар илнең байлыгын җилгә очырды! Без дә урладык. Әмма безнең урлаган белән әле

тагы 70 ел яшәргә була иде! Болар — берничә айда Америкага сатып бетерделәр! Аның урыны — төрмәдә!

Җүләрләр ярсып Дёмократ өстенә ташланалар.

Демократ. Соңгы сүз! Соңгы сүз! Кайда монда демократия, тигезлек! Аңа соңгы сүзне бирдегез, ә кайда минем кеше хокукларым?!

«Баш» Тиле. Ул дөрес әйтә. Бездә — демократия. Аңа да үзенең шыр тилелеген исбатларга мөмкинлек бирергә кирәк! Бары тик шул гына аның гомерен саклап кала ала! Юк икән — аны үлем җәзасы көтә.

Тавышлар:

— Дөрес! Ул иң куркыныч бәндә!

— Ул безнең бөтенебезне талаштырып бетерде!

— Ул — башын демократка салган шовинист!

— Юк, ул башын шовинистка салган демократ!

— Аны монда ук юк итәргә кирәк!

Барысы да Демократ өстенә киләләр.

Демократ. Әфәнделәр! Кызганыгыз мине! Мин бит барысы да яхшы булсын өчен генә тырыштым! Хәзер аңладым — шыр тиле булганмын! Миңа бер яктан, син — Соломон улы, дөньяда иң бөек милләт, дип сеңдерделәр, шул идеяне дөньяга тарату өчен зур акчалар тоттылар. Төп дошманымның кем икәнен күрсәттеләр. Әмма икенче яктан — син Иван Грозныйлар нәселеннән, син дөньяда иң бөек милләт, дип ышандырдылар, шул идеяне дөньяга тарату өчен зур акчалар тоттылар. Төп дошманымны күрсәттеләр. Маңгаема демократ мөһере суктылар. Кем мин — Иванмы, Соломонмы? А-а-а! Тиле мин, шыр тиле, үзенең нәселен онытkan шыр тиле! Мин хәзер Соломонга да, Иванга да кирәкмим! А-а-а! *(Елап, идәнгә егыла.)*

Барысы да аның янына җыела.

«Баш» Тиле. Ул үзенең тилелеген раслады. *(Демократка кәгазь суза.)* Менә шуңа «мин шыр тиле» дип кул куй, ул синең гомереңне саклар.

Демократ. Куям! Куям! Әмма мине моннан соң «Демократ» дип атамагыз! Мин шыр тиле, тиле Иван, Иванушка, әмма мин — Баш шыр тиле! *(Кул куя.)* Шулай дип кул куйдым. Әмма мин, шыр тиле буларак, безнең арада кайбер кешеләрнең булуын теләмәс идем.

«Баш» Тиле. Кемне күздә тотасың? Сат, исбатла!

Демократ. *(Депутатка күрсәтеп.)* Мин түгел, менә бу бәндә безнең арада иң куркыныч кеше. Чөнки ул — акыллылар арасында — җүләр булып, җүләрләр арасында — акыллы булып уйный. Ул — демократ та түгел, консерватор да түгел, коммунист та түгел, милләтче дә түгел. Кем ул, аны бирегә нинди максат белән җибәргәннәр — үзе дә белми. Тегендә дә, монда да ул барысын да бутап бетерде.

Тиле карт. Дөрес! Ул бутады барысын да! Ул килгәч башланды монда хәлләр! Аны монда махсус җибәргәннәр. Кара күзлек белән күзен яшереп йөри!

Тавышлар:

— Әйтсен үзенең кем икәнен!

— Күзлеген салдырыгыз, күзлеген! Бәлки ул сукырдыр?

— Авыру бит ул, тиле, нәрсә сөйләгәнен дә белми.

— Наркоман ул! Шуңа күзе чыккан кигәвен кебек йөри!

— Из үзен, сыт, бәр!

«Баш» Тиле. Тимәгез аңа! Ул үзенең кем икәнен раслады инде!

Депутат. Мин сүз сорыйм! Нигә мине сүздән мәхрүм итәсез?! Мин рәисне алыштыруны таләп итәм — ул үзе өчен җайлы кешеләргә генә сүз бирә. 4 нче микрофон! 4 нче микрофон! Тоташтырыгыз! Регламентны бозмагыз!

«Баш» Тиле. Алыгыз аны! Күрмисезмени, исбатлап торырга да кирәкми, ул — шыр тиле!

Тиләләр Депутатны үз араларына өстерәп кертәләр. «Тиле, тиле, шыр тиле!» дип, аның тирәсендә әйләнәләр. Депутат идәнгә тезләнеп елый.

Депутат. Кая эләктем мин?! Шыр тиле! Тегендә дә, монда да мине тиле дип уйлыйлар. Әмма мин аңлыйм

бит, тиле булсам да аңлыйм — миннән файдаланалар! Миннән үз халкыма каршы эшли торган корал ясадылар! Минем тамырларыма агу җибәреп, миемне, аңымны юдырдылар! Мин туган анамны да белмим, милләтемне дә саттым, үзем дә беттем! Манкорт мин, манкорт! А-а-а! Кемгә кирәк мин? Кумагыз мине үз арагыздан, сез тегеләргә караганда барыбер акыллырак. Бирегез кәгазь, мин сезнең арада үз теләгем белән калам. *(Кул куя.)* Шыр тиле дип кул куям! Әмма бу дөньяда миннән җүләррәкләр дә бар! Алар гомере буе үзләрен акыллыга санап йөрделәр, әмма алар — шыр тилеләр!

«Баш» Тиле. Без шыр тилеләрне хөкем итмибез! Тилегә суд юк — сез депутат кеше, законнарны яхшы белергә тиеш идегез!

Депутат. Мине бүлмәвегезне сорыйм! Мин дә хәзер сезнең белән бер хокуктагы шыр тиле! Вот так! Тилелеккә мандатым бар! *(Кәгазен алып селки.)*

«Баш» Тиле. Сез регламентны яхшы беләсез. Сезгә бер минут, исбатлагыз — кемне һәм нәрсә өчен хөкем итәргә җыенасыз?

Депутат *(Тиле картка күрсәтеп)*. Менә кемнәр шушы хәлгә китереп җиткерде илне! Башкаларны тилегә санап, Берлинны да алдылар, Кытаена да керделәр, Әфганына да барып җиттеләр. Мең еллык тарихлары бар, имеш! Тагы мең ел яшәргә җыеналар! Бердәм һәм бүленмәс армия! Атом да бүленә, әфәнделәр! Ә мине бүлдермәгез! Менә бу карт тилеләр, армияне бүлмибез, дип, өченче бөтендөнья сугышын башлап җибәрергә дә әзерләр. Безнең башка бу тиле-миле демократлар түгел, менә шушы «маршал»лар җитәчәк, әфәнделәр!

Җүләрләр Тиле картны чорнап алалар.

Тавышлар:
— Әле ул сугыш планнары корып ята икән!
— Аны бирегә махсус җибәргәннәр!
— Кнопкасы юкмы, кнопкасы! Басып куя күрмәсен!

— Йолкы орден-медальләрен!

— Из, сыт, бәр!

Тиле карт. Мин — карт солдат! Якын киләсе булмагыз! Кисәтәм — мин һөҗүмгә күчәргә мәҗбүр булачакмын! Огонь!

Барысы да идәнгә егыла. Алар белән бергә Тиле карт үзе дә ава.

Тиле Түрә *(эшләпәсен сала)*. Бердәм һәм бүленмәс армия... бетте.

Барысы да Тиле карт янына җыелып, елый башлыйлар.

Тиле карт. Бердәм һәм бүленмәс армия... Соңгы сулышын алып ята... *(Башын күтәреп.)* Мин, карт солдат, соңгы минутымда шуны аңладым — мин, чыннан да, шыр тиле булганмын икән!

Барысы да «шыр тиле, шыр тиле, аңа тимәгез!» дип кычкыра башлыйлар.

Тиле карт. Әйе, шыр тиле булганмын. 12 яшемнән, иптәш Сталин өчен, дип, бозлы суга сикерә идем! Шыр тиле булганмын! 17 яшем тулганчы, иптәш Сталин өчен, дип сугыш утына сикердем! Шыр тиле булганмын! Яраланып, әсирлеккә эләктем, күпме кеше шул якта калды, ә мин шыр сөяккә калган гәүдәмне өстерәп, Ватаныма кайтып егылдым! Шыр тиле булганмын! Әсирлек өчен мине Себер төрмәләре көтеп торган икән. Төрмәдән чыккач та, минем исемем «фашист» булды, хатыным талашкан саен миңа «фашист» дип әйтә иде. Үземнең фашист түгел икәнлегемне исбатлый-исбатлый, мин акылымнан яздым. Мин, карт солдат, хәзер шуны аңладым — без юкка немецлардан сакладык бу илне! Фашистлар басып алса да, халыкның хәле бүгенге кебек булмас иде! Тиләләр йортлары, төрмәләр халык белән шыгрым тулы бит! Ил ачлыктан шешенә! Кешеләрне кол урынына саталар — коллективларыние белән! Шуның өчен сугыштыкмыни соң без?! Шыр тиле мин, шыр тиле! *(Елый.)* Бирегез кәгазегезне, кулымны куям. *(Кулын куя.)*

«Баш» Тиле. Кемнең кем икәне хәзер ахыргача ачыкланып бетте. Хәзер карар кабул итәргә дә була.

Тиле Түрә. Ул нинди карар тагы?! Әле уен беткәдемени соң?! Кайчан чын тиләләрчә генә яши башлыйбыз соң без? Кирәкми карарларыгыз, кирәкми. Сүндерегез телевизорны!

«Баш» Тиле. Уен бетте — хөкем башланды, әфәнделәр!

Тиле карт. Нинди хөкем?! Нәрсә өчен хөкем! Күпме аңлатырга була, мин фашист түгел дип. Түгел! Мин — җүләр! Җүләр булып калырга ирек бирегез!

Тиле Түрә. Мин дә карак түгел! Мин бернәрсә белмим. Мин — тиле! Ә тилегә суд юк!

Демократ. Ә мин — Иван Грозный! Бу йортның патшасы! Хәзер мин Казанны алырга барам! Кемнәр минем армиягә языла?!

Тиле карт. Мин языламы! Миңа хәзер барыбер — Мәскәүне алыргамы, Казанныымы! Гаскәр һәм приказ гына булсын!

Тиләләр «Мин дә!», «Мин дә!», «Казанны алабыз!» дип кычкыра башлыйлар.

Тиле Даһи. Туктагыз, кешеләр! Мин сезнең соңгы пәйгамбәрегез! Мине тыңлагыз! Бу минем сезгә соңгы сүзем. Миңа сездән җүләрме, юкмы, дип сорап тору кирәкми, мин сезнең барыгызны да үтәдән-үтә күрәм. Ниһаять, сине дә күрәм, «Баш» Тиле! Синең кемнәр тарафыннан җибәрелгән икәнеңне дә беләм! Син кара йолдыздан килдең. Син бу йортка хәсрәт, кайгы алып килдең. Әмма монда син булмасаң, башканы җибәрерләр иде. Шуңа күрә сиңа ачу тотмыйм. Миңа хәбәр килде — бу йортта беренче җәзаны син алачаксың. Бер соравым бар. Нигә син тиләләр белән тиле булып уйнадың?!

Милләтче. Мин әйтәм. Мин дә синең шикелле бу ямьсез уенны читтән күзәттем, соңгы пәйгамбәр! Дәшүдән барыбер мәгънә булмас иде! Ышанмас идегез! Миңа мил-

ләтче мөһере сугылган бит! Мине үз халкым милләтчелек өчен җүләрләр йортына япты. Мин инде бередә сәясәт тә, мәкер дә,алдау да булмас дип уйлаган идем! Бу дөньяда барысы да төзәтеп булмаслык буталган, дөньяның астыөскә килгән булып чыкты! Кайда җүләрләр, кайда акыллылар — хәзер беркем әйтә алмый. Гаеплеләрне дә эзләмик, без барыбыз да гаепле! Һәм барыбыз да корбаннар. Вакыйга җүләрләр йортында бара, дип, сезне алдадылар! Вакыйга безнең тормышта бара! Барысына да сезнең тавышыгыз гына кирәк иде! Нәрсә дип кычкыра ул тавыш — бер сынык икмәк сорап өзгәләнәме, тел, дәүләт таләп итеп аваз саламы — дөнья өчен моның әһәмияте юк иде, чөнки алар өчен без җүләрләр йортына ябылган тиленәр генә идек! Һәм безнең монда бер генә хокукыбыз бар иде — үзебезне тәҗрибә өчен сату. Хәзер, кул куеп, сез шуны эшләдегез. Безнең белән хәзер кем тели — шул тәҗрибә уздыра ала. «Тимер» Тилегә дә үпкә белдереп булмый, ул җүләрләр арасына махсус программа белән җибәрелгән тимер машина гына. Аның заманы, вакыты үтеп бара. Әмма ул сезне сатып җибәрергә өлгерде.

Тиле карт. Ничек, сатып өлгерде?! Кемгә?

Тиле Түрә. Мин үз өстемдә тәҗрибә уздырырга рөхсәт бирмим! Бирегез минем тавышымны кире! Бирегез! А-а-а! Төрмәгә керергә дә әзер — моннан гына чыгарыгыз!

Депутат. Аһ, мин тиле! Аның машина икәнен бер күрүдә аңлап була иде бит! Кемгә ышандым?!

Тиленәр ярсый, шаулаша башлыйлар. Барысы да «Баш» Тиле өстенә киләләр.

Тавышлар:

— Без хәзер барысын да аңладык! Без — тиленәр түгел, тиленәр — без түгел!

— Тавышларыбызны кире бирегез!

— Йортыбызны кире бирегез!

— Без тәҗрибәгә риза түгел! Без ялгышыбызны аңладык!

— Чыгарыгыз безне моннан, чыгарыгыз!

Өстәлдәге кәгазьләрне килеп ертып ташлыйлар.
Өстә кинәт лампочка-күз. яна. «Баш» Тиле нидер әйтмәкче була, әмма тавышы чыкмый, ул, робот кебек, кулларын хәрәкәтләндерә. Кинәт аны өскә күтәрә башлыйлар. Ләкин аның гәүдәсе ике арада асылынып кала. Тиләләр, моны күреп, куркып идәнгә егылалар.

Депутат. Менә хәзер, чыннан да, уен тәмам, әфәнделәр. Нокта нәкъ менә шушылай куелырга тиеш иде. Сез үзегезнең иң акыллы, иң сабыр халык икәнегезне расладыгыз. Мин моны парламентарий буларак әйтәм. Әйе, тормышта шулай килеп чыкты — күпләрегез башларын җүләргә салырга, төрле системаларга хезмәт итәргә мәҗбүр булды. Ниһаять, сезгә дә акыл керде — бу тормышта җүләрләр йортына качып кына котылып булмасын аңладыгыз. Димәк, үз язмышың өчен көрәшергә кирәк, хәтта җүләрләр йортында да! Моны хәтта мин-манкорт та аңладым, әфәнделәр! Димәк, сез исбатладыгыз — сез тиләләр түгел. Димәк, сез бүгенге көннән ирektә, әфәнделәр! Капкаларны ачыгыз! Ирек керсен бу йортка!

Барысы да «Ирек!», «Ирек!, «Азатлык!» дип кычкырырга тотыналар.
Капка-ишекләр ачыла. Аннан кара халатлы врач-омончылар кереп тула. Алар тиләләрне дубинкалар белән кыйный башлыйлар. Калканнарын өскә күтәреп, аларны чорнап алалар. Өстә лампочка-күз яна. Арттагы кара пәрдә акрынлап аска шуып төшә. Аның астыннан ике башлы карчыга — Россия гербы килеп чыга. Залга Россия гимны яңгырый. Бер яктан тәреләр, икенче яктан кылычлар тоткан кешеләр җүләрләрне чорнап ала.

Милләтче. Вакыйга җүләрләр йортында бара...
Тиләләр *(хор белән)*. Вакыйга... җүләрләр... йортында... бара...

Пәрдә.

БЕЗНЕ ОНЫТМАГЫЗ...

2 пәрдәлек драма

КАТНАШАЛАР:

Айсылу.
Суфия.
Гадилә.
Исламия — 1937 елның 20 августында бер төндә, бер камерага ябылган татар хатыннары.
Җамал.
Галимҗан — Айсылуның ире.
Кыяметдин — НКВД работнигы.
Эдик — Суфияның оныгы.
Тоткын хатыннар.
Балалар.
Массалар.

Вакыйга 1937—1987 елларда Советлар Союзында бара.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

1987 елның 20 август киче. Казан шәһәрендә Суфиялар квартирасы. Квартир иске таш йортларның берсендә булып, борынгылык, ныклык сизелеп тора.

Стенага Сталин портреты эленгән.

Пәрдә ачылганда Суфия карчык табын әзерләп йөри.

Эдик ашыга-ашыга керә.

Суфия. Бүген дә чыгып качасыңмы?

Эдик. Так точно, бабуля!

Суфия. Әтиең янына барып кайтыр идең...

Эдик. Анда кертмиләр.

Суфия. Берәр нәрсә алып барыр идең...

Эдик. Ну, бабуля, сиңа әйттеләр бит инде — анда... бзик-бзик *(чигәсенә борып күрсәтә)*... кертмиләр.

Суфия. И, алла! Килен дә командировкалардан кайтып керми. Үземнең дә йөрерлек хәлем юк. Атаң җүләрләр йортында үлсә, сиңа да кызык булмас.

Эдик. Үлми! Ел саен кереп ята бит ул анда. Азрак эчәр...

Суфия. Җаның юктыр синең, балам... Атаң күргәннәрне син күрсәң, эчү генә түгел, шашар идең...

Эдик. Күргән, күргән!.. Үзегез гаепле. Сарык кебек, кайда кусалар, шунда йөрмәскә иде.

Суфия. Бу рәсемне алып торам. *(Стенадагы Сталин портреты янына килә.)*

Эдик. А, юк, бабуля! Син аңа тимә инде.

Суфия. Миңа бүген карчыклар килә... Ашка...

Эдик. Ашагыз соң. Тик рәсемгә тимәгез.

Суфия. Алар... теге елларны утырып чыккан кешеләр. Яратырлармы икән?

Эдик. Заманында яратканнар бит. Алла урынына табынганнар. Ә аллаларны бишьеллык саен алмаштырмыйлар.

Суфия. Телең... Атаң йомшак, анаң эш кешесе... Кайдан килгән сиңа шундый усаллык?

Эдик. Әйтсәм, ачуланмыйсыңмы?

Суфия. Ачуланып нишләтәсең инде сине?

Эдик. Синнән килгән усаллык ул миндә, әбекәй.

Суфия. Әстәгъфирулла! Мин кеше белән шулай сөйләшәмме?

Эдик. Алай сөйләшмисең. Ләкин... күңелең каты синең... Мин элек синнән курка идем, әбекәй... Көннәр буе сөйләшмичә йөри идең. Елмайганыңны да хәтерләмим... Ә көлү турында... *(Кулын селти.)*

Суфия. И, бала... Мин күргәннәрне күрсәң...

Эдик. Опять «мин күргән»! Соң, синең ул күргәннәреңә без гаепле түгел бит инде, әбекәй! Ул да гаепле түгел! *(Сталин рәсеменә күрсәтә.)*

Суфия. Кем гаепле соң? Кем...

Эдик. Сез! Син үзең, мәсәлән...

Суфия. Мин... *(хәле китеп урындыкка утыра.)*

Эдик. Ну, әбекәй, синең белән берни сөйләшеп булмый. *(Су китереп бирә.)* Егылып китәргә генә торасың. Үзең өй тутырып кеше җыясың тагы.

Суфия. Чыгып китми тор, улым. Берәрсе килсен, аннары чыгарсың.

Эдик. Ярый, бабуля. Тик озакка түгел. Безнең законнар каты анда.

Суфия. Юкка йөрисең, улым. Харап итәрләр үзеңне. Юктан харап булырсың.

Эдик. Я — без, я — безне, әбекәй. Анда урталык юк. Рәхим-шәфкать тә юк.

Суфия. Нигә шулай кыланасыз соң, улым? Нигә бер дә юкка кеше җанын кыясыз?

Эдик. Моңа беркем җавап бирә алмый.

Суфия. Тыныч заманда бер-берегезне үтерешәсез бит. Бер сәбәпсез! Я, хода...

Эдик. Бездән генә калган эш түгел. Менә... сезнең заманда ни өчен үтерештеләр? Миллионлап бит... Беркем җавап бирә алмый.

Суфия. Безнеке — башка... Ил белән... Заманы шундый иде.

Эдик. Заман, заман! Әйттермә, әби, я тагы егылырсың.

Ишектә звонок.

Слава богу, беренче кешесе килде! *(Барып ача.)*

Айсылу керә.

О, картәби! Салют!

Айсылу. Исәнме, Эдик. Сеңелем, син ни хәлдә? Кәефең юк кебек...

Суфия. Шулайрак шул...

Айсылу. Безне дә җыясы иткәнсең икән...

Суфия. Шулайрак шул... Бүген нинди көн икәнен хәтерлисеңдер?

Айсылу. Иртәдән бирле шул турыда уйлыйм... Илле ел тулган диген.

Эдик. Берәр юбилеймы әллә, картәби? Шампанскийны ачам хәзер.

Айсылу. Ачмыйча тор, улым. Бу шампански ача торган көн түгел. *(Суфияга.)* Нигә барыбызны да җыясы иттең?

Суфия. Әйтер сүзем бар. Бераз Коръән укытып алыйм, дидем.

Айсылу. Мулла ук чакыртмагансыңдыр бит?

Суфия. Мулла, дип... Мулла ук түгел инде. Килгәч күрерсең.

Айсылу. Кирәкмәс иде. Заманында коммунист хатыннар идек бит без синең белән. Апалы-сеңелле коммунисткалар, дип, газеталар гел безнең хакта язды бит ул елларда.

Суфия. Коммунистлык Себер шахталарында калды инде. Монда кайтмады.

Бергәләп өстәл әзерлиләр.

Эдик. Картәби! Нинди бәйрәмгә шулай әзерләнәсез соң сез? Әллә... *(әкрен)* Сталинның берәр юбилеемы?

Айсылу. Юк, улым, Сталин юбилее түгел. Бүген безне кулга алганга илле ел.

Эдик. А-а! Вот как! Жертвы культа личности... Кызык... Аяклы тарихлар... Корбаннар... Я, я, карыйм әле, кемнәр килерләр икән?

Айсылу. Алай зәһәрләнмә, улым... Ул корбаннарны карарга ерак барасы юк. Берсе — менә мин, берсе — әбиең. Бабаң бөтенләй юкка чыкты. Атаң... җүләрләр йортыннан чыгып тормый.

Эдик. Ну и семейка!.. Минем пай-мальчик булуны телисез тагы! Бөтен нәселдән төрмә исе килә — мин фәрештә булыйм! Ә мин, барыгызга да үч итеп, үзем тураклыйм бүген. Идея өчен киткәннәр имеш! Ну и люди!

Ишектә звонок.
Гадилә белән Исламия керә. Гадилә бераз кызмача. Исламия гел дерелдәп-калтырап тора.

Гадилә. Чак килеп җиттек. *(Утыра.)* Башта Исламиянең ишеген ачтыра алмыйча җаным чыкты. Ачмый. Җиде йозакка бикләнгән.

Исламия. Милиция дип куркыттың бит...

Гадилә. Соң мин аны юри әйттем бит. Салган баштан... Бу җүләре ышана калды.

Исламия *(сикереп тора)*. Сездә чит-ят кеше юкмы? *(Эдикка.)* Бу нинди кеше?

Суфия. Минем оныгым ул, Исламия.

Исламия *(стенадагы рәсемне күреп)*. Ай, алла! Хараплар гына булдым! Тыңлап торган бит! Нигә башта ук аның монда икәнлеген әйтмәдегез! *(Качмакчы була.)*

Гадилә. Шул тәре сынын һаман тотасың икән әле. Эчкән баштан бер көл итәм инде итүен. *(Рәсемгә таба бара.)*

Эдик *(каршы төшеп)*. Тише, бабуся! Урыныңа утыр.

Гадилә *(чигенеп)*. Утырырмын. Мин 8 ел утырган. Ә син, салам сыйрак, нигә дип саклыйсың аны?!

Эдик. Чөнки... минем аллам ул! Мин шуңа табынам. Сез мескеннәр түгел, менә ул — тимер кеше — минем аллам!

Гадилә. Нәрсә сөйли ул?! Суфия, шушыны әйттерер өчен җыйдыңмы син безне?! Илле елдан соң? Шушы... маңка малайлардан!

Исламия. Аягым тартмаган иде аны...

Гадилә. Әйдә, Исламия, җыен.

Айсылу. Ул балага кагылмагыз. Нәрсә сөйләгәнен аңламый ул.

Суфия. Сезгә әйтер сүзем бар. Шуны әйтмичә, үлә дә алмыйм, кала да алмыйм. Эдик, бар, улым, барасы җиреңә.

Эдик. Монда да бик кызык булырга тора әле. Музейный экспонатлар. Ха-ха-ха!

Ишектә звонок.
Төенчекләр тотып Җамал керә. Ул — телсез. Карчыкларның барысы белән дә кул бирешеп исәнләшеп чыга. Эдикның аркасыннан сөеп, чәчләреннән сыйпап үтә.

Айсылу. Җамал... И, Җамал! Син дә картайгансың....

Җамал елмаеп карап тора.

Гадилә. Картаерсың... Сез аның нинди тормышта яшәгәнен беләсезме соң?

Суфия. Улы эчә, дип ишеткән идем.

Гадилә. Эчә генәме?! Мин бит теге елларда, торырга урын булмагач, анда да барып чыктым. Анасын, контр калдыгы, дип кыйный икән. Мин барында гына тыелып торды.

Айсылу. Мин дә ишеткән идем аны. Бер үзебезгә дә алып килергә уйлаган идем. Килмәде.

Суфия. Эчсә дә, бала бит. Үз баласы. Хәзер ул да картайгандыр инде. Акыл кергәндер.

Исламия. Минем кызларым миннән ваз кичтеләр. Менә язу язып... *(Кәгазь күрсәтә.)*

Гадилә. Элек бит инде ул, Исламия. Хәзер кызларың сөйләшә бит үзең белән.

Исламия. Сөйләшмиләр. Айлар буе сөйләшмиләр. Минем гаебем зур шул. Мин — халык дошманы хатыны.

Җамал килеп аның чәченнән сыйпый. Исламия тынычлана.

Гадилә. Гел сихерче кебек бу Җамал. Тегендә дә шулай иде бит, иеме? Кемгә авыр — шуның янында Җамал иде...

Айсылу. Күнеле әйбәт шул аның. Безнеке кебек бозланып катмаган...

Суфия. Ягез, карчыклар, утырыша торыйк.

Утырышалар. Тынлык.

Айсылу. Мине алыр сәгать җитә... Кремль астына иң беренче мине китерделәр бит. Аннан — Исламияне, Гадиләне, сине, Суфия...

Гадилә. Әй-й! Төшермә исләргә! Кая, бераз тотып куярга юкмы соң синең монда? Йөрәк яна, карчыклар!

Суфия. Куй әле, Гадилә! Шул яман гадәтең һаман бетмәгән икән. Коръән мәҗлесенә кем андый нәрсә куйсын, ди.

Гадилә. Коръән?! Нинди Коръән?! Без тереләй тәмугта яндык! Теге дөньяда безгә оҗмах инде — Коръәнсез дә!..

Җамал килеп аның чәченнән сыйпый.

Исламия. И, алла, аягым тартмаган иде аны. Күршеләр ишетеп, барып әйтерләр инде.

Звонок.

Әстәгыфирулла! Килеп тә җиттеләр.

Айсылу. Мине алыр сәгать җитте...

Ишектә Кыяметдин күренә.

Кыяметдин. Аллаһе Тәгалә йортка иминлек бирсен. Утырып бер дога кылыйк.

Утырып дога кыла башлый. Барысы да катып аңа карап торалар.

Чак исән-сау килеп җиттек. Сезнең турыда гына ду китереп сугышып яталар. Әллә кеше үтерәләр шунда? Ахырзаман... Кыямәт... Ярый, мин тәһарәт яңартып чыгыйм да, эшкә тотынырбыз. *(Кереп китә.)*

Эдик йөгереп барып тәрәзәдән карый. Кинәт артка чигенә. Ишеккә бара. Тыңлый. Биклəп куя.

Айсылу. Үзгәрмәгән... Безне танымады. Безнең кеше танырлык калмады шул. Ул, әнә, һаман имән кебек. Менә ни өчен җыйгансың икән безне, сеңелем.

Суфия. Әйтеп каласы сүзем бар...

Гадилә. Аһ, гад! Исән икән әле, күр син аны! Ишектән керүгә, йөрәкләрем жу итеп китте... Эчкәндә дә алай булмый иде. Ну, Кыяметдин, мин сиңа әйтәм бүген илле ел җыелганны.

Исламия. И, ходаем, ул идемени ул?! Шул... безне утырткан Кыяметдинме? Аягым тартмаган иде аны. Качырыгыз мине, тизрәк качырыгыз!

Айсылу. Сиңа тими ул, Исламия. Курыкма, яме. Кил, минем янга утыр.

Бер Җамал дәшми, каш астыннан карап утыра.

Суфия. Кыяметдингә... алай каты бәрелмәгез. Эше шул иде. Бездән соң үзе дә утырып чыккан.

Айсылу. Анда эләккән ирләр исән калмады...

Гадилә. Соңыннан чиста күренәсе килгән! Утырып чыккан, имеш! Гад!

Исламия. Минем кәгазем бар! Акланды, дигән кәгазем бар. Менә.

Суфия. Безгә бүген тыныч сөйләшергә кирәк. Ул әле сезне танымады. Үтәсе гомер үтте, аның өчен үч алудан мәгънә юк. Тыныч кына сөйләшик.

Айсылу. Минем аның белән исәп-хисабым бар, син беләсең. Язмыш шулай туры китергән икән — комачау итмә.

Кыяметдин чыга.

Кыяметдин. Я, карчыклар, утырышыйк. *(Коръәнен актара-актара.)* Дөньялыкта кылган гөнаһларны ахирәткә алып бармыйк. Бу дөнья безнең кырык көнлек йортыбыз гына. Ни күрсәк тә, ни кылсак та Аллаһе Тәгалә каршында һәрберебезгә аерым-аерым җавап бирәсе... *(Тотлыгып туктап кала.)*

Айсылу. Нәрсә, таный башладыңмы әллә?

Гадилә. Син, төрмә күсесе, теге дөньяга китәргә ашыкма әле. Монда җавап биреп бетерәсе эшләрең бар.

Исламия. Аягым тартмаган иде аны. Минем бер гаебем дә юк. Әнә ул өстерәп алып килде. Ничә ел бикләнеп утырам. Картлык көнемдә мине җавапка тарттыра күрмә. Минем кәгазьләрем бар.

Җамал гына дәшми.

Кыяметдин *(аңлый башлап)*. Бу... нинди кәмит? *(Суфияга.)* Шуның өчен чакырдыңмыни син мине?..

Суфия. Тавышланмыйк. Сөйләшеп бетерәсе сүзләр бар. Төн озын. Гомер генә бетте.

Айсылу. Нинди төн бит?! Я, Хода, әллә тагы барысы да кабатланамы? Шул ук рәсем, шул ук кешеләр...

Гадилә. Кая кабатлансын инде?! Кая шул ук кешеләр? Безме шул ук кеше? Мин шушындый идемме?! Татар театрының иң гүзәл артисткасы идем бит мин! Йолдыз идем. Хәзер кем? Кайда минем ирем? Кайда минем улым? Ә, кайда?! *(Кыяметдин өстенә килә.)*

Исламия. Зинһар, китик, Гадилә. Тынычлап үләргә ирек бирегез. Бернәрсә кирәк түгел, берни сорамыйм, миңа гына кагылмагыз.

Айсылу. Минем улымны соңгы тапкыр син күргәнсең. Ник кайттың син аны эзәрлекләп, кан исеннән барган шакал кебек?! Безнең утыру җитмәгән идемени?!

Эдик. Бу нинди кошмар?! Нәрсә бүлешә алар. Туктагыз! Үтерәсез бит бу картны.

Суфия. Кыяметдингә... кагылмагыз. Гөнаһы булса, үзе җавап бирер. Бүген миңа ирек бирегез. Илле ел инде таштай гөнаһым җанымны басып торды. Бүген шуны әйтергә җыйдым... Кыяметдин түгел, мин гаепле сезнең каршыда!

Айсылу. Зур гаепне өстеңә аласың, сеңелем...

Гадилә. Алай... Телдә — Алла, күңелдә — кара таш...

Суфия. Шуңа күрә җыйдым да. Муенымдагы кара ташны каберемә дә алып китәсе килмәде... Теге елларда...

яшисем килде. Балаларны саклап каласым килде... Мин саттым сезне, мин! Кыяметдин түгел.

Эдик *(сызгырып җибәрә)*. Ну, бабуля, даешь...

Айсылу. Син... ни сөйлисең, Суфия?..

Суфия. Әйтеп үлим, дидем... Менә монда ул таш, менә монда!.. Әйтеп үлим, ирек бирегез!!!

Сәхнә караңгылана.

Аста милиция машинасы кычкырткан тавышлар, шау-шу ишетелә. Биш карчык, сын кебек, катып басып торалар. Кыяметдин башын тотып утырган.

Сәхнә алдыннан, көтү кебек, толпа үтеп китә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче күренеш сәхнәдә бераз өстә барып, бу күренеш исә аста — тормышның төбендә, үткәнендә дәвам итә. Әйтерсең биш карчык үз-үзләренә карап торалар.

1937 ел. Айсылулар яши торган бүлмә. Кич, төнгә таба. Айсылу озын ак күлмәктән урын җәя. Галимҗан башын иеп утырган.

Айсылу. Газизне авылга, әнкәйләргә кайтарып, яхшы иттек әле. Дөньялар да тыныч түгел.

Галимҗан. Тыныч түгел... Һаман ала торалар. Безнең бүлектә бер мин калдым — барысы да яңалар... Чират — миндә...

Айсылу. Сиңа кагылмаслар, Галимҗан. Синең бит бер гаебең дә юк.

Галимҗан. Ә аларның бар идеме? Их, йөрәк яна, Айсылу. Сөйләшер кеше дә калмады. Һәммәсе шикләнә, курка, күзләрендә хәвеф. Алынганнар турында бер дә яхшы хәбәрләр йөрми.

Айсылу. Сине алмаслар, Галимҗан! Анда да бит башсыз кешеләр утырмый. Син — ярлы баласы, Чапаев дивизияләрендә сугышкан кеше. Минем нәсел аркасында гына бәйләнсәләр инде...

Галимҗан. Табарлар, Кировның ни гаебе бар иде?

Айсылу. Кировның? Соң ул бит... Аны бит...

Галимҗан. Үтерделәр, дисеңме? *(Пышылдап.)* Ә үтертсәләр... ни диярсең?

Айсылу. Алай... сөйләмә... Зинһар, ялварып сорыйм синнән... алай уйларга да курык. Улыбыз хакына, минем хакка. Ул нәрсәләр турында уйлама. Синең бит уйлаганыңны әйтә торган гадәтең бар. Ычкындырырсың да... бетәсең бит, Галимҗан! *(Аякларын коча.)*

Галимҗан. Мин генә калмам инде, Айсылу. Әзер булып торырга кирәк.

Кинәт каты итеп ишек дөбердәтәләр. Галимҗан ишекне ачарга бара. Йөзен танымаслык итеп төргән Суфия керә. Керә дә урындыкка ава.

Суфия. Апа! Нурәхмәтне алдылар.

Айсылу. Алдылар?! Әле... укытучыларга тимиләр иде бит? Ялгышлык кынадыр, сеңелем, елама.

Суфия. Түгел. Гаепләре бик җитди. Балаларны... Совет дәүләтенә каршы котыртканы өчен... Мәктәптә шпионлык мәктәбе оештырган өчен... Ишан кызына өйләнгәне өчен...

Айсылу. Әти күптән үлде бит инде, аның ни катнашы бар икән? Юк, юк, бу ниндидер аңлашылмаучылык кына. Кыяметдингә әйтеп карарга кирәк. Ул бит анда эшли, Нурәхмәтне дә яхшы белә.

Суфия. Алырга... Кыяметдин үзе килде.

Айсылу. Үзе килде?! Нәрсә, ул бөтенләй җүләрләнгәнме әллә? Ул Нурәхмәтнең кем икәнен белмиме инде? Соң, үзе дошман бит инде ул болай булгач. Үзе халык дошманы!

Галимҗан. Алай түгел, Айсылу. Кем дошман — беркем дә ачык белми. Шуңа күрә шикләнгән бер кешене утырталар. Кыяметдин — үтәүче генә ул. Ул гомер буе йомшак булды — менә үз урынын тапты.

Суфия. Җизни! Әни сине китсен, диде. Кит, кач, җизни! Үзбәк якларына кит, апалар янына. Мин да олы балаларны аңа биреп җибәрәм. Бергә китегез! Бүген төнлә үк китегез!

Галимҗан. Алай булмас инде ул, балдыз. Алай качып котылып булмас...

Айсылу. Ичмаса, баланы да авылга җибәрдек бит! Бәлки, апаларга иярер идек тә, китәр идек.

Галимҗан. Мине күзәтәләр, Айсылу. Сине борчымас өчен әйтмәгән идем. Эшкә баруым да, кемнәр белән сөйләшүем — барысы да күзәтү астында. Иптәшләр ни күрсә, шуны күрермен. Илгә килгән афәттән качып кына котылып булмас.

Суфия. Нурәхмәт... үзеннән ваз кичәргә кушты.

Айсылу. Ничек — ваз кичәргә?

Суфия. Мин аннан ваз кичсәм, безнең фатирга да, үзебезгә да кагылмыйлар икән. Чыгып киткәндә каерылып-каерылып әйтте: «Миннән баш тарт», — дип. *(Елый.)*

Галимҗан. Үзеңә кара, балдыз. Үз тормышыңа ничек җайлы — шулай эшлә.

Айсылу. Әни нәрсә ди соң?

Суфия. Әни ничек тә балаларны саклап калырга тырыша. Олыларын үзбәк якларына җибәрү дә — аның фикере.

Галимҗан. Әби теге елларны күргән кеше шул ул. Рәхим-шәфкать көтеп булмасын белә.

Айсылу. Сеңелем, син бүген кайтып йөрмә инде. Күрмәсеннәр.

Суфия. Юк, юк! Балаларны әзерләргә кирәк. Кайтыйм. Җизни! Харап итәрләр бит сине дә...

Галимҗан. Ни булса да, ил белән күрербез, балдыз.

Суфия тәренеп чыгып китә. Айсылу ишекләрне бикләп кала.

Димәк, чират бездә.

Айсылу. Ни сөйлисең син, Галимҗан! Сиңа кагылмаслар. Нурәхмәтне дә чыгарырлар. Безнең Суфия элек-электән хәвефле җан инде ул. Менә күрерсең, берни булмас. Совет илендә яшибез бит без! Сталин бар, Ленин партиясе бар, коммунистлар бар. Бу нindидер аңлашылмаучылык кына.

Галимҗан. Үзем дә кайвакытта шулай уйлыйм. Илдә корткычлар күп, дошманнар да бар. Алар белән көрәшергә кирәк. Ләкин нигә мондый юл белән? Нигә гаепсез кешеләргә кагылалар?

Айсылу. Гаепләре булмаса, чыгарырлар. Борчылма, җаным. Соңгы вакытта бөтенләй бетеренден. Сиңа карасам, йөрәгем сыза.

Галимҗан. Кайвакытта, капчыгымны тутырып, әллә төрмәләренә үзем барыйммы икән, дип уйлыйм! Җан урынында түгел. Һәр төнне... киенеп ятам бит... Үземнән оят! Синнән, хатынымнан оят, шундый көчсезлегем, мескенлегем өчен! Әле ярый баланы авылга җибәрдек, күзенә туры карарга ояла, курка башлаган идем.

Айсылу. Оялма... оялма, җаным. Ни күрсәк тә, бергә күрербез. Ак җәймәләр җәйдем... Син яраткан мамык мендәрләрне салдым. Бер төн булса да, онытып тор... Урамда яз бит, май... Мин дә сине... бик сагындым...

Галимҗан. Әле ярый дөньяда син бар, Айсылу! Юаттың — барысы да юкка чыкты. *(Аны күтәреп ала.)* Без бит әле исән, бәгърем, без бит әле исән! *(Күтәреп әйләндерә.)*

Айсылу. Син нинди көчле, Галимҗан! Ул кулларың, муеның, тәнең... Мин сине ничек яратам, Галимҗан!.. Яшь вакытта ярату — ул уен гына булган икән... Ничек сагынам, ничек көтәм мин сине һәр төн... *(Иренең күлмәк төймәләрен чишә.)*

Галимҗан *(аны күтәреп караватка алып китә)*. Менә шулай күтәреп, дөнья читенә хәтле алып китәр идем үзеңне.

Аста машина килеп туктый.

Дөнья... читенә... хәтле... *(Айсылуны сак кына төшерә.)*

Көчле итеп ишек шакыйлар.

Айсылу. Ачма!!! Алар сине... Алар...

Галимҗан ишекне барып ача. Кыяметдин һәм тагы берничә кеше керә. Кергән кешеләр шундук нидер эзли, актарына башлыйлар.

Кыяметдин. Матбугат йортының өлкән редакторы Зәкиев Галимҗан! Төркия һәм Япония белән яшерен мөнәсәбәттә торган өчен, ил хакында яшерен мәгълүматларны чит илләргә тапшырып барган өчен, шпионлык өчен, сез Совет дәүләте тарафыннан халык дошманы дип игълан ителәсез һәм кулга алынасыз.

Айсылу. Нинди... шпион?! Нинди... Япония? Кыяметдин! Син ни сөйлисең?! Ул бит синең авылдашың!

Кыяметдин. Молчать! Монда Кыяметдин юк. Монда НКВД тикшерүчесе Нәҗипов Кыяметдин генә бар. Җыеныгыз!

Галимҗан. Кычкырмыйча гына буламы? Әле минем шпионлык расланмаган. Авылдаш...

Кыяметдин. Молчать! Күп сөйләшәсең... авылдаш. Артык кыю сөйләшәсең... Шул гадәтең һаман бетмәгән. *(Әкренрәк.)* Зыяны тиюе бар. *(Кычкырып.)* Молчать!

Айсылу. Мин дә... синең белән китәм, Галимҗан! Дөнья читенә, диден! Дөнья чите насыйп икән! *(Җыена башлый.)*

Кыяметдин. Ярамый. Заманы шундый. Вакытлыча. Шулай кирәк.

Айсылу. Бу нәрсә соң бу?! Бу нинди кыямәт көне?! Минем иремнең гаебе юк! Сталинның үз янына барам! Инде Галимҗан кебек кешеләрне дә утырта башлагач, кая бара соң бу дөнья?! Кемгә ышанырга?!

Кыяметдин. Күп сөйләшәсең. *(Әкрен.)* Акыллы хатын идең бит син... Башыңны җуйма... Башыңны җуйма. Гаебе булмаса, чыгарырлар. Тик... күп сөйләмә. Башыңны сакла. Их, аңламыйсың...

Айсылу *(аның аягына егылып)*. Калдыр, Кыяметдин. Синең бит анда сүзең үтә. Син бит Галимҗанны беләсең. Мәхәббәтебез хакына, балабыз хакына калдыр Галимҗанны?!

Галимҗан. Түбәнәймә, Айсылу. Аннан тормый. Ул кушканны гына эшли.

Кыяметдин. Молчать! Җыен.

Галимҗан. Мин кайтырмын, Айсылу! Син ышан гына! Синең ирең илгә хыянәт итмәде! Син көт, мин кайтырмын! *(Каерылып карый.)* Баланы сакла.

Чыгып китәләр.

Айсылу *(шок хәлендә)*. Ак җәймәләр җәйдем... Син яраткан мамык megаерләрне салдым. Кайларга чыгып югалдың, ирем?! Кемнәрдән ярдәм сорыйм?!

Сәхнә алдыннан, көтү булып, толпа үтеп китә. Сәхнә караңгыланып кала. Бер мизгелгә беренче күренештә карчыклар җыелган бүлмә яктыртыла. Алар уйга батып утырганнар. Аста милиция машинасы кычкырткан тавышлар, мотоцикл тавышлары, шау-шу ишетелә. Хатын-кыз чырылдап кычкырып җибәрә. Биш карчык сын кебек катып калганнар. Кыяметдин башын тотып утырган.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

1937 ел. Суфиялар бүлмәсе. Бүлмәдә Суфия белән Кыяметдин. Түрдә Сталин портреты.

Кыяметдин. Син күндерергә тиеш аны. Югыйсә, бөтен нәселегез харап була — үзе дә, син дә, балаларыгыз да...

Суфия. Син Айсылуны белмисең. Ире өчен төрмәгә генә түгел, утка керә бит ул! Утка!

Кыяметдин. Беләм! НКВДга килгән. «Ирем белән бергә Себергә озатыгыз»,— ди. Ә аның иренә... Галимҗанга... кимендә 20 ел. Аннан — үзен. Сорап йөрмәсә дә Себер көтә. Син дә... балаларыңны урнаштыр. Җиле тиюе бар. Барыгыз да исән калу өчен, Айсылуның бер сүзе җитә бит, бер сүзе.

Суфия. Әйтмәячәк. Җизнидән ваз кичәме соң ул... Аларның мәхәббәте... Адәм баласында бүтән юктыр андый мәхәббәт.

Кыяметдин. Мәхәббәт, мәхәббәт! Бөтен илнең асты-өскә килә. Төрмәләр, җүләрләр йортлары, каберлекләр шыплап тулды. Аларның мәхәббәтләре юк идеме? Шашмасын. Исән каласы килсә, иреннән ваз кичеп, мин калдырган кәгазьгә кул куйсын. Мин һаман-һаман монда килеп йөри алмам. Заманы шундый. Неужели шуны аңламый ул?! Менә син аңладың бит.

Суфия. Аңладым. Мин исән иремнән ваз кичтем. Өч балам, әни хакына... Мин иремнән ваз кичтем! Аны, халык дошманы, чит ил шпионы дип кул куйдым! Балалар хакына бит! Ләкин Айсылу үлсә дә иреннән баш тартмаячак.

Теге якта бала елаганы ишетелә. Суфия кереп китә.

Кыяметдин. Туктарга вакыт... Туктарга вакыт. Ут белән шаярам. Дөнья өчен хәзер Кыяметдин дә, Галимҗан да, Айсылу да юк. Бар халык, бар халык дошманы, бар халык дошманы хатыннары... Шуны аңламыйлар икән, нәрсәгәдер ышаналар икән... үзләренә үпкәлиләр инде.

Кырт борылып чыгарга барганда Айсылу белән очраша. Артка чигә. Айсылу аягында чак басып тора.

Айсылу. Бүген дә көн буе төрмә капкасын сакладым. Ничә көн инде... илткән әйберләремне дә алмыйлар. Халык арасында төрле хәбәрләр йөри... Төннәр буе аталар ди. Кемнәргә барыйм, аның гаепсез икәнен кемнәргә сөйлим?! Ничек коткарыйм?!

Кыяметдин. Гаепсез булса, чыгарырлар. Илдә андый закон юк. Дошманы калыр, гаепсезе чыгар...

Айсылу. Галимҗан дошман түгел! Син бит яхшы беләсең. Бер авылда үстегез, бер кызны яраттыгыз. Минем ратуым хакына, минем хакка... коткар иремне?!

Кыяметдин *(башын тотып урындыкка утыра)*. Аларны хәзер... беркем коткара алмый инде. Тегермән ходка китте...

Айсылу. Ә Сталин?! Сталин беләме соң бу хәлләрне? Ул бит иң гадел, иң изге кеше. Нигә аннан яшерәләр бу

хәлләрне? Иртәгә үк үзем чыгып китәм аның янына. Барыбер коткарам иремне!

Кыяметдин *(әкрен)*. Син дә ут белән шаярасың, Айсылу... Акылыңны җуя күрмә. Сиңа Мәскәүгә түгел, бөтенләй башка якка китеп торырга кирәк. Галимҗанны да онытып торырга кирәк. Үзең турында уйла, Айсылу. Син бит акыллы хатын идең...

Айсылу. Нәрсә әйтергә теләгәнеңне беләм. Суфия да иреннән ваз кичте. Ваз кичәргә мәҗбүр булды. Аңа ире үзе шулай әйтеп калдырган.

Кыяметдин. Соң, шулай булгач? Бер сүзең җитә бит, бер сүзең! Гомереңне, нәселеңне саклап калырга бер сүзең җитә!

Айсылу. Син яратуның нәрсә икәнен белмисең икән, Кыяметдин... Менә син мине гомер буе яратам, дисең. Өйләнмәдең дә. Баш тарт миннән шулай җиңел генә! Баш тарт!!! Булмыймы? Менә мин дә Галимҗанга карата шулай шул. Артыннан Себергә җәяү чыгып китәргә әзер. Яланаяклап... Төннәр буе аның белән саташам бит мин... Кулларын сагынам... Назларын сагынам... *(Әллә ыңгыраша, әллә елый.)*

Кыяметдин. Саташ! Саташ!!! Тик соң булмасын. Мин монда килергә тиеш түгел идем. Мин сиңа боларны әйтергә тиеш түгел идем. *(Кинәт Айсылуның кулларына килеп тотына.)* Китик, Айсылу, бүген төнлә үк чыгып качыйк бу каһәр төшкән каладан! Минем вокзалда таныш егетләр бар. Качыйк үзбәк, казах якларына. Анда болай ук кыланмыйлар, ди. Син әле яшь, әле өр-яңадан тормыш башларга мөмкин. Улыңны да алырбыз. Иртәгә соң булуы мөмкин, аңла, Айсылу!

Айсылу. Ә Галимҗан?..

Кыяметдин. Галимҗанга... я стена, я кимендә 20 ел. Анда үзен бик горур тота. Кемгә кирәк аның ул горурлыгы? Кыйныйлар үзен. Исән калуы да икеле.

Айсылу. Ул үлеп ятсын, ә без — казах далаларына... Яшь кияү белән... Галимҗан шулай эшли алыр идеме икән?

Кыяметдин. Эшли алыр иде! Син ир-атны аз беләсең. Баш кадерле, аңлыйсыңмы, баш! Исән калса, соңыннан аңлашырбыз. Балаңны булса да саклап калырга кирәк бит инде. Сиңа бирәр нәрсә булса... миңа тормыш юк.

Айсылу. Әйдә... Ләкин башта ирем утырган бүлмәгә илт! Безне бер-беребездән аерып ала алсаң — ал! Ал!! Ал!! Үле гәүдәм кирәк икән — ал... Тик башта ирем янына, ирем...

Кыяметдин. Бетте! Бетә! Барысы да бетә! Нигә шуны аңламыйсың син?!

Чыгып китә.
Атылып Суфия чыга.

Суфия. Китте?! Нишлисең син, апа?! Бөтенебезне харап итәсең бит! Нигә син әни турында онытасың, нигә безнең хакта уйламыйсың? Нәселләре белән утырталар бит, күрмисеңмени?! Айсылу! Айсылу! Нигә эндәшмисең? Әллә... *(Артка чигенә.)*

Айсылу *(әкрен генә көйли)*.

Бәхетле Совет илендә
Үтә минем көннәрем.
Бәхетле Совет җирендә
Мәңге шиңмәс гөлләрем.

Сәхнә алдыннан, котү булып, толпа үтеп китә.
Сәхнә караңгылана.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук бүлмә. Бүгенге көн. Беренче күренештәге картина.

Айсылу. Нигә укымыйсың Коръәнеңне, Кыяметдин?

Кыяметдин. Башка догалар искә төште. Яшь чагындагылары. Тыңламадың шул чагында мине... Их, тыңламадың... Үтте гомерең кадерсезлектә.

Айсылу. Икенче көнне мине алырга килделәр. Синең дә ярдәмең булгандыр.

Кыяметдин. Мин инде зыян да сала алмый идем, ярдәм дә итә алмадым. Мин бары тик шөреп идем. Шөреп!

Айсылу. Мин аны соңыннан үзем дә аңладым. Ул елларда халык вагайды, мескенләнде. Куркакка әйләнде. Халык бергә укмашканда гына халык шул, аерым-аерым башны кистергәндә аны сарыкка әйләндерәләр.

Кыяметдин. Сезнең ирләр сарык түгел иде. Мин үзем кагылмадым, ләкин кыйнадылар аларны анда. Билдән бозлы суларда тоттылар, башларыннан төннәр буе түшәмнән салкын тамчы тамыздылар. Акылдан язсалар яздылар, аяк астына аумадылар. Күбесе «Яшәсен Сталин!» дип кычкырып үлде. Халык ышана иде шул.

Гадилә. Ә сез шул ышанычтан файдаландыгызмы? Менә минем нинди гаебем бар иде власть каршында, нинди?! Мин — артистка, мин уйныйм гына. Политиканы сез ясыйсыз. Нигә мин, йолдыз булып янарга туган җан, сигез ел буе Себер шахталарында күмер чабарга тиеш идем?! Кан төкерә идем бит мин, кан. Соңыннан, иреккә чыккач, канны аракы белән бастыра башладым. Нигә мин, татар карчыгы, картайган көнемдә аракы кибете тирәсендә йөрим?! Шул газапларны, хурлыкларны оныта алмаганга эчәм бит мин! Төшләремдә күмер чабам, һаман күмер чабам.

Җамал аның янына килеп баса, чәчennән сыйпый.

Их, Җамал, синең кебек телсез-чукрак булсаң, җиңелрәктер бу дөньяда.

Урам якта кемдер ишеккә килеп бәрелә. Ачы тавыш белән ярдәм сорап кычкырып җибәрәләр. Айсылу ашыгып ишеккә атлый. Эдик аңа каршы төшә.

Эдик. Ачма, картәби. Монда һәр төнне шулай.
Айсылу. Күрә торып кеше үтертикме?

Эдик. Син аларның законнарын белмисең. Бу — 37 ел гына түгел инде!

Исламия. Әй, алла! Ача күрмәгез! Шул теге еллардан исән калганны, бандит кулыннан үлимме? Ача күрмә... Аягым тартмаган иде... Ничек кайтырбыз.

Суфия. Бүген монда гына кунарсыз. Өй иркен. Сөйләр сүзләр күп. Гомер генә бетте.

Исламия. Мин калам, калам. Минем кәгазем дә бар...

Айсылу. Һаман кыйныйлар. Теге заманда югарыдагылар кыйнаса, бүген түбәннәр кыйный. Кая барырга? Ахырзаман... Ахырзаман...

Гадилә. Илле ел элек тә камерада идек, бүген дә камерада! Барыбер тоткын. Гомер буе тоткын. Барыгыз да тоткыннар! *(Үрсәләнеп көлә.)*

Кыяметдин. Ә син төбенәрәк төшеп уйла, төбенәрәк...

Гадилә. Барыбер тоткыннар! *(Залга.)* Сез дә тоткыннар. Безне кулга алганда нигә берегез дә сүз әйтә алмадыгыз? Сез күп бит, меңнәр, миллионнар, ә ул *(Сталин портретына ишарәләп)* — берүзе. Нигә безне якламадыгыз? Дәшмисезме? Чөнки сез үзегез дә тоткын. Ха-ха-ха!

Суфия. Тынычлан, Гадилә. Син — ябылганда гына тоткын. Мин — иректә дә тоткын. Гомерлек гөнаһны юарга бер төн генә җитәрме?

Эдик. Әбекәй! Син әллә кемнәрнең гаебен үз өстеңә алырга ашыкма әле, яме?!

Суфия. Кем гаепле дигән идең, менә тыңла, улым. Хәзер атаңны алырга киләчәкләр...

Эдик. Әллә син дә... бу карчык кебек... Саташа башладың инде, әбекәй? Әти күптән ята бит инде...

Суфия. Шул-шул. Күптән ята. Ә башы... Теге елларда башланды бит аның... Син кара, кара... Игътибар белән кара... Әнә, аста, бала имезеп утырам, ул мин. Имчәк баласы — ул синең атаң. Хәзер киләләр...

Сәхнә караңгылана.
Сәхнә алдыннан бер көтү булып толпа узып китә, урамнан кычкырган, елаган, сүгенгән тавышлар ишетелә.
Сәхнә караңгылана.
1937 ел.
Шул ук бүлмә. Суфия бала имезеп утыра. Ниндидер җыр көйли. Аста машина килеп туктаганы ишетелә. Кинәт ишекне каты дөбердәтәләр. Баласын күтәргән килеш, Суфия ишекне барып ача. Кыяметдин белән хәрби киемдәге бер хатын килеп керәләр. Артта — ике шаһит.

Суфия. Мин бит... сез... мин бит... *(Артка чигенә.)*

Кыяметдин. Шулай кирәк... Вакытлыча. Сиңа НКВДга барып кайтырга кирәк.

Суфия. Юк!!! Юк... Минем бит бер гаебем дә юк. Мин иремнән ваз кичтем, ваз кичәм! Мин халык дошманы хатыны түгел! Мин коммунист! Юк!!!

Кыяметдин. Шулай кирәк... Вакытлыча... Аңлыйсыңмы син — вакытлыча? Син анда кирәк. Аңласаң, ярар. Балаңны тапшыр. Аны балалар йортына илтеп торырбыз.

Суфия. Иртәгә әни кайтып җитә. Ул Айсылуларга гына китте. Айсылу... *(Туктап кала.)* Айсылуны да?

Кыяметдин. Белмим. Анда башкалар китте. Җыен.

Суфия. Вакытлыча? Кая? Сез мине төрмәгә утыртырга җыенасыз бит! Ни гаебем бар минем?! Мин бит инде иремнән дә баш тарттым. Өч баламның атасыннан баш тарттым, шуларны исән калдырам дип. Дөрес түгел бу хәл. Мин Сталинның үзенә язам!

Стенадагы рәсемгә барып асылына.

Кыяметдин. Иреңнән баш тарттың, ә атаң? Бөтен тирә-юньгә атаклы Сафа ишан? Үзеңнең Төркия белән элемтәң?

Суфия *(катып кала)*. Нинди... элемтә?

Кыяметдин. Анда шулай язылган. Анда барысы да билгеле. Баргач ачыкларсың. Гаепсез икән, чыгарырлар.

Суфия. Инде гүр ияse булган атамнан да баш тартыйммы? Тагы кемнән баш тартыйм?! Кемнән?!

Кыяметдин. Вакытлыча... Шулай кирәк... гаебең булмаса, кайтырсың.

Суфия. Аннан кайта алган кеше юк шул.

Кыяметдин. Тагын ике балаңның язмышын онытма!

Суфия «Ah!» дип кычкырып җибәрә.

Суфия. Аларына... аларына гына кагылма. Барысын да эшлим, бар нәрсәдән баш тартам — аларына гына кагылма.

Акрын гына килеп баласын хәрби киемле хатынга тапшыра. Хатын чыгып китә.

Суфия *(ишеккә ташлана)*. Улым! Ирем! Балам!

Елап, идәнгә ава. Үрмәләгән килеш Сталин рәсеме каршына тезләнә.

Атам урынына син калдың. Атам урынына син. Бөтен өметем синдә. Ташлама ярдәмеңнән?! Чәчем агарганчы сиңа хезмәт итәрмен, балаларымны сакла... Иптәш Сталин! Сөеклебез Сталин! Ярдәм ит! Коткар бу хәлләрдән. Мин дошман түгел! Дошманнар бар, ләкин мин түгел! Мин түгел!!!

Шаһитлар ике яктан алып, Суфияны алып чыгып китәләр.

Кыяметдин. Шулай кирәк... Вакытлыча... Шулай кирәк...

Чыгалар.
Тышта машина тавышы, бала елаганы, камера йозаклары ябылганы, этләр өргәне ишетелә.
Сәхнә караңгылана.
Сәхнә беразга яктырып ала. Беренче пәрдәдәге беренче күренешне күрәбез. Эдик йөзен каплап утырган. Урамда кычкырган, елаган тавышлар. Кыяметдин сузып-сузып Коръән укый.
Сәхнә караңгылана.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

1937 ел. Кремль төрмәсе. Хатыннар утыра торган камера. Өстә Кремль сәгатенең сукканы ишетелә. Түрдә — Сталин портреты. Алгы планда Айсылу белән Суфия.

Айсылу. Балаларыңнан хәбәр бармы, сеңелем?

Суфия. Ни булса да, язмаска куштым. Эзләрен белмәсеннәр, дидем. Исәннәрме-юкмы — үзем дә белмим.

Айсылу. Әни ничек түзә икән инде?

Суфия. Улыңны... авылга кайтардыңмы?

Айсылу. Тс-с! Дәшә күрмә. Ичмаса, ул исән калсын.

Суфия. Бәлки Октябрь бәйрәменә чыгарырлар? Бөтен хатыннар шул турыда сөйләшә бит.

Айсылу. Белмим, сеңелем... Һаман өсти торалар бит.

Суфия. Теге матур хатынны... Гадиләне бүген бигрәк озак тоттылар. Ни булыр икән?

Айсылу. Бик шикле алып чыгып киттеләр шул.

Алар янына Исламия килә. Кулында кәгазь.

Исламия. Минем кызларым миннән баш тарткан. Ничек алай була икән инде ул? Ничек ана кешедән баш тартып була икән? *(Елый.)*

Айсылу. Елама, Исламия. Безне монда озак тотмаслар. Кызларыңа үз телең белән аңлатырсың. Бала-чага ни язмас, елама аның өчен.

Исламия. Әллә Сталинның үзенә хат язып карыйммы икән? Ник безнең балаларны безгә каршы котырталар алар? Сталин боларның берсен дә белми бит, белсә, мондый хәлләр килеп чыгар идеме соң?

Айсылу. Илдә корткычлар да бардыр инде. Булмыйча калмас. Менә, тикшерерләр дә, гаепсезләрне чыгарырлар. Безне дә чыгарырлар.

Суфия. Октябрь бәйрәменә үк чыгармаслармы әле?

Исламия. Барыгызны да кунакка җыяр идем, кызлар. Өем иркен минем. Ирем шундый әйбәт. Кеше кил-

гәнне бик ярата. Октябрь бәйрәменә бәлки чыгарырлар дип, башкаларны да сөендерим әле. *(Китә.)*

Суфия. Анның ирен җәй башында ук атканнар икән, дип ишеттем. Үзе һаман белми икән әле...

Айсылу. Әйтмиләрдер. Бәлки, әйтеп тә ышанмыйдыр.

Суфия. Бәлки әле дөрес тә түгелдер. Безнекеләр ничек икән инде? Нурәхмәт суга төшкән кебек юк булды.

Айсылу. Нурәхмәт турында берни ишетелми шул...

Суфия. Җизнине монда, диләр...

Айсылу. Мин дә шулай дип ишеттем. Прогулка вакытында күргәннәр. Бик бетеренгән, ди. Әле ярый исән! Әле ярый исән! Төннәрен аткан тавыш ишеткән саен сикереп торам...

Кыяметдин керә. Кулында кәгазь.

Кыяметдин. Элеккеге язучы, хәзер халык дошманы Гомәр Гали хатыны?

Тавыш. Мин.

Кыяметдин. Элеккеге профессор, хәзер халык дошманы Сәлах Атнагулов хатыны?

Тавыш. Мин.

Кыяметдин. Элеккеге журналист, хәзер халык дошманы Вәли Шәфигуллин хатыны?

Тавыш. Мин.

Кыяметдин. Элеккеге обком работнигы, хәзер халык дошманы Габдрахман Мусин хатыны.

Тавыш. Мин.

Кыяметдин. Элеккеге язучы, хәзер халык дошманы Закир Гает хатыны?

Тавыш. Мин.

Кыяметдин. Элеккеге нәшрият работнигы, хәзер халык дошманы Зәки Гимранов хатыны?

Тавыш. Мин.

Кыяметдин. Элеккеге юрист, хәзер халык дошманы Мәҗит Әхәтов хатыны?

Исламия. М-и-ин...

Кыяметдин. Элеккеге бригадир, хәзер халык дошманы Мөхәмmәтша Әминев хатыны.

Җамал дәшми. Хатыннар аңа төртәләр.

Җамал. М-м-м! *(Мөгрәгән сыман итә.)*

Кыяметдин. Нигә мөгри ул?

Суфия. Телсез.

Кыяметдин. Сезгә бүген хөкем карары җиткереләчәк.

Айсылу. Суд... нинди хөкем карары? Безгә бит суд булмады.

Кыяметдин. Ирләрегезгә булды. Сез — халык дошманнарының хатыннары. Сезгә гомуми карар укылачак.

Айсылу. Сарык көтүе кебек сугымга саласыз инде?

Кыяметдин *(теш арасыннан)*. Күп сөйләшәсең... *(Суфияга.)* Бераздан минем янга керерсең. *(Ишекне ачып.)* Алып керегез...

Ике яктан култыклап, Гадиләне кертеп ташлыйлар. Кыяметдин чыгып китә. Хатыннар Гадилә тирәсенә җыела.

Исламия. Әллә кыйнаганнар инде, ходаем?

Гадилә *(башын күтәреп)*. Үтергәннәр...

Айсылу. Иреңнеме?!

Гадилә. Улымны... *(Чайкала-чайкала.)* Улымны, бәгырь кисәгемне... Үтергәннәр... Үтергәннәр... *(Читкә барып утыра.)*

Айсылу. Ялгыш аңлагансыңдыр. Балаларга... тимәсләр.

Исламия. Минем кызларым миннән ваз кичкәннәр. *(Елый.)*

Гадилә. Баш тартсын иде әле! Исән генә калсын иде. Иремнең исәнлеген белмим. Улым, үз муенына үзе элмәк салган. Нигә миннән алда киткән ул, нигә?!

Суфия. Үз-үзен үтергәнмени?

Гадилә. Бездән баш тартырга кушкач, следовательның битенә төкергән. «Сез ул дошманнар, минем әти-әни түгел!» дип. Үзен тотып төрмәгә япканнар. Шушы ләгънәт төшкән йортта, шушы стена артында!!! Иремне яптылар, улымны, үземне! Без бит артистлар гына идек, без бары артистлар гына идек бит! Ничек яшәргә хәзер?! *(Барып ишекне төя.)* Үтерегез! Мине дә үтерегез! Минем яшисем килми! Улым! Аһ! Үтерегез!!! *(Башын таш идәнгә бәрә башлый. Җамал йөгереп килеп аның башын тота, юата.)* Күралмыйм мин аларны! Ышанмыйм! Ишетәсезме! Беркемгә дә ышанмыйм. Сталинга да ышанмыйм. Ләгънәт Сталиныгызга!!!

Исламия аның авызын томалый.

Исламия. Дәшмә! Барыбызны да харап итәсең. Барыбызны атачаклар. Балаларыбыз хакына... дәшмә.

Айсылу. Инде үзеңне сакла, Гадилә. Бәлки озак тотмаслар, чыгарырлар. Иреңне дә чыгарырлар.

Гадилә. Ышанмыйм. Хәзер инде беркемгә дә ышанмыйм...

Ишектә тавыш. Бикмурзина Суфия — тикшерүчегә!

Айсылу. Зинһар, бер үтенечемне җиткер Кыяметдингә. Прогулкага чыкканда Галимҗан белән очраштырсын. Шушы йортта утыра бит инде ул. Бер генә күреп калыйм үзен. Зинһар, сора.

Суфия чыга.

Сакчы Суфияны озата бара. Әкренләп камера караңгылана, күренеш, Суфия артыннан, Кыяметдин бүлмәсенә күчә. Төрмәдә тикшерүче Кыяметдин бүлмәсе. Бүлмәдә Кыяметдин һәм Суфия.

Суфия. Вакытлыча гына дигән идең бит. Мин бит иремнән баш тарттым. Нишләп тотасыз мине монда? Нишләп тотасыз мине монда?

Кыяметдин. Дәшмә! *(Әкрен.)* Вакытлыча диелгән икән, димәк, вакытлыча булыр. Аның өчен чакыртмадым.

Суфия. Имчәк улым балалар йортында. Ничек эчем янмасын минем? Ник газаплыйсың син мине монда?! Җиде ят, ден дошманы да болай кыланмас. Без бит авылдашлар... И, аллам...

Кыяметдин. Дәшмә! *(Әкрен.)* Алланы куеп тор. Тагы ун ел чәпәрләр. Миннән тормый.

Суфия. Тагы? Ун ел? Ун ел?!

Кыяметдин. Дәшмә! *(Мәгънә белән.)* Мин берни дә әйтмәдем. Айсылуга алай әйтмәдем. Аңлыйсыңмы? Аңласаң, шул. Айсылуга әйт — *(әкрен)* күп сөйләшә. Артык күп сөйләшә. Акыллы хатын иде бит ул.

Суфия. Монда акыл калмый икән... Нишләргә? Кыяметдин! Әгәр минем ирекә чыгуым синнән тора икән, әйт, нишлим?! Нишлим?!

Кыяметдин. Камерада... ни сөйлиләр? Халык кемнәрне гаепли? Кемнәр властька каршы сөйли? Һәр төнне... шул турыда.

Суфия. Кемнәр *(Чигенә)*. Барысын да... әйтеп барам бит. Инде сөйләмиләр... Берни сөйләмиләр...

Кайсыдыр камерада яшь бала тавышы ишетелә. Суфия әсәрләнеп кала.

Кыяметдин. Молчать! Иптәш Сталин турында... ни сөйлиләр?

Бала елый.

Суфия *(әсәрләнеп)*. Иптәш Сталин турында? *(Аңлап алып.)* Ышанмыйлар! Ышанмыйлар!

Бала елый.

Кыяметдин. Кемнәр? Исемнәре?

Бала елый.

Суфия. Гадилә ышанмый! Күралмый ул аны! Чыгарыгыз мине моннан! Бирегез миңа баламны? Чыгарыгыз мине моннан!

Кыяметдин. Дәшмә! Тагы кемнәр нәрсә сөйли?

Суфия. Әйтәм! Баламны гына бирегез?!

Кыяметдин. Я?

Суфия. Исламия Сталинга хат язарга җыена.

Кыяметдин. Я? Я? Айсылу ни ди?

Суфия. Айсылуның бөтен курыкканы — баласын эзләп табулары. Ул — авылда.

Кыяметдин. Алай... Авылда... Тагы ни ди?

Суфия. Прогулкалар вакытында ире белән очраштыруын сорады. Ялварып сорады.

Кыяметдин. Һаман ялварамы? Ярар, күп ялварасы калмагандыр.

Суфия. Мине чыгарырсызмы? Чыгарыгыз мине моннан.

Кыяметдин. Вакыты җиткәч. Шулай кирәк. Бар.

Суфия чыгып китә.
Кыяметдин ялгыз. Йөренә. Кулына пистолетын ала. Карап тора. Запись-та Кыяметдин уйлары.

Кыяметдин уе. Боларга чик кую өчен бер пуля җитәр иде. Мин шушы мескен хатыннарны күзәтәм, мине башкалар күзәтә. Миңа дус та, дошман да ышанмый. Хәзер кем дус, кем дошман — белеп тә булмый. Бер пуля... Тормышта берни күрмәгән, сөелмәгән, нәсел калдырмаган килеш китеп барырга... Мин ачкан җинаятьләр саны аз диләр. Күбрәк тотарга кирәк, күбрәк утыртырга, күбрәк газапларга кирәк. Кемне тотарга?! Кешеләр авыз ачып сүз әйтергә куркалар, мескенләнеп күзгә карыйлар, саталар, сатылалар. Һәркем исән калырга тырыша. Башкаларны сатып булса да...

Бер пуля... Мин китәрмен, миннән дә явызы, миннән дә имансызрагы килер... Айсылу белән нишләргә?! Улы белән нишләргә? Нишләргә?!

Сәхнә караңгылана.

СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төрмә ишегалды. Ике түгәрәк ясап, бер якта ир-атлар, икенче якта хатын-кызлар йөри. Баш-башта — күзәтчеләр. Түрдә Кыяметдин карап тора. Тоткыннар бик начар, сәләмә киенгәннәр. Урамда кара көз. Җил улый, яңгыр катыш кар ява. Төркемнең берсендә — Галимҗан, икенчесендә Айсылу бар. Тоткыннарга сөйләшү катгый тыела. Эфирда аларның уйлары.

Айсылу уе. Галимҗан! Сине ничек газаплаганнар?! Аксыйсың да бит. Өс-башың да тетелеп беткән.

Галимҗан уе. Баш исән булсын, Айсылу! Иман исән булсын. Улыбыз исән булсын.

Айсылу уе. Бала авылда. Безне тиздән озаталар, Галимҗан.

Галимҗан уе. Ничә ел?

Айсылу уе. Сигез ел. Суфияга — биш.

Галимҗан уе. Миңа — егерме ел...

Айсылу уе. Егерме?! *(Сөрлегеп киткәндәй була.)*

Галимҗан уе. Исән булсам, алтмыш яшьлек карт булып кайтырмын. Күтәрсеңме?

Айсылу уе. Егерме ел... Синнән башка... Түзә алмам, Галимҗан... Барып җитә алмам ул көнгә.

Галимҗан уе. Түзәргә кирәк, бәгърем. Балабыз хакына, сөюебез хакына... түзәргә кирәк.

Айсылу уе. Бәлки әле... Гел бер тирәдә утырырбыз. Бәлки әле... амнистия булыр?

Галимҗан уе. Анысына ышанмыйм. Әле корбаннар күп булыр. Әле без — башы гына... Шундый сагындым үзеңне... кулларыңа бер генә кагылыр идем.

Айсылу сөрлегеп китә. Аның янәшәсенә туры килгән Галимҗан Айсылуга егылырга ирек бирми, сак кына аягына бастыра. Шундук ярсып этләр өрә башлый. Тоткыннар әйләнүләрен дәвам итәләр.

Галимҗан уе. Өрсеннәр! Кулларыңа орындым... Егерме ел түзәрлек дәрт алдым.

Айсылу уе. Син нинди көчле, Галимҗан!

Галимҗан уе. Син нинди гүзәл, Айсылу!

Айсылу уе. Тәшләремә керә күр, Галимҗан!
Галимҗан уе. Төшләремә керә күр, Айсылу!

Тоткыннарны ике якка алып кереп китәләр. Кыяметдин ялгызы кала.

Кыяметдин уе. Мине күрмәделәр дә... Әйтерсең, алар өчен төрмә дә юк, аерылу да, коточкыч киләчәк тә... Күзләре ничек яна, тәннәре ничек бер-берсенә тартыла... Алай да... иң куркыныч хәбәрне белмичә киттеләр. Уллары Газизҗанны балалар йортына тапшырырга дигән әмер бар. Шуны мин башкарырга тиеш. Тагы бер кара' эш минем кул белән эшләнә. Мин эшләмәсәм, башкалар эшләячәк. Миннән дә куркынычрак итеп эшләячәкләр. Үткән юлымны гәүдәләр белән күмә барам... Мин — барысы өчен дә дошман. Киләчәктә миңа аклану юк...

Ишегалды уртасында ялгызы басып кала.
Сәхнә караңгылана.

ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ачы итеп паровоз кычкыртканы ишетелә. Сәхнә бераз гына яктыра. Декабрь башы. Төн. Вокзал. Түрдә — Сталин портреты. Тоткын хатыннарны Себергә озаталар. Вокзал буйлап этләр, сакчылар йөгерешә. Сүгенгән, кычкырган тавышлар. Хатыннарны инде вагоннарга төяп бетергәннәр. Ишеккә асылынып, кемдер елый, кемдер шашып көлә. «За Сталина», «Сталин өчен!» дип кычкырган тавышлар ишетелә. Кем күккә карап кычкыра, кем караңгылыкка.

Поезд кузгалып куя. Акылдан язган бер рус хатыны буыла-буыла көлә дә, иелеп, үзенә өргән этнең танавына төкерә, аннан артка — хатыннар кулына чалкан ава.

Поезд кузгала. Әллә кайдан — вокзал почмакларыннан карт-карчыклар йөгереп чыга. Алар, сөртенә-сөртенә, поезд белән янәшә йөгерәләр. Кем сузып-сузып тәкбир әйтә, кем чукына. Русча-татарча кычкырган тавышлар.

— Кызым, бәхил бул, бәхил!..

— Балаларыгызны җыеп алдылар! Алып киттеләр балаларны!

— Ты не волнуйся! Самому напишем!
— Не виновата ты, не виновата!
— Кызым, алладан сора, алладан!
— Прощай, Надежда!
— Бәхил булыгыз! Бәхил... булыгыз!

Поезд бер якка хәрәкәт итә. Аңа капма-каршы, сәхнә алдыннан, балалар рәте үтеп китә. Карадан киенгән ятим балаларны икенче составка төяргә алып баралар. Балалар әниләре утырган поезддан башларын читкә борганнар. Барысы да хор белән җырлыйлар.

Сталин безгә бәхет бирде,
Сталин безгә тормыш бирде.
Сталин безгә әмер бирде
Сакларга туган илне.
Сак бул, Ватан, янәшәдә
Дошман күрсәтә угын.
Тамырына кылыч када —
Калтырамасын кулың!

Марш белән үтеп китәләр. Паровоз соңгы тапкыр ачы итеп кычкырта да күздән югала. Һавада елаган, җырлаган авазлар җыелып тора да барысы да тына.

Сәхнә аша тын гына башын иеп, бер кечкенә кыз бала үтеп китә. Кулына төенчек һәм курчак тоткан. Сабый үзенең билгесез язмышына таба бара... Аны автор тексты озатып бара: «Әле бу сабыйга үзенең кара язмышы буйлап озак, бик озак барасы. Аны махсус балалар йортына ябарлар, ата-анасының дошман икәнен миенә сеңдерерләр. Кулы, аңы белән бу бала ата-анасыннан ваз кичәр, җаны белән барыбер аларны сагыныр, елар. Халык дошманнары балаларыннан берне уйлап, икенчене эшли торган куркыныч типлар әзерләргә тырышырлар. Күпләр сынар, сынмаганнары ташка әйләнеп калырлар. Эчүгә сабышкан, кыйбласын югалтканнары да булыр. Тормыш тарафыннан алар әле озак, бик озак кыйналырлар...»

Пәрдә

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

1987 ел. Беренче пәрдәнең беренче күренешендәге бүлмә. Бүлмәдә Суфия, Айсылу, Гадилә, Исламия, Җамал, Кыяметдин, Эдик.

Эдик *(колакларын томалап)*. Җитте! Булды! Бер сүз дә сөйләмәгез! Гарык! Ишетәсезме, гарык! Һаман төрмә! Һаман богау! Жить не хочу!

Айсылу. Без илле ел дәшмәдек. Шул килеш китеп тә бара идек. Заман үзе искә төшерде.

Эдик. Һаман Сталин! Һаман шәхес культы. Ә без гаепләмибез аны! Көчле булган, менә болай тоткан! Ә сез, сарык көтүе кебек, үз аягыгыз белән...

Кыяметдин. Ә син түбәнрәк төшеп кара, түбәнрәк...

Гадилә. Бу малай дөрес лыгырдый. 20 миллион корбан!

Исламия. Сталин...

Гадилә. Нәрсә, Сталин? Сталиннар килерләр дә китәрләр. Сталин түгел, кешеләр үзләре гаепле, үзләре...

Суфия. Без нишли ала идек?! Менә мин нишли ала идем? Мин бит Җир йөзенә нәсел калдыру өчен генә яратылган. Мин ил өчен түгел, өч балам өчен генә җавап бирә идем бит! Мин җан сакларга тырыштым, җан!.. Ул кешеләрдә минем эшем юк иде. Барыгыз да җан сакларга тырыштыгыз бит, һәркемгә үз җаны кадерле иде.

Кыяметдин. Шулай... Җан кадерле иде. Беркем беркемне якламады. Һәркем үзе исән калырга тырышты. Ә син түбәнрәк төшеп кара, түбәнрәк...

Эдик. Ярый, исән калырга тырышуыгызны да аңлыйм. Ләкин нигә башкалар хисабына?! Нигә башкаларны батыра-батыра үзегез исән калырга тырыштыгыз? Ул җан аларда да булгандыр бит? Менә мин, бүгенге көннең бандит малае, шуңа җавап таба алмыйм — берничә ел эчендә ничек бер-берегезне шулай утыртып бетерә алдыгыз сез?

Бездә алай түгел... Без төрмәдә дә бер-беребезне сатмыйбыз... Их, сез, черек интеллигентлар.

Исламия. Минем кызларым да шулай ди... Үзегез гаепле, ди... Үзләре миннән баш тарттылар... Мин нишли ала идем инде. Мин нишли ала идем? Беркем шуны аңламый...

Айсылу. Безне гаепләү җиңел... Бик җиңел... Кешеләрнең бу турыда күп сөйләшәселәре дә килми... Кызык өчен бер шаулашып алдылар да, туя башладылар. Менә син дә, гарык, дисең, улым. Без илле ел ул җәрәхәтләрне яшереп яшәдек. Берегезгә бер сөйләмәдек. Безне гел куркытып тордылар. Хәзер исә кешеләрдә безнең кайгы түгел. Ләкин ялгышлар кабатланучан була... Шуны оныталар...

Эдик. Ә без, картәби, төкерәбез барысына да! Безгә сезнең үткәннәрегез кирәкми. Без беркемгә дә, бернәрсәгә дә ышанмыйбыз. Бары үз көчебезгә генә. *(Йодрыгын күрсәтә.)* Бөтен тормышыгыз ялганга һәм сатылуга корылган. Сез — корбаннар, сез мескен корбаннар гына. Без сезгә охшамабыз. Без, сезгә охшамас өчен, тимердән киенеп урамнарга чыктык. Без үзебезнең башны болай гына бирмәбез.

Айсылу. Тарихта ялгышлар кабатланучан була, балам... Без фикер көрәшендә корбан булдык. Ә сез? Сез бит — максатсыз көрәшчеләр.

Эдик. Безнең максат — мескен булмау! Безнең максат — кол булмау! Безнең максат — сезнең кебек булмау! Безнең максат — тимергә әйләнү!

Кыяметдин. Илдә тагын шундый афәт башланса, син нишли аласың, тимер йөрәк?

Эдик. Кырам! Барысын да рәттән кырам! Сезнең кебек сатып ятмам.

Кыяметдин. Кыру өчен әллә ничә баш кирәкми. Син, улым, түбәнәрәк төшәргә тырыш. Безнең ялгышларны аңларга тырыш. Кыручылар синнән башка да табылыр...

Суфия. Кил, тагы түбән кара... Әнә, аста күрәсеңме — ул — без утырган зона. Вышкада кораллы сакчы тора, зона буйлап кеше үтерергә өйрәтелгән овчаркалар чабып йөри. Алар безне — халык дошманнарының хатыннарын саклыйлар. Әнә ул баракларда без торабыз. Бараклар ягылмый — кышын идән-сәкеләр боз булып ката, җәен бет, кыргаяктан мыжлап тора. Без, хатыннар, унсигезәр сәгать шахтада эшлибез. Әнә анда, чыпта җәйгән бер нарда, бер хатын ята — картәбиең Айсылу ул. Шахта басты аны... Аңа ул чагында 37 яшь иде. Шуннан мәңгегә бөкерәеп калды... Кара, кара, хәзер хатыннар кайтып керә...

Сәхнә караңгылана.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Магадан лагерьларының берсе. Озынча барак. Түрдә Сталин портреты. Көн кичкә таба. Баракта Айсылу берүзе ятып тора. Берәздән, тезелешеп, тоткын хатыннар эштән кайта башлый. Гадилә, Исламия, Җамал да алар арасында. Исламия Сталин портреты янына килә дә, пыш-пыш сөйләшә.

Гадилә. Син бераз торып кара идең, Айсылу. Кояшка чыгып кара идең. Бигрәк йөзең юк.

Айсылу. Аягыма баса алмыйм... Бу шахта тәнне генә түгел, җанны басты... Арыдым. Яшисем килми.

Гадилә. Чү, чү, Айсылу, син болай түгел идең бит әле. Без егылганда да син егылырга тиеш түгел — сине балаң көтә.

Айсылу. Дүрт ел буе берни белмим. Авылда кала алдымы? Аңа хәзер унсигез яшьтер инде. Укыймы икән, эшлиме — берни белмим.

Гадилә. Синең хет... Искә төшермә! Әй, кызлар! Бүген концерт икәнен онытмадыгызмы? Безнең чират — татарлар чираты. Сабантуй ясыйбыз бүген, әзерләнегез. *(Айсылуга.)* Себер урманнарында күмелеп калырга җыенмыйбыз әле, борыныңны төшермә.

Җамал әкрен генә Айсылу янына үтә. Учындагы җиләген аңа бирә.

Айсылу. И, аллам, җиләк! Чын җиләк, чын җиләк! *(Исни, елый.)* Исен дә онытикан идем инде. Кайлардан алдың моны, Җамал? Әҗәл даруы бит бу, әҗәл даруы...

Җамал дәшми, елмаеп башын селки.

Гадилә. Аларны бүген конвой урман аша алып кайтты. Заключенный ирләр яткан больницаны җыештыра кайтканнар.

Айсылу. Ирләр?! Галимҗанны күрмәдеңме, Җамал?! Галимҗан турында белүче юкмы икән.

Гадилә. Телсез кешедән нәрсә таптырасың син? Ул Галимҗаның турында сорамаган кешең калмады бугай инде.

Айсылу. Гел... очрар кебек... Шушында — Колымада бит инде ул. Исемен генә ишетсәм дә терелер идем. Шушында бит инде ул...

Гадилә. Шушындадыр, шушындадыр. Монда җир астында да, җир өстендә дә алар аяк атлаган саен — каберләре, аяк атлаган саен сөякләре... Кызлар, Исламия нишли ул?

Исламияне җитәкләп алып китәләр. Исламия һаман үзалдына сөйләшә.

Айсылу. Исламия, нәрсә булды сиңа?

Исламия һаман пыш-пыш килә.

Гадилә. Әллә... тегеләй инде?

Айсылу. Исламия, бер-бер хәбәр ишеттеңме әллә?

Исламия. Комачау итмәгез! Мин иптәш Сталин белән сөйләшәм! Китегез! Анда барыбер чит кешеләрне кертмиләр.

Гадилә. Ах... шайтан алгыры... Көне буе әллә нишләп йөргән иде... Җитмәсә, конвой да кыйнады үзен... Харап була бит бу...

Исламия. Бүген төнлә төш күрдем. Тс-с-с! Сталинның үзен күрдем! Ике сәгать минем белән сөйләште! Ап-ак

бүлмәләр, ап-ак пәрдәләр... Ул чәчәк, чәчәк! Бөтен дөнья чәчәк белән тулган. «Мин синең иреңне беләм,— ди.— Мин аны үземнең генералым ясыйм,— ди.— Тиздән зур яу булырга тора, атка атланыр, кылыч алыр»,— ди. Шул вакыт... кызларым килеп керде... Аларга хәзер унҗиде яшь бит инде... Ап-актан киенгәннәр, кара чәчләре тезгә тиеп тора. Ул гүзәллек, ул пакьлек! Йөзеп киләләр кызларым, йөзеп... Үземнең өс-башыма карыйм, бетләремне генә күрмәсәләр ярар иде, дим. «Кызларыңны,— ди,— иң затлы сарайларда гына яшәтәбез, ди, иң зур галимнәр белем бирә, ди, иң затлы егетләр кулларын сорый, ди. Синең ризалыгың кирәк, шуңа күрә монда чакырттык», ди. Мин риза, дип әйтеп өлгермәдем, менә бу төртеп уятты. *(Елыйелый Гадиләне йолкый башлый.)*

Гадилә. Әйтәм җирле иртәдән бирле миңа бәйләнә... Их, Исламия... Кызларыңны күрүең әйбәт булган, бик әйбәт булган... Хәл ал бераз...

Исламия. Сез миңа юри комачау итәсез! Иптәш Сталин белән яңадан сөйләшмәсен, дисез! Ә мин менә сөйләшәм, сөйләшәм! Ул минем кызларымны ак сарайларда яшәтә!

Айсылу. Кил әле, Исламия, менә нәрсә бирәм.

Исламия. Җиләк... Юк, мин аны ашамыйм, мин аны кызларыма бирәм. Анда, ак сарайларда җиләк юктыр.

Гадилә. Исламияне сакларга кирәк. Җиңеләйгәнен белсәләр, харап итәрләр. Исламия, утырып тор шунда. Хәзер җырны кабатлыйбыз. Бүген безнең чират концерт бирергә. Җамал, син артка бас. Басып булса да тор. Айсылу, син карап ят.

Айсылу. Әллә Суфияны көтикме? Ни әйтер, староста бит. Бүген әллә нишләп озаклады. Сез эштән кайтканда гел монда була иде.

Гадилә. Әйдә, кабатлый торабыз. Тотып асмас әле. Себердән дә ары сөрмәсләр. Үзем башлыйм. Йөрәк яна! Кушылырсыз. Русча да, татарча да җырлыйбыз. Бүген безнең Сабантуй!

Широка страна моя родная,
Много в ней лесов, полей и рек!
Я другой такой страны не знаю,
Где так вольно дышит человек!

Җырлап бетерми, буыла-буыла көлә башлый.

Нигә кушылмыйсыз? Ошамыймы? Әйдә, алайса, үзебезнең доганы сузыйк.

«За власть Советов» җырын башлый. Аңа әкрен генә башкалар кушыла. Сәләмә киемле хатыннарның

Совет власте өчен
Без нык торырбыз,
Аның юлында без
Корбан булырбыз!—

дигән сүзләре бик кызганыч һәм авыр тәэсир ясый.

Гадилә. Их-х! Кызлар! Биим! Татарский танец. Исполняет известная татарская актриса, ныне заключенная Гадиля Казанская.

«Син сазыңны уйнадың» көенә үзе җырлап, шәрык биюе бии.

Их! Их! Их! Менә монысы да бар әле ул биюләрнең. Танец заключенных женщин! Исполняет заключенная Гадиля Казанская, шестьдесят пятый барак, седьмое место.

Безнең Ватан бер генә,
Чәчәк кенә, гөл генә.
Чәчәк асты, чәчәк өсте
Сөякләрдән көл генә.

Их! Их! Их!!! *(Шашып бии.)*

Айсылу. Акрынрак, Гадилә, ошатмаслар.

Исламия. Сталинга әйтәм. Мин аны бүген күрәм!

Гадилә. Мин бит Совет илен мактыйм! Мактаган өчен сүз юк. Татарский Сабантуй. Их! Их!!

Тыпырдап каршыларына бара. Ишектән килеп кергән Суфия белән бәрелешә.

С у ф и я. Хатыннар! Хатыннар... Туктагыз... Сугыш...

А й с ы л у. Сугыш?! Нинди сугыш?! Кем белән?

С у ф и я. Комендатурага хәбәр килде. Германия белән сугыш башланган.

И с л а м и я. Ә минем кызларым кай тирәдә икән? Аларны ак сарайлардан куарлар инде? Сугыш кай тирәдә бара? Кем белә, ул детдомнар кай тирәдә икән?! Белмисезме? Рус хатыннары белмиме? Кем белә, без кай тирәдә дә, сугыш кай тирәдә? Без кайда соң, кайда без?!

Барак буйлап бәргәләнеп йөри.

А й с ы л у *(торып утыра)*. Тукта, Исламия, вакытыннан элек хафаланма. Илдә балаларны сакларлык кына көч бар. Сугыш диген... *(Урыныннан төшә.)*

Г а д и л ә. Кызлар! Ур-ра-а!!

С у ф и я *(аның авызын тотып)*. Нишлисең син?! Сигез ел срок аз булдымы сиңа?! Сугыш башланганга кем сөенә?!

Г а д и л ә. Мин! Менә мин сөенәм! Төкерәм мин сезнең бу кыргаяклы барагыгызга! *(Итекләрен салып бәрә.)* Төкерәм срогыгызга! Менә мин хәзер Сталинның үзенә хат язам! Китәм! Сугышның үзәгенә керәм. Монда гына калмыйм!

С у ф и я. Тс-с! Дәшмә! Дәшмә!

И с л а м и я. И, ходаем, кем җибәрә безне?! Бөтен кеше шулай тиз генә лагерьдан чыгып качар иде. Кем җибәрсен сине... Сталин белсә әле...

Г а д и л ә. Тыныңны чыгарма. Каласың килсә, син кал әнә, борыныңны селкетергә дә куркып утыр. Ә мин китәм! Бүген үк гариза язам. Монда бетләп үлгәнче, сугышта үләрмен ичмаса! Китәм! Китәм!

С у ф и я *(каршына төшеп)*. Җүләрләнмә! Зэк икәнеңне онытма.

Г а д и л ә. Кит юлымнан. Мине хәзер берни тоталмый. Сугыш! Сугыш!!!

С у ф и я. Баракны атлап чыгуга — пуля сиңа! Бүген особый контроль. Син алар өчен — контр, халык дошманы. Ил синдәйләрнең ярдәменә мохтаҗ түгел.

Гадилә. Миңа... кешечә үләргә дә мөмкинлек юкмыни инде? Мин бит — үзем теләп! Хатыннар, нигә дәшмисез, мин бит үзем теләп. Нәселемә калдырасым килми бу кара тапны. *(Суфияга.)* Шуны да аңламыйсыңмыни син?!

Суфия. Аңлыйм. Элек аңламаганнарны да аңлый башладым. Син дә аңла, кайнар баш. Илгә нинди бәла килсә дә, бездән — халык дошманнарыннан күрәчәкләр. Хәтта шушы сугышны да! Әле бу бараклар тар булырга мөмкин. Сез... андагыларның ни сөйләгәнен белмисез. Без кеше түгел алар өчен! Һәм булмаячакбыз да, кисәтми атачаклар. Бу төндә бpraktан чыгу юк. Конвой килмичә, тыныгызны да чыгарасы булмагыз.

Исламия. И, алла! Тыныч кына утырып бетерик инде. Өстәмәсеннәр генә. Ярты срок үтте бит. Мин Сталинга үзем әйтермен, балаларны ак сарайларда гына тотыгыз, дип. Сез курыкмагыз, ул мине тыңлый.

Айсылу. Балалар... ут эченә барып керә икән. Бәхилләшә дә алмый калам икән! Газизҗан! Улым! Тагы дүрт ел! Тагы дүрт ел!

Суфия. Ярый, апа, үлмәс борын күммик әле балаларны. Аңынчы бәлки әле сугыш та бетәр. Ни әйтсәң дә безнең илне җиңәрлек көч юк әле бу дөньяда. Иртәгә ничек булса да шахтага төш. Особый тикшерү булачак.

Отбой! Отбой! Җамал, Гадилә, сез бүген төнге дежурда. Керфек кагасы булмагыз.

Гадилә белән Җамал баракның икесе ике башына барып утыралар.

Сәхнә караңгылана.

Баракка төн килә.

Өстә урман шаулый. Ерактан сугыш тавышлары ишетелә. Барак авыр, саташулы йокыга тала. Тоткын хатыннар йокыга китүгә барак эче балалар белән тула. Бу — тоткын хатыннарның төшкә кергән балалары. Алар әкрен генә аналары яткан нарлар янына киләләр, аларның чәчләреннән сыйпыйлар. Балалар барысы да бүген ак күлмәкләрдән, яланаяк. Һәрберсе үз анасын эзләп табарга тырыша. Хатыннарның кайсыдыр саташып елый, кайсы баласының исемен әйтеп кычкырып куя. Балалар шәүләләр кебек әкрен генә йөриләр дә йөриләр. Тәрәзәдә таң яктысы күренә, урамда чаң суккач, балалар качып-таралып бетәләр. Барак эче яктыра. Хатыннар

кирза итек, соры халатларын киеп, барактан чыгып китәләр. Айсылу да аларга ияра. Аны ике яктан култыклаганнар. Хатыннар чыга, магнитофонга язылган автор тексты аларны озата бара.

Текст.

«Сугыш әле дүрт ел дәвам итәр... Тоткын хатыннарның туган авылларына, шәһәрләренә кадәр барып җитәр ул сугыш. Көнбатышка, ятимнәр йортына озатылган балалары дошман кулында калыр. Кайберләре Германиягә озатылыр, кайберләре урында ук юк ителер. Сугышка яше кергән ир балалар, әти-әни калдырган кара тапны юабыз, дип, гариза язып, үзләре теләп фронтка китәрләр, сугышның беренче көннәрендә үк танк эчләрендә янып үләрләр, эзсез югалырлар.

Бу тоткын хатыннар хәзергә әле бернәрсә дә белмиләр. Аларга хат алу да, хат язу да тыелган. Алар бары тик бер нәрсәне — сроклары бетәсе көнне генә беләләр. Биш елга хөкем ителгәннәр 1942 елның 20 августында кайтып китәрләр, сигез елга хөкем ителгәннәр, тирән шахта төпләрендә тилмереп 1945 елның 20 августын көтәрләр. Бу көнгә кадәр килеп җитә алмаганнар да булыр...»

Сәхнә караңгылана.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Яктырганда Суфия яши торган йортның ишек төбен күрәбез. Кулына төенчек тотып, бөкрәеп ишек төбендә бер карчык басып тора. Сак кына ишекне кага. Озак кына ачмыйлар. Тагы кага. Ишектә Суфиянең куркынган йөзе күренә. Хатынны күргәч, ул кычкырып җибәрә дә, авызын каплый. Як-ягына карана. Аннан хатынны тиз генә өй эченә тартып ала. Ишекне кат-кат бикли. Тәрәзә пәрдәләрен кора, өстән, тагын нидер яба. Аннан соң гына башын иеп утырган хатын янына килә. Бу хатын — лагерьдан кайткан Айсылу.

Суфия. Күрүче булмадымы?

Айсылу. Караңгы бит... Син... гаепләмә инде. Безнең йортта чит кешеләр яши бит. Кайтып егылырга башка урын юк.

Суфия. Я, өсләреңне сал. Мин сине августта ук көтә башлаган идем инде. Озаграк кайттың. Сине көтүчеләр бер мин генә түгел монда.

Айсылу. Сугыш беткән икән бит. Бөтен эшелоннар хәрбиләр белән тулы. Айдан артык кайттым. Үзең беләсең бит документларның нindileген. Акча мәсьәләсе дә...

Суфия. Алай да монда ашыгыбрак килгәнсең. Мин үзем дә монда тормыйм. Син дә, мин дә Казаннан җитмеш чакрымда гына урнаша алабыз.

Айсылу. Беләм. Әни янына килдем.

Суфия. Әниең хәле авыр. Кисәк күренмә. Йөрәге чыдамас. Әле йоклый. Килеп-килеп аны карап китәм. Үзем Арчага идән юарга йөрим. Эшкә алмыйлар.

Айсылу. Мин дә берәр яры китәрмен. Бик бетерендем. Бераз ял итим.

Суфия. Бүген икебез дә кунарбыз. Иртүк, караңгыда чыгып китәрбез. Күршеләр күзәтеп кенә торалар. Үзең беләсең, безгә ышаныч юк.

Айсылу. Беләм. Юл буе шуның газабын күрдем... Әле ярый әнигә, квартираңа кагылмаганнар. Балаларың ни хәлдә?

Суфия. Ирекне әни детдомда озак тотмаган — берәр елдан барып алган. Олылары апа янында иде бит, үзең беләсең. Хәзер дә шунда, монда кайтарырлык түгел бит.

Айсылу. Ирек йоклыйдыр инде? Сагындым, аны да сагындым. Без киткәндә имчәк баласы иде бит. Газизҗанга... охшаганмы?

Суфия. Бераз бар. Туганнан туган бит.

Айсылу. Сеңелем! Килүемнең сәбәбе... дөресен әйтим... әни дә түгел, син дә түгел. Сорарга йөрәгем җитми. Газизҗан турында бер хәбәрем дә юк. Исәнме, үлеме, кайда — берни белмим. Исән булып кайтса, монда кермичә калмас иде. Сезгә... берәр хәбәр юкмы?

Суфия. Бездә хәбәр бар, апа...

Айсылу. Шулаймы? Ник аны баядан бирле әйтмисең соң?! Хәер, мин сорамадым да бит. Әллә нишләп... курык-

тым... Хәсрәтнең иң зурысы лагерьларда түгел, монда кәтәдер кебек...

Суфия. Ул хәбәр инде 41дә үк килгән булган. Газизҗан монда әниләргә хат язып торган бит... Хәбәре дә монда килгән.

Айсылу. Хәбәре? Үлгән? Үлгәнме? Плен төшкәнме?

Суфия. Танк эчендә... янып үлгән. Апа! Апа! Берәр сүз әйт ичмаса! Ела! Ела! Еласаң, җиңелрәк булыр.

Айсылу кыймылдый да, сүз дә әйтә алмый.

Апа! Куркытма мине. Син бит инде төрмәләрне күргән кеше. Ела, кычкыр, орыш — болай басып торма.

Айсылу *(һәр сүзен өзә-өзә)*. Елый... да... алмыйм... шул... Яшь... бетте...

Суфия. Син сөйләш, сөйләш, апа! Әни дә шушы хәбәрдән егылды. Әле ярый мин кайтып җиткән идем.

Айсылу. Бер өметем бар иде... ул да сүнде. Ничек яшәргә, сеңелем?! Арыдым мин. Яшисем килми! Яшисем килми!!! Улым юк, иремә тагы унике ел! Газапланып арыдым, кәтеп арыдым!

Суфия. Монда хәлләр яман әле, апа! Безне бит... яңадан җыялар.

Айсылу. Ничек җыялар?

Суфия. Миңа кагылмаслар мөгаен. Мин бит инде теге елларда ук иремнән баш тарткан идем. Сиңа тагы НКВДдан хәбәр бар. Үзең кайтканчы ук килеп житте. Әнинең монда торганын беләләр. Җизнидән отказ бирмәсәң, яңадан алулары бар.

Айсылу. Яшьлегемне бирдем, сәламәтлегемне бирдем, улымны бирдем, инде иремне дә биримме? Сигез ел утырып чыкканнан соң?!

Суфия. Әнине уйла. Сине тагын алсалар, ул үлә. Сиңа җизнидән баш тартырга кирәк. Син хәзер төрмәдә утыра алмыйсың. Соң, кара үзеңә. Аягыңда чак басып торасың бит! Баш тарт, апа?!

Айсылу дәшми.

Я, нинди рәхәт күрсәтте ул сиңа? Шуның аркасында төрмәдә утырдың, шуның аркасында баласыз калдың. Үз теләге белән киткән бит Газизҗан сугышка! Яше җитмәс борын! «Әти-әни китергән кара тапны юам» дип киткән. Беренче көннәрдә үк җанып үлгән... Соң, уйла, исән кайтса да, җизнигә 60 яшь була бит инде! 60 яшь! Ул кайтканда сиңа 53 яшь була! Ярар, элек, яшь вакытта, мин аңлыйм инде, яратыша идегез. Төрмәдән соң җизнидә ул хис калыр дисеңме?

Айсылу. Беләсеңме, сеңелем... Миңа инде барыбер. Миңа инде берни кирәкми. Шахта тачкасы тартып арыдым мин, җаным арыды, таушалды! Ник газаплыйсыз сез мине?! Миннән сезгә тагы ни кирәк?! Алыгыз, алыгыз, барысын да бирәм. Тик миңа гына кагылмагыз! *(Өстәлгә сыгылып төшә.)*

Суфия. Мин сине барыбер яңадан анда җибәрмим! Баш тарт, апа! Анда тагын китсәң, син кайта алмаячаксың. Бер сүзең җитә бит, бер сүзең!

Айсылу. Миңа инде барыбер... Бөтен дөньям караңгы... Киләгәчем аннан да караңгы... Мин Галимҗанның... йөзен дә оныттым инде... Шахта тузаны каплады... барысын да...

Суфия. Соң, шулай булгач?! Әллә исән, әллә үле, әллә кайта, әллә юк. Бер утырдың — җитәр. Куй менә монда кулыңны *(кәгазь бирә)*.

Өстән, өстәге күренештән Эдикның кычкырганы ишетелә.

Эдик тавышы. Картәби, куйма! Җизни исән бит. Картәби, куйма кулыңны! Сатасың бит! Иреңне сатасың...

Айсылу. Газизем тавышы килгән кебек булды. Башым әйләнеп китте.

Суфия. Ирек ул. Саташып кычкыра. Детдомнан шулай саташа торган булып чыкты. Нәрсә әйткәнен һич аңларлык түгел... Миңа да бик авыр, апа. Әни үләргә ята, Ирек больницадан чыгып тормый. Инде син дә яңадан китсәң... Яшәп бетерик бергә, куй кулыңны.

Айсылу. Миңа... барыбер инде. Барысы да бетте. *(Кулын куя.)*

Суфия. Булды. Иртәгә үк үзем илтеп бирәм. Син барып йөрмәссең, үзем аңлатырмын. Иртәгә әни янында калырсың. Мин өстегездән бикләп чыгып китәрмен. Урамга чыгып йөрмәссең. Кеше күзенә күренмәссең.

Айсылу. Кайда бикләсәгез дә... миңа барыбер...

Сәхнә караңгылана.

Язмада автор тексты:

«Халык дошманнары хатыннары... Ирләре өчен бер тапкыр утырып чыккач та, аларга әле тынгы булмас. Яңадан алу белән куркыткач, күпләр ирләреннән ваз кичәр. Ләкин аңа карап аларга җиңеллек килмәс. Картлык көннәренә хәтле даими прискалары да, йортлары да булмас. Кайчандыр гимназияләр, институтлар тәмамлаган затлы хатыннар мунча сәкеләрен юып, идән себереп көн кичерерләр. 37 елда сугылган кара мөһерне әле алар озак еллар күтәреп йөрерләр, күпләр шул мөһер белән китеп тә барыр...»

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Суфиялар яши торган йорт яны. Таягын алга сузып, шакылдатып бер сукыр карт узып бара. Таякка таянып, өйдән Айсылу чыга. Сукыр карт, йортка җиткәч, туктап кала.

Карт. Бу тирәдә адәм заты бармы?

Айсылу. Барын бар... Ни йомыш, бабай?

Карт. Бу йортның беренче катында элек Суфия атлы хатын яши иде. Хәзер дә торамы икән?

Айсылу *(шикләнеп)*. Хәзер дә... биредә яши. *(Картны әйләнеп чыга.)* Син кем буласың соң, бабай?

Карт. Үтеп баручы.

Айсылу аңа якын ук килеп карый. Карт, битен каплап, стенага сөялә.

Шулай, үтеп баручы гына. Яшиләрме икән, дигән идем. *(Китәргә җыена.)*

Айсылу. Зинһар, тукта... Син... Галимҗан бит...

Галимҗан. Галимҗан шул... Ә син...

Күрмичә, икенче якка атлый.

Айсылу *(аның кулыннан алып)*. Монда мин, Галимҗан.

Галимҗан бармаклары белән Айсылуның йөзен капшап карый.

Галимҗан. Син... карчык кеше. Бик күпне күргәнсең булыр. Йөзең җыерчыклар белән сырланып беткән. Бик күпне күргәнсең, ахры.

Айсылу *(шок хәлендә)*. Дөнья читләренә хәтле бардым шул. Тик синнән башка гына.

Галимҗанның кулыннан шылтырап таягы төшеп китә.

Галимҗан. Айсылу?! *(Кулларын сузып, аны эзләнә.)* Айсылу!

Айсылу. Үлгәнче бер очратырмын дигән идем...

Тын гына торалар.

Галимҗан. Мин бу тирәдән көн саен үтеп китәм бит... Көн саен шулай эндәшеп карыйм. Исән булсаң, тавышыңнан танырмын дигән идем. Танырлык түгел икән.

Айсылу. Мин таныдым. Син... үзгәрмәгәнсең, Галимҗан. Миңа... рәнҗемисеңме?

Галимҗан дәшми.

Айсылу. Бала турында беләсеңме?

Галимҗан. Беләм. Кайтуга, военкоматка киттем. 41 дә үк... диделәр...

Айсылу. Шул хәбәрдән соң сындым. Безне яңадан җыя башладылар. Синнән... баш тарттым.

Галимҗан. Беләм...

Айсылу. Казанга кертмәделәр. Авылга киттем. Ятим балаларны жәлләп, бер көтүче картка кияүгә чыктым.

Галимҗан. Беләм... Башта бик авыр булды. Синең баш тартканыңны белсәм, мин тегендә үк ятып кала идем. Соңгы елларда бик авырга туры килде. 20 ел шахтадан чыкмадым.

Айсылу. Рәнҗемә миңа, Галимҗан. Ничек тә яшәргә кирәк иде... Көтә алмадым.

Галимҗан. Башта бик авыр булды. Үз-үземә кул салырга да уйладым. Аннан... көтмичә дөрес иткәнсең дигән фикергә килдем. 60 яшьлек сукыр карт булып кайттым бит мин аннан. Тәнем тулы җәрәхәт, эчем тулы чир белән. Син белгән ир идемме инде мин?!

Айсылу. Мин дә ташка әйләнгән идем инде. Тормышка да балаларын жәлләп кенә чыктым. Өлкән яшьтәге кеше иде. Инде үлгәненә дә җиде ел. Синең кайтканыңны ишеткән идем. Суфия күреп калган булган. Безнең җизнигә охшаган иде, ди.

Галимҗан. Бөтенләй сукырайгач, бер хатын килеп булышкалый башлады. Аннан торып калды. Хәзер бергә яшибез.

Айсылу. Караучың бар икән әле...

Галимҗан. Һаман авылда яшисеңме?

Айсылу. Ирем үлгәч, үги балаларым Казанга алдырды. Хәзер аларда яшим.

Галимҗан. Әбекәй... әниең... вафаттыр инде?

Айсылу. Җеназасыннан чыгып киләм. Туксанга җитеп үлде. Үлгәндә сине дә исенә алды.

Галимҗан. Әйбәт кеше иде. Бергәләп яшәргә генә насыйп булмады. Үтте дә китте гомер. Яшәмәгән дә кебек... Башка күрешмәсәк, бәхил бул, Айсылу.

Айсылу. Син мине кичерә алмассың инде, Галимҗан? Гаебем зур. Кичерә алсаң, кичер мине. *(Алдына тезләнә.)*

Галимҗан. Синең гаебең юк, Айсылу... Мин булмасам, син бу авырлыкларны күрер идеңме? Бәхет өчен туган идең бит син. Дөнья миннән көчлерәк булып чыкты.

Берни эшли алмадым синең өчен... Берни эшли алмадым.

А й с ы л у. Күрешә алмасак, бәхил бул...

Г а л и м җ а н. Бәхил... мең бәхил... Мең бәхил...

Таягын шакылдатып, Айсылу яныннан үтеп китә.

А й с ы л у *(пышылдап)*. Бәхил бул...

Сәхнәгә яшьләр төркеме атылып керә. Тезләнеп утырган карчыкны күреп, алар аның алдына вак акчалар ташлап китәләр.
Сәхнә караңгылана.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

1987 ел, 20 август төне.
Суфиялар бүлмәсе. Бүлмәдә Суфия, Айсылу, Гадилә, Исламия, Җамал, Кыяметдин, Эдик.
Сәгать төнге уникене суга.

С у ф и я. Төннең уртасы, гомернең ахыры җитте. Күп сөйләштек, иң мөһиме әйтелмәде.

Э д и к. Сатканыңны әйттең, әбекәй. Тик синең сатуың боларның барысының да сатуы кебек кенә ул. Юкка борчылма.

С у ф и я. Юк, алай гына түгел. Минеке аерым. Таш булып җанымны басты, әйтергә ирек бирегез.

А й с ы л у. Гаепләрне эзләмик, сеңелем. Яңа корбаннар кирәкми. Алай да... Кыяметдингә рәнҗешем зур... Теге вакытта... улым артыннан ник кайттың син? Аның авылда икәнен белеп, исәнеп?

С у ф и я. Апа, зинһар, артыгын әйтмә. Кыяметдиннең гаебе юк. Газизҗанның авылда качып ятканын аңа мин әйттем.

Бөтенесе дә гаҗәпләнеп аңа карыйлар, Гадилә йокымсырап утырган җиреннән сискәнеп, башын күтәрә.

Мин әйттем. Теге вакытта... Кремль астында утырганда... барысын да Кыяметдингә сөйләп бардым. Гадиләнең Сталинны сүккәнен дә... Исламиянең мондагылар өстеннән Сталинга хат язарга җыенуын да... Айсылуның баласын яшерүен дә... барысын да сөйләп бардым.

Гадилә. Менә нәрсә өчен сиңа биш ел да, миңа сигезне биргәннәр икән! Безнең җанны сатып исән калмакчы булгансың икән!

Суфия. Баламны... күкрәгемнән аерып алдылар. Елаган тавышы гел колагымда торды. Сиңа... югалтырга инде берни дә калмаган иде. Улың...

Гадилә. Әйе, минем улым юк иде инде. Ирем дә юк иде — лагерьдан качкан вакытта этләр талап үтергән үзен. Синең менә Казанга кайтып керергә йортың булды. Мин гомерем буе читтә бәрелеп-сугылып йөрдем бит. Казанга кертмиләр. Театр турында әйткән дә юк. Театрсыз яши дә алмыйм — артистка бит мин! Сталин үлеп, законнар бераз йомшаргач, театрга идән юарга алдылар. Кайчандыр үзем уйнап йөргән сәхнәне, ирем шунда калдырган эзләрне күз яшьләрем белән юа идем бит мин! Төннәрен, берүзем сәхнәдә калганда, онытылып, уйнап китә идем. Аннан... эчә башладым... Шахтада үпкәләрем бетте — кан төкерәм. Бөтен тормышым бетте — кан йотам. Син, улым, дисең... Улымның йөзен дә оныттым бит инде мин!!!

Суфия. Кичер! Кичерегез!! Гомер буе шул гөнаһым җанымны талады. Теге дөньяга да алып китә алмыйм. Аякларыгызга егылып кичерү сорыйм. Тау кадәр гөнаһ белән... үлем дә алмый үземне!

Кыяметдин. Юкка бетеренмә, Суфия. Юк синең гөнаһың.

Гадилә. Нәрсә, син Коръән чыгып бетердеңме әллә аның гөнаһларын?

Кыяметдин. Теге вакытта... аның әйткәннәрен мин берсен дә бер җиргә дә тапшырмадым. Барысы да... үз эчемдә калды.

Суфия. Әйтмәдең?! Мин аларны... сатмадым булып чыгамы?! Минем аркада алар газап күрмәде булып чыгамы?! Әйт тизрәк, минем алар каршында гаебем юкмы?!

Кыяметдин. Юк. Син дә, алар кебек үк корбан идең.

Суфия. Я, хода! Хәзер үзеңә алсаң да сүзем юк! Кара кайгылар төште өстемнән... Минем гаебем юк...

Айсылу. Ә Газизҗан — кем корбаны? Баланың авылда икәнен сез генә белә идегез. Син, Кыяметдин, аны үз кулларың белән бәйләп алып киткәнсең!

Кыяметдин. Акланмыйм. Алып киттем. Үз кулларым белән бәйләдем.

Айсылу. Галимҗанның... нәселе калмасын дидеңме?

Кыяметдин. Ул әле Галимҗан малае гына түгел, синеке дә иде. Күзләре, иреннәре, йөзе — нәкъ син иде...

Айсылу. Шуңа күрә рәхәтләнеп ботарладың, газапладың инде.

Кыяметдин. Син минем хәзер... бер сүзгә дә ышанмаячаксың. Ышанма да. Тырышмыйм да. Дөресе шул. Менә Коръән. Уемда явызлык юк иде. Балагызны детдомга озатырга, дигән хәбәрне ишеткәч, бу эшкә үзем алындым. Гадиләнең улы кебек, кызулык белән берәр нәрсә эшләмәгәе дип курыктым. Башкалар кулына төшсә, кыйнарлар, дип тә курыктым. Авылда үзен чак тоттым. Әллә нәрсәләр кычкырып бетерде. Ул сүзләр өчен аның үзенә кимендә 20 ел иде. Бәйләргә туры килде. Юлда бераз тынычланды. Мин аны, вакытлыча детдомга урнаштырып, соңыннан үземә алырмын, дигән идем. Сезнең каршыда гаебемне башкача юа алмасымны белдем. Газизҗанга шуларны аңлаттым. Акыллы малай иде. Ризалашты. Аны алып кайтып тапшырганның икенче көнендә... үземне дә утырттылар. Шуннан соң мин аны күрмәдем.

Айсылу *(Кыяметдингә)*. Мин сине... гомер буе аңлый алмадым. Нинди бәндә соң син?

Кыяметдин. Бәндә? Дөрес әйтәсең — бәндә. Кеше идем, бәндәгә әйләндем. Ләкин — Алла шаһит — күңелем

яхшылыкта иде. Сине дә коткарасым килде, үземнең дә исән каласым... Дөрес, берәүгә дә тырнак белән дә кагылмадым, ләкин күпләр минем кул белән алынды. Ата-аналарын алып чыгып киткәндә, балаларының күзләрен хәтерлим! Алар бит аңа *(Сталин рәсеме ягына күрсәтә)* Аллага караган кебек карадылар. Ә гаепле кеше мин һәм минем кебек... шөрепләр иде. Барысы да бик уйлап эшләнгән булган шул, бик уйлап... Җан саклау өчен адәмнәр нәрсәгә генә бармады. Шуннан файдаландылар. *(Эдикка.)* Гаепләнә эзлисең икән, боларны да бел, энем. Беркайчан да шөреп булма! Башкалар кулында корал булма! Кеше кечкенә, мескен булырга тиеш түгел. Кеше бит ул! Кеше...

Эдик. Ә кем гаепле? Тагын сорыйм — моның шулай булуына кем гаепле? Тимергә төренергә мәҗбүр булган безнең буынмы? Юк-к!! Безнең ышаныр нәрсәбез калмады, шуңа күрә барысын ватабыз да җимерәбез. Кайда Аллагыз, кайда идеалларыгыз?! Үткәннәрне гел яндыра, юкка чыгара барасыз. Безнең тимердән төренүебезгә син генә гаепле! *(Кыяметдингә төртә.)* Карышмыйча кемне кушсалар шуны барып алгансың. Син! *(Айсылуга төртә.)* Нәселеңә ут төртсәләр дә һаман кызыл коммунист булып калгансың. Янәсе, ил белән күргәннәр, янәсе, ил белән утырганнар. Син фанатик булуың белән гаепле! Син! *(Суфияга төртә.)* Үз җаның өчен калтырып, боларның барысын да сатып яткансың. Бер дебильный ул үстергәнсең. Ул дебильдән — мин, таш җанлы кеше тудым. Синең муеныңнан таш төшмәде, менә мин бар әле, гомерлек таш! Син! *(Гадиләгә төртә.)* Эчеп-исереп, син төрмәдә утырган барлык хатыннарга тап төшерәсең. Янәсе, төрмәгә шундыйларны гына утырталар, янәсе, төрмәдән шундыйга әйләнеп чыгалар. Син! *(Исламиягә төртә.)* Башыңны җүләргә салып, илле ел бикләнеп ятасың. Җүләрләр кыйбла була алмый. Җүләрләр Алла була алмый! Бәлки синдер, телсез карчык?! Дәшмичә җан сакларга уйладыңмы?

Җамал. Юк!! Юк!!! *(Аягына егыла.)* Утыртмагыз мине! Мин телсез түгел! Телсез түгел мин... Утыртмагыз

мине... *(Идән буйлап шуыша.)* Күп сөйләшсәң, телеңне тартып өзәбез, диделәр. Үлгәнче тыныңны чыгарасы булма, диделәр. Башта... *(Стенадагы Сталин рәсеменә күрсәтеп.)* ул кешедән курыктым, аннан Хрущев дигәннәре килде — аннан курыктым, аннан — Брежнев дигәне килде — аннан курыктым. Аннан улым үсеп җитте, контр дип кыйный башлады — аннан курыктым. Гомер буе телемне аркылы тешләп яшәдем. Телсез түгел идем бит мин! Түгел идем! *(Үкереп елый.)*

Суфия. Без... телсез... Без... телсез. *(Ава.)*

Айсылу. Суфия! Сеңелем! Тәрәзәләрне ачыгыз! Куллары суына!.. Эдик, врач чакырт! Сеңелем! Сеңелем, ач күзеңне...

Суфия. Мәшәкатьләнмәгез. Сәгатем сукты.

Урамда кычкырган, елаган, сүгенгән тавышлар ишетелә.

Айсылу. Бар, улым, чакырт врач! Күрәләтә кеше үтереп булмый бит! Бар, чакырт.

Суфия *(башын калкытып)*. Йөрмә, улым... Үзеңне харап итәрләр... Син яшә...

Эдик. Әби! Әбекәй! Үлмә, әбекәй! Мин ул сүзләрне ачудан гына әйттем бит, әбекәй. Җаныма урын тапмаганнан әйттем. Юк сезнең гаебегез, юк!..

Суфия. Аны... каплап куй. *(Стенадагы Сталин рәсеменә күрсәтә.)* Үлememне күреп куанмасын. Үлмим әле мин, үлмим... Нурәхмәт! Нурәхмәт.

Эдик. Әбекәй!..

Суфия. Бабаң... янына китәм... Дөньяда... сез каласыз. Бер-берегезне саклагыз... Бер-берегезне сатмагыз... Безне... онытмагыз... *(Үлә.)*

Эдик. Әбекәй!!! Әбекәй!..

Урыныннан сикереп тора. Чайкалып бүлмәне әйләнеп чыга. Сталин портреты каршына килә. Ике куллап пыялага китереп суга. Пыяла ватылып, идәнгә коела. Портрет та идәнгә төшә. Эдик пыяла кисәкләрен, портретны елый-елый аягы белән таптый.

Э д и к. Пыяла гына булгансың бит үзең... Пыяла гына... Әби, менә капладым, әби, менә юк инде ул кеше. Әбекәй, үлмә генә, үлмә генә. Шул хәтле күпкә түзгәнне, азга гына түз. Түз, әбекәй! Хәзер врач алып киләм! *(Чыгып йөгерә.)*

Карчыклар Суфияны әйләндереп алалар. Кыяметдин сузып-сузып ясин чыга башлый.

Урам. Өйдән атылып чыккан Эдикны яшьләр группасы чорнап ала. Аларның тимердән киенгән күкрәкләрендә Сталин портреты. Эдикны төркемнән төркемгә бәргәләп йөртәләр. Кемдер кычкыра, кемдер елый, кемнедер үтерәләр.

Эдик аяк астына егылып кала. Толпа, көтү кебек, аның өстеннән чыгып китә.

Кыяметдиннең сузып-сузып ясин чыкканы ишетелә.

Пәрдә

АЛЛАЛАР ЯЛГЫШЫ

Өч бүлектә

(Трагикомедия)

КАТНАШАЛАР:

Ир — соңыннан Ир-ат алласы.
Хатын — соңыннан Хатын-кыз алласы.
Ана.
Ананың улы.
Егет.
Кыз.
Яшь кыз.
Яшь егет.
Ирләр.
Хатыннар.
Яшь егетләр.
Яшь кызлар.
Алла.

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

Мәгарәгә охшатып бизәлгән бүлмә. Идәндә һәм стенада җәнлек тиреләре. Мәгарә-бүлмәдә ярымкараңгылык, аны шәм уты гына яктырта. Ярымкыргый рәвештә киенгән хатын. Чәчләре тузгып җилкәсенә төшкән. Ирнең дә киемнәре, үз-үзен тотышы мәҗүсиләрне хәтерләтә. Ул җәнлек тиресе җәелгән диванда ята. Кулында газета. Хатын кер үтүкли. Кыяфәте ачулы. Пәрдә ачылганда без аларны әнә шулай күрәбез. Ярымкыргый (яки артык заманча) музыка ишетелә.

Хатын *(үтүкләвеннән туктап)*. Җитте! Туйдым. Мин болай артык яши алмыйм! Мин бу хәлгә артык түзә алмыйм!

Ир. Нинди хәлгә? Нәрсә булган әле монда түзә алмаслык?

Хатын. Юк, син, хәтта, аңлый да алмыйсың. Һәм аңларга да теләмисең! *(Ярсып йөренә.)* Соң, син кара. Кем мин монда?

Ир. Ничек, кем? Хатын. Минем хатын.

Хатын. Хатын! Хатын гына шул! Югыйсә, мин бит синең белән ун ел бер парта артында утырдым, биш ел институтта бергә укыдык. Син биргән имтиханнарны мин дә бирдем, син алган белемне мин дә алдым. Һәм ни өчен мин һаман хатын гына булып калырга тиеш?

Ир. Синең... кем буласың килгән иде соң? Әллә хатын-кыз булып туганыңа да мине гаепләмәкче буласыңмы? Әллә син безгә, ир-атларга, бик җиңел дип беләсеңме?

Хатын *(аның каршысына килеп)*. Их, эшем кешеләре, эшем кешеләре! Аларга авыр, имеш. Нәрсә, акыллы, эшлекле булып кыланырга авырмы? Ә сез кыланмагыз. *(Иренең кулыннан газетасын тартып ала.)* Булдыксызлыгыңны газета артына яшереп, акыл сатып утырган булма, ичмасам. Мә, бераз кер үтүклә. Мин ашарга бирәр нәрсә әзерләп алыйм.

Ир килеп үтүкне ала, тотып карый.

Ир. Эшләми бит бу. Вәт, дивана, инде ярты сәгать салкын үтүк белән маташа икән. Соң, телеңә салынганчы, үтүгеңне тотып карыргае башта.

Хатын. Ә син өйрәтмә, өйрәтмә миңа нәрсә эшләргә кирәген! Нәрсә өчен эшләми соң ул үтүк? Өйдә ир-ат булмаганга эшләми. Төзәт, әйдә, тизрәк. Иртәгә эшкә үтүкләнмәгән күлмәк киеп бармам бит инде.

Ир үтүкне әйләндереп-әйләндереп карый.

Ир. Балта юк.

Хатын. Нәрсәгә сиңа балта?

Ир. Соң, үтүк төзәтергә кушасың бит!

Хатын. Я, хода! Үтүк төзәтергә балта кирәкмени?! И-и-и! Мин дә яшим бит ир белән!

Үтүкне иреннән тартып ала. Пычак белән каерып ача башлый.

Ир. Интекмә. Иртәгә эшкә барышлый мастерскойга кертеп бирерсең. Момент төзәтеп бирерләр аны анда.

Хатын. Анда ир-атлар эшлидер шул. Ой-ой-ой! Бетердем, харап иттем бармагымны! *(Кулын тотып, чабулап йөри башлый.)* Нәрсә карап каттың, әнә, каный бит инде! Алып кил тизрәк мамык.

Ир *(эзләштергәләп)*. Мамык юк.

Хатын. Соң, бинт бир алайса. Әнә, тама бит инде каны.

Ир *(актарынып)*. Бинтың да юк. Гомумән, нәрсәң бар соң синең? Нәрсәгә тотынсаң, шул юк. Хатын, имеш. Әй, остарган була әле үзе. Кешене өйрәткән була.

Хатын. Мин яралы, мин җәрәхәтле! Ә син ярдәмгә ташланасы урында, акыл сатып торасың! Ах, кем белән яшим мин? Ах, үләм, үләм! *(Диванга барып ава.)*

Ир *(мыр-мыр килеп)*. Тотынмыйлар аны пычакка, рәтен белмәгәч. *(Үтүклисе керләр арасыннан зур бер яулык алып килә.)*

Икәүләшеп эзли башлыйлар.

Ир. Юк ич монда киселгән җире?

Хатын. Менә ич, менә. Күзеңә керәм дип тора.

Ир. Җәрәхәтмени бу? Моның кай төшен бәйлисең?

Хатын. Үзеңнеке шулай киселсә, өч көнгә больничный алыр идең әле. Әйдә, бәйләвеңне бел!

Ир хатынының бармагын зур итеп, яулык белән бәйләп куя. Хатын, аһылдый-аһылдый диванга менеп утыра.

Хатын *(бармагын әйләндергәләп)*. Мин бүген ашарга да пешерә алмам инде. Үзең берәр нәрсә әзерләп аша шунда. *(Кулына газета алып ята.)*

Ир. Син юри кистең ул бармагыңны, ашарга пешермәс өчен. Ну, хәйлә үзендә, ну, мәкер. *(Эчен тотып.)* Ашыйсы да бик килә. Әй, была не была, пешереп карарга кирәк.

Кухня якка уза. Бераздан башын тыгып сорый:

Май кайда?

Хатын. Май юктыр әле ул. Иртәгә аласы булыр. Майсыз гына пешер инде.

Ир кереп китә. Бераздан бүлмәгә чыгып нидер эзләнә.

Хатын. Нәрсә эзлисең тагы?

Ир. Тоз кирәк.

Хатын. Соң, тоз залда була димени? Ахмак! Кайда нәрсә ятканын да белмисең бит син. Бар, кухнядан кара.

Ир. Аннан эзләдем инде. Юк.

Хатын. Беткәндер алайса. Иртәгә аласы булыр. Тозсыз гына пешер инде.

Ир кухняга кереп китә. Бераздан савыт-саба, кашыклар күтәреп чыга.

Ир. Менә, әзер.

Хатын. Что-то, бик тиз өлгерттең әле син. Кая, карыйк әле... *(Кашык белән болгата.)* Нәрсә соң бу?

Ир. Су.

Хатын. Нинди су?

Ир. Краннан агыздым да алдым. Чөнки безнең өйдә судан башка берни юк.

Хатын *(сикереп торып)*. Опять мин гаепleme?

Ир. Ә кем гаепле булсын тагы? Мин бит күрәм кеше хатыннарын, эштән чак өстерәлеп кайталар, ике кулларында ике сумка, кибет саен керә кайталар. Ә син эшкә дә уч төбе хәтле сумочка белән йөрисең. Күзге белән пудра гына сыярлык.

Хатын. Ә син нәрсә күтәреп кайтасың? Ә син кая керә-керә кайтасың? Пивнойдан — пивнойгамы?

Ир. Мин — ир-ат.

Хатын. Ә мин, хатын-кыз, синең колың булырга тиеш инде, әйеме? Син кайтышка барысын да алып кайтып, әзерләп тә куярга тиеш. Ә мин бит синең белән бер оешмада эшлим, җаваплылык та бер үк. Ә нигә мин эштән кайткач, тагы бер смена куарга тиеш?

Ир. Нинди смена? Нинди эш булсын сиңа монда? Нәрсә, мичкә ягасың бармы, чишмәдән су ташыйсыңмы? Эшли, имеш... *(Диванга барып утыра.)*

Хатын. Ә, шулаймы? Алайса, мин сиңа вообще ашарга әзерләмим. Хезмәтчеләр заманы үтте. Тү-тү! Бар, әнә, үзең пешергән суны аша! Ха-ха-ха!

Ир. Ул чагында... миңа синең кирәгең дә шул кадәр генә! Ашарга пешереп, табак-савытын да юмагач, син миңа нинди хатын соң?

Хатын. Ә минем синнән кай җирем ким? Ни өчен эштән кайткач син ял итәргә тиеш тә, мин ярты төнгә хәтле чабулап йөрергә тиеш? Ни өчен?!

Ир. Чөнки син хатын-кыз. Йорт-җир карау синең төп бурычың.

Хатын. Ә мин теләмим, теләмим андый бурычны үтәргә! Ә, между прочим, кем тарафыннан бирелгән бурыч ул? Минем беркайчан да андый йөкләмәне үз өстемә алганым булмады.

Ир. Алла тарафыннан бирелгән бурыч ул, беләсең килсә! Табигать тарафыннан.

Хатын. Ха-ха-ха! Алла, имеш. Ә беләсең килсә, мин үземә үзем алла. Минем дипломым, җәмгыятьтә тоткан урыным бар, шул җәмгыять алдында үтисе бурычларым да җитәрлек. Хокукларым да бар!!

Ир. Да, артык күп шул сезнең хокукларыгыз хәзер. Бурычларыгыз да җитәрлек. Тегесе алдында да, монысы алдында да. Тик гаилә, ир, балалар алдында гына бурычларыгыз юк. Анысын җәмгыятькә йөклисез сез.

Хатын. Син балага кагылма. Бала тәрбияләүдә синең бер катнашың булмады.

Ир. Булмады шул. Тууга атналык яслегә илтеп тыктың, аннары, юк авыруларын бар итеп, санаторияләрдән кайтарып кертмәдең. Ахырда, анаң пенсиягә чыгуга, аңа илтеп ташладың. Хәзер әбисенә «мама» ди бит ул. Безнең барлыкны да белми. Үз балаңны карарга да иренәсең бит син!

Хатын. Ә сиңа бала түгел идемени ул? Нигә дип мин ул авырганда больничныйларда утырырга тиеш идем? Начальстводан сүз ишетергә тиеш? Ә нигә син бер тапкыр да авыру бала белән больничныйда утырмадың? Ир, имеш, ата, имеш. Ир түгел, чүпрәк син, пешмәгән нәрсә...

Ир. Җитте! Мин болай артык яши алмыйм! Ирме мин, в конце концов, юкмы? *(Җыена.)* Китәм мин синнән, шуны белеп тор.

Хатын. О! Дүрт ягың кыйбла, егет! Мин синнән башка да үз көнемне үзем күрә алачакмын. Ә менә карарбыз — син нишләрсең икән?

Ир. Яшәрбез. Хатын-кыздан башка да яшәрбез. Гарык. Булды! Туйдым! Арыдым! Ял итәсем килә. Ял...

Хатын. Ах, мин сине ничек күралмыйм! Синең белән узган гомерем әрәм.

Ир. Бар, яхшырагын эзләп кара. Бәлки, минем кебек бер дурагы килеп кабар җәтмәңә. Бар, хәзер сиңа шул гына кала. Ха-ха-ха!

Хатын *(тезләнеп)*. О, Алла! Нигә күрә торып шушы ир-ат затыннан мыскыллатасың? Нигә син мине хатын-кыз итеп яраттың? О, Алла! Мин болай артык яши алмыйм! Бир миңа көч-куәт шушы ир-ат халкын җиңә алырлык?! Бир миңа акыл-зиһен шушы ир-ат затыннан өстен булырлык?! Алла, ишетәсеңме? Минем мәңгелек кол буласым килми?!

Ир. Итәрсең сине кол. Ышанма аңа, Аллаһе Тәгалә! Алар үзләре безне колларга әйләндереп бетерделәр инде. Мал колына, чүпрәк колына, акча колына, власть колына. Барысы да алар диктовкасы белән эшләнә! Йә, Алла, нигә кысылдырасың син хатын-кызны ир-ат эшенә? Нигә күрә

торып шулай азындырасың син аларны? Шуның өчен яраттыңмыни син аларны Җир йөзенә?!

Еракта Алла пәйда була.

Алла. Мин сезне җир йөзенә яшәр өчен яраткан идем.

Хатын. Булмый аның белән яшәп, булмый. Куда черт яшәү!

Ир *(төртеп)*. Тукта, син башта кеше әйткәнне то есть, Алла әйткәнне тыңла! *(Аллага)*. Соң, Аллаһе Тәгалә, үзең шаһит бит, булмый ул хатын-кыз заты белән яшәп. Йә, нишләргә инде миңа?

Алла. Ир булырга.

Хатын. Ә миңа, миңа нишләргә?

Алла. Хатын булырга.

Ир. Ә, менә, ишеттеңме инде? Әнә, Аллаһе Тәгалә дә хатын булырга диде. Хатын! Домашний прокурор түгел!

Хатын. Ә сиңа ир булырга диде! Ә син кем? Чүпрәк син, ир түгел.

Ир. Ул мине мыскыл итә! Ул мине Алла каршында мыскыл итә! Аллам, ничек чыдап торасың бу хәлгә? Ничек аны яшен сукмый?

Хатын. Суктырырмын менә мин сиңа. *(Бәргәли.)* Менә сиңа яшен, менә сиңа. Хәзер ялтыравын да күрерсең.

Алла. Их сез, кешеләр! Карап-карап торам да, мин сезне таный алмыйм. Нәрсә булды сезнең токымга? Мин яраткан кешеләр түгел инде сез.

Ир. Ә юк, Аллаһе Тәгалә, син алай тиз генә җаваплылыкны үз өстеңнән төшермә әле. Әйт дөресен, ничек яшәргә безгә хәзер Җир йөзендә?

Алла. Ирләргә — ир урынында, хатыннарга — хатын урынында булырга кирәк. Дөнья яратылганда шулай иде.

Хатын. Аһ, Аллам, син аңлатып әйт, кайда ул урын? Менә минем, хатын-кызның урыны кайда?

Алла. Мин дөньяны яраткан заманда хатын-кыз йорт хуҗасы, учак хуҗасы иде. Ул дөньядагы барлык матурлык, җылылык, наз хуҗасы иде.

Ир. Ә ир-ат? Ир-ат нәрсә хуҗасы иде.?

Алла. Ир-ат дөнья хуҗасы иде. Ир-ат хатын-кызның туйдыручысы, яклаучысы иде.

Хатын. Ишеттеңме? Туйдыручысы, яклаучысы, ди. Синдә бу сыйфатларның берсе дә юк. Синең зарплатаң минекеннән дә аз, синең ул йөз тәңкәңне көтеп утырсаң, ачка үләрсең! Шуның өстенә әле син куркак та! Төнлә ишек шакысалар да мине төртеп уятасың. Димәк, син чын ир түгел.

Ир. Син минем ирлегемә кагылма! Әнә, синең урыныңны да учак янында диде ул. Ә безнеңчә — кухня була инде ул.

Хатын. Ялганлама. Ул кухня дип әйтмәде. *(Тагы бер-берсен бәргәләшә башлыйлар.)* Ул учак диде. *(Тәэсирләнеп.)* Учак! Төнге сихри учак! Ә синең мине урманга алып чыгып, учак янында утыртканың да юк. *(Бәргәләшәләр.)*

Алла. Нишләргә инде миңа сезнең белән? Кайсы чорда шулай ялгыштым икән соң мин?

Хатын. Аллам! Бир миңа шушы ир-ат затын җиңә алырлык көч!

Ир. О, Алла! Алай эшли күрмә! Син иң элек мине дөньяга яраткан. Һәм башта минем язмыш турында уйларга тиеш.

Икәүләп. Ярдәм ит безгә, Алла? *(Тезләнеп, Аллага ялваралар.)*

Алла. Әй, кадалып китегез сәнә! Телисез икән, әнә, үзегез Алла булыгыз! Тик минем каршыма башка киләсе булмагыз! Ни теләсәгез, шуны кыла751ыгыз! Мин сездән ваз кичәм. Ваз кичәм мин сездән, кешеләр! *(Югала.)*

Сәхнә караңгылана, дөбердәп, күк күкри, яшен яшьни. Аңа барабаннар тавышы кушыла. Ир белән хатын әсәрләнеп урыннарыннан сикереп торалар. Алар хәзер Ир-алла һәм Хатын-алла. Хәрәкәтләрендә ярсу, ашкыну. Джаз музыка. Алар котырып, тантана белән сәхнәне бер әйләнәләр дә, икесе ике якка чыгып йөгерәләр. Сәхнә әйләнә. Хатын-алла, атылып, халык төркеме каршына чыгып баса. Ул бераз өстәрәк, аста — хатын-кызлар

торкеме. Хатын-кызлар ниндидер сәер бию башкаралар. Бу биюдә аларның бала багу хәрәкәтләре дә, аш-су әзерләүләре, кер юу алымнары да чагыла.

Хатын. Ярты дөньяны үз җилкәсендә тотучы, ашатучы, киендерүче, чистартучы — ул кем?

Төркем *(астан, гүләп)*. Без — хатын-кызлар.

Хатын. Бар дөньяны тудыручы-яңартучы, күкрәк сөте белән туендыручы, һәр тапкан баласы хакына ярты сәламәтлеген, яшьлеген, тынычлыгын корбан итүче — ул кем?

Төркем. Без — хатын-кызлар.

Хатын. Мин-минлекле иреннән мыскыл ителүче, гомер иткән ирләре төннәрен башка урыннарда кәеф-сафа кылганда, ялгызлыктан, хыянәттән күңеле катып егълаган — ул кем?

Төркем. Без — хатын-кызлар.

Хатын. Тели икән — дөньяны гөл итә алучы, иң таш бәгырьле адәмнәрне дә хистән шашыр дәрәҗәгә китерүче, бу җирнең алласы да, патшасы да була алырлык — ул кем?

Төркем. Без — хатын-кызлар!

Хатын. Шулай булгач, ирләрдән башка яши алмыйбызмыни без?

Төркем. Яши алабыз!

Хатын. Без үзебезнең аллалыкны — хатын-кызлар аллалыгын төзергә тиеш. Ирләрдән башка тормыш! Матриархат! Алла да үзебез, патша да!

Төркем *(гүләп)*. Дөрес! Үзебез алла, үзебез патша!

— Кирәкми безгә ир-атлар!

— Көлмәсеннәр бездән гомер буе!

— Үз аллалыгыбызны булдырабыз!

Хатынга мөрәҗәгать итеп:

— Ә син безнең аллабыз булырсың?

— Аллабыз булырсың, аллабыз!

Кыргый бию башлана. Хатын-алла да алар арасында. Бу юлы инде биюдә йорт эше хәрәкәтләре юк, анда иркенлек, дәрт, тәвәккәллек алымнары чагыла. Биюнең иң кызган чагында Ана алга чыга.

Ана. Туктагыз!

Төркем туктап кала.

Хатын-алла *(тәхетенә менеп утырып)*. Син кем?
Ана *(астан)*. Мин — ана.
Хатын-алла. Без барыбыз да аналар. Йә, ни сүзең бар, ана?
Ана. Мин андый җәмгыятькә риза түгел.

Барысы да тынып кала.

Ана. Мин андый җәмгыятьтә яшәргә теләмим.
Хатын-алла. Ни өчен син андый җәмгыятьтә яшәргә теләмисең, хатын?

Ана дәшми.

Нәрсә, син ireңә кол булмадыңмыни?
Ана. Ялганлый алмыйм, колы урынына булдым.
Хатын-алла. Әллә бик ярата идеме үзеңне?

Ана дәшми.

Хатын-алла. Авырганда аяк очында утырып, син йокыга киткәч, башкалар янына чаба идеме?
Төркем. Ха-ха-ха!
Ана *(башын иеп)*. Ялганлый алмыйм, ирем башкалар белән уртак булды.
Хатын-алла *(кискен)*. Соң, шулай булгач, нәрсә тота сине аның янында?!
Ана *(кулларын алга сузып)*. Бала! Балам кала бит аның янында!
Хатын-алла. Ал балаңны да үзең белән. Безнең җәмгыятьтә хөррият, иркенлек, тигезлек. Башыбыз аек, күңелебез саф, кулларыбыз нык, гөрләтеп яшәрбез.
Төркем. Гөрләтеп яшәрбез, гөрләтеп!
Ана *(башын иеп)*. Юк.
Хатын-алла *(кискен сикереп тора. Ярсып)*. Мин — алла! Ләкин минем сабырлыкның да чиге бар. Мине бер

томана хатынның кирелеге туйдыра башлады. *(Кискен борыла.)* Алып китегез аны! Ябыгыз алтын сарайларның берсенә. Гомер буе рәхәттән, эшсезлектән иза чиксен! Берьялгызы! *(Китә башлый.)*

Төркем Ананы урап ала.

Ана *(Хатын-алланың аягына егыла)*. Аллам! Ялварып сорыйм синнән, аерма мине баламнан! Мин бит аннан башка сагыштан тилмереп үләчәкмен.

Хатын-алла *(аңа борылып)*. Ә нигә син балаңны үзең белән алырга теләмисең?

Ана *(ачыргаланып)*. Ул бит ир бала!

Хатын-алла. Ир бала?!

Ана. Әйе, шундый матур, шундый ягымлы ир бала. Аның куллары шундый йомшак, шундый нәни. Ул шул куллары белән минем муенымнан коча, иркәли, үбә... Үзе шундый җылы, чиста, битләреннән, иреннәреннән сөт исе, үлән-чәчкә исләре килеп тора...

Төркем «аһ» дип сулкылдап куя. Ана сөйләгәндә, күбесенең күзләрендә моңсулык, алар, әкрен генә, бишек тибрәткән кебек чайкалалар. Төркем шулай чайкала-чайкала Ана янына күчеп бетеп бара.

Ана. Ә кечкенә аяклары белән каршыңа шулкадәр матур итеп тупырдатып йөгереп килә, чапмый, атыла, оча синең кочагыңа, шулкадәр наз, ышаныч белән килеп сыена синең күкрәгеңә... Шул чагында дөньядагы бөтен авырлыкларны да, кимсетүләрне дә онытасың. Сабыеңның саф, чиста күзләрен яхшырак күрү өчен аның каршына тезләнәсең... Аллам! Аерма мине шул бәхетемнән! Мин аннан башка бер генә минут та яши алмыйм дөньяда.

Төркем. Аерма аны баласыннан, Алла, аерма!

Хатын-алла. Бүген — бала, ә иртәгә ул кем булыр?

Төркем. Асыл егет булыр.

Хатын-алла. Аннан соң кем булыр?

Төркем. Батыр ир булыр.

Хатын-алла. Әйе шул, ир булыр! Ир! Ә безнең җәмгыятьтә ир-атка урын юк! Юк! Һәм булмаячак та.

Төркем дәшми. Башлар иелгән.

Хатын-алла. Сез, шул ир-аттан күпме җәбер, кимсетелү, мыскыллау күргән хатын-кыз заты! Күтәрегез башларыгызны! Без саф, чиста, ялгансыз, кимсетелүсез, тигез хокуклы үз җәмгыятебезне төзедек. Сез акыллы, тәвәккәл, тырыш хатын-кызлар. Күрсәтегез үзегезнең көчне, чыгыгыз кысан кухняларыгыздан, салып ташлагыз мәңгелек халатларыгызны! Сез дөньяны матурлау, яңарту өчен яратылган затлар. Сез коллар түгел!

Төркем *(гүләп)*. Түгел, без коллар түгел.

Хатын-алла. Бүген — малай, иртәгә — ир булачак! Ә безнең җәмгыятьтә ир-атка урын юк.

Төркем. Ю-у-к!!!

Хатын-алла *(Анага мөрәҗәгать итеп)*. Син дә, ана, юкка борчылма! Ир булганның икенче көнендә үк улың сине онытачак. Онытачак! Әнә, күпме аналар черегән нигезләрендә ялгызлыктан бил бөгәләр. Ә аларның да кайдадыр уллары бар бит. Бар... Тик сабый чагындагы кебек әнисе каршына түгел, аракы шешәсе каршына тезләнә ул. Куллары белән дә әнисенең бөкрәйгән аркасын түгел, сөяркәсен яки аракы шешәсен иркәли. Сиңа да шул көн килер бит.

Ана *(сулкылдап)*. Юк! Ул андый бала түгел.

Хатын-алла. Андый булмаса — шундыйга әйләнер. Кара, кемнәр арасында синең улың? Кемнән үрнәк алсын ул? Мәңге исерек атасыннанмы? Мәктәп эскәмиясеннән үк аракы кибетенә чапкан дус-ишләреннәнме?!

Ана. Дөньяда бит әле мин дә бар! Ана! Мин тәрбияләргә тиеш үз баламны кеше итеп. Мин!

Хатын-алла. Ә синең үзеңнең бу дөньяда дәрәҗәң юк. Ирең алдында да, кешеләр алдында да. Чөнки син — хатын-кыз! Бары тик хатын-кыз гына... Нигә тыңласын ул ир-бала бер мескен хатын-кыз сүзен. Син аңа бары тик

комачау гына итәчәксең. Ул сине куралмас дәрәҗәгә килеп җитәр! Син аның тормышында артык бер шәүлә генә булып калачаксың. Һәм сез, бер-берегез өстеннән жалобалар язып, ызгыша-талаша йорт-мал бүләчәксез! Акылыңа кил, ана, әле соң түгел.

Ул сөйләгәндә Ана әкрен-әкрен башын аска ия.

Хатын-алла. Әй, сез, тырыш, тәвәккәл, батыр хатын-кызлар заты! Үз патшалыгыбызга, үз дөньябызга юл алыйк. Мин — сезнең аллагыз. Һәм мәңге сезнең белән булырмын.

Төркем. Син безнең аллабыз!

— Мәңгегә, мәңге, мәңге!

Хатын-алла. Кирәкми безгә ир-ат, кирәкми безгә мәхәббәт, кирәкми безгә аларның ялган назлары. Аек акыл, аек тормыш кирәк.

Төркем. Мәңге, мәңге, мәңге!

Төркем чыгарга кузгала. Ана да акрын гына алар артыннан атлый. Бер яшь кыз гына читтәрәк басып кала.

Хатын-алла. Ә син, чибәркәй, ни көтәсең? Синең дә ялантәпиле балаң калмыйдыр бит?

Кыз. Юк...

Хатын-алла. Алайса, нигә башкалар юлыннан атламыйсың син?

Кыз. Мин... Көтәм...

Хатын-алла. Кемне... көтәсең, кыз бала?

Кыз. Сөйгән ярымны.

Хатын-алла. Егетеңне, димәк...

Кыз *(аның аякларын кочып)*. Аллам, Аллакаем, ул башкалар кебек түгел, ул бик әйбәт, бик, бик игътибарлы ул, ул... Ул мине сөя!

Хатын-алла *(аның башына кулын салып)*. Әй җүләр кызый, җүләр кызый. Алар башта барысы да шулай әйтәләр. Ә өйләнешеп бер ай да үтми, синең урының инде аяк астында. Харап итмә яшь башыңны, җүләркәй. *(Төр-*

кем киткән якка күрсәтә.) Тор. Әнә, ул юлдан синең аналарың, апаларың китте. Гомерләренең ахырларында булса да аңладылар үз хәлләрен. Алар ялгышын син кабатлама.

Кыз. Алайса, бер генә тапкыр, соңгы тапкыр гына булса да күреп калыйм үзен.

Хатын-алла *(сынап)*. Соңгы тапкыр дисәң генә. Ләкин кара аны, ялгышсаң, безнең җәмгыятьтә сиңа урын юк! *(Китә.)*

Кыз ялгызы. Әкрен генә моңсу, лирик көй агыла. Кинәт бөтен сәхнәне тутырып, ат тояклары, барабаннар каккан тавыш, гөжләү ишетелә. Ул да булмый, сәхнәгә өермәдәй атылып ирләр төркеме килеп керә. Төркем башында безгә таныш Ир-алла.

Музыка, бию, ярсу омтылыш.

Ир-алла. Ирләр! Җирдәшләрем! Сез беләсезме, безнең борынгы бабаларыбыз кем булган?

Төркем. Курку белмәс гайрәт ияләре булган!

— Ерткыч җанварларга каршы коралсыз да ауга чыга алган батыр ирләр булган!

— Бар дөньяның туендыручысы, яклаучысы булган!

Ир-алла. Ә бүген сез, аларның ерак оныклары, сез кемнәр?

Төркем. Шикләнеп, икеләнеп, хатыннарыбыз шәүләсе артына качучылар...

— Сумка күтәрәп, кибет белән базар юлында чабучылар.

— Эштән биш минутка соңга калып кайткан өчен дә хатыннарыбыздан биш сәгать буе тезләнеп гафу сораучылар.

— Ашарга пешерүчеләр, бала караучылар, кер юучылар, өй җыештыручылар...

Ир-алла. Сезнең бу хәлләргә бер дә эчегез пошмыймы? Борынгы бабаларыгыз каны сезне төнге ауларга, ярсу бәрелешләргә дәшмиме?

Төркем. О! Бездә кайчак кыргыйлар, мәҗүсиләр каны уйный башлый.

— Безнең яңа утраулар ачасыбыз, ерак диңгез-океаннар буйлап сәяхәт кыласыбыз килә!

— Безнең, философ булып, акыл иясе булып, киләчәккә мәңгелек язмаларыбызны калдырасыбыз килә!

— Безнең чын ирләр буласыбыз килә!

Ир-алла. Нәрсә комачаулый соң безгә бу бөек эшләрдә, ир-егетләр?

Төркем. Хатын-кыз...

— Хатын-кыз безнең хыялыбызга да, гамәлебезгә дә чик куя.

— Безнең һәр минутыбыз аның үлчәве белән үлчәнә, һәр кылган эшебез аның тарафыннан бәяләнә.

— Өйдән — эшкә, эштән — кибеткә, кибеттән — кухняга.

— О, без ничек туйдык бу бертөрлелектән!

— Безнең чын ирләр буласыбыз килә!

Ир-алла. Янәшәгездә хатын-кыз барында, сез беркайчан да чын ирләр була алмаячаксыз. Мин ир дип йөргәннәрегез дә күптән инде хатын-кыз тарафыннан өйрәнелгән, яулап алынган, буйсындырылган, кол ителгән җаннар.

Төркем. Нишләргә соң безгә, бир бер киңәшеңне, о, безнең кебек үк ир-ат?!

Ир-алла *(кискен хәрәкәт белән)*. Берләшергә. Хатын-кыздан ваз кичәргә. Үзебезнең аллалыгыбызны булдырырга. Хатын-кыздан башка тормыш! Хәйләсез, мәкерсез, алдаусыз тормыш! Чын ирләр тормышы!

Төркем. Берләшергә!

— Ваз кичәргә!

— Үз аллалыгыбызны булдырырга!

Ир-алла. Сез, дөньяның хуҗасы булырдай батыр ирләр, ризамы шундый тормышка?

Ирләр. Риза! Безне хатын-кыз диктовкасы туйдырды!

— Син безгә юл күрсәт!

— Юлбашчыбыз бул, юлбашчыбыз!

Ир-алла. Сез, аталар, хатыннарыгыздан узып, балаларыгызга бер җитди сүз әйтә алмаган аталар! Сезнең

чын ир булып, үз улларыгызга үзегез тәрбия бирәсегез киләме?

Ирләр *(аталар)*. Килә! Без улларыбызның чын ирләр булып үсүен телибез. Кирәк икән, янып торган утка да, бозлы суга да сикерә алырлык, ерткыч җанварны да коралсыз җиңә алырлык батыр ирләр булып үсүен телибез! Ә бүген безнең улларыбыз — әниләре кочагында, назда, рәхәттә җебиләр. Шулай дәвам итсә, алардан беркайчан да чын ирләр чыкмаячак. Без улларыбызны да үзебез белән алабыз.

— Син безгә юл күрсәтерсең!

— Юлбашчыбыз булырсың, юлбашчыбыз!

Ир-алла. Ә сез, сөйгән ярлар, хатын-кызның бер серле карашыннан башларын җуйган сөйгән ярлар! Сез ризамы ир-ат туганнарыгыз белән китәргә, хатын-кызсыз, мәхәббәтсез, хиссез чын ирләр тормышы белән яшәргә?!

Сөйгән ярлар дәшми. Пауза.

Ир-алла. О, сөйгән ярлар, сез минем аллалык чылбырының иң тотрыксыз, иң ышанычсыз боҗрасы. Сезне хатын-кыз кайчан теләсә шунда үзенә кол итә алачак. Ирләр шул сөюләре белән харап булалар да инде. Башта ул гашыйк булып хатын-кыз алдына тезләнсә, соңыннан хатын-кыз аны көн саен тезләндерергә сәбәп табачак. Уйлагыз, сөйгән ярлар, әнә, ир-туганнарыгызга карагыз. Алар да кайчандыр сезнең кебек үк гыйшык утында янган яшь егетләр иде. Ә соңыннан хатын-кызның колына әйләнделәр.

Ирләр *(шаулап)*:

— Колларга әйләндерделәр, колларга!

— Моннан соң бу хәл кабатланмаячак!

— Без үз аллалыгыбызны төзибез, хатын-кыздан башка тормыш!

— Мәкер-хәйләсез, чын ирләр тормышы!

— Син безнең аллабыз булырсың, аллабыз!

— Аллабыз булырсың, аллабыз!

Ир-алланы кулларына күтәрәләр.

Ир-алла. Җирдәшләрем! Табигать-алла безне ирләр итеп яраткан. Һәм без ирләр булып калыйк та. Безне зур дөнья, зур хыяллар, зур эшләр көтә! Без, хатын-кыз теләгәнчә, чүпрәк колы, акча колы, мал колы булмаячакбыз!

Төркем. Булмаячакбыз!

— Без батыр, ирекле, акыллы ирләр токымы!

— Без дөньяны гөл итәчәкбез!

Ир-алла. Алга, ирләр! Алга — үз аллалыгыбызга!

Ярсып, гүләп, барабан, ат тояклары тавышы чыгарып, чыгып китәләр. Төркем артыннан яшь бер егет, башын иеп, теләр-теләмәс кенә атлый. Аның каршына кыз йөгереп чыга.

Кыз *(аңа атыла)*. Син!

Егет *(туктап)*. Син! *(Килеп, кулларыннан ала.)*

Сүзсез басып торалар.

Кыз. Син... кая болай ашыга идең?

Егет. Башкалар белән, ирләр белән...

Кыз. Кая?..

Егет. Әрнетмә йөрәгемне, җаным... Болай да беләсең бит. Халык кайда — мин шунда.

Кыз. Димәк, китәсең...

Егет. Нишлим соң? Анда минем атам, ир туганнарым. Анда халык.

Кыз *(күз яшьләре аша)*. Ә безнең мәхәббәт? Ә безнең икебез генә белгән уртак серләребез, вәгъдәләребез?! Аһ, бәгърем, яши алмам мин синнән башка! *(Аңа сыена.)* Синсез язлар тамчыларсыз, гөрләвекләрсез булыр бит...

Егет. Ә синсез җәйләр кояшсыз, нурсыз, салкын узар. Чәчәкләр дә үсмәс инде...

Кыз. Көзләрен сары сагышымдай сары яфракларны кем белән җыярмын? Парлы аккошларны ерак илләргә мин ялгызым гына озатып калырмын инде...

Е г е т. Син булмагач, ул ак карларның, саф карларның матурлыгына кем сокланыр? Ул карларда ялгыз эзләр калыр...

К ы з. Ә яңадан язлар килмәсә?! Син булмагач, язлар да кабат килмәс инде, килмәс. *(Елый.)*

Е г е т. Елама, бәгърем! Әйдә, качыйкмы моннан берәр җиргә?!

К ы з *(елавыннан туктап, гаҗәпләнеп)*. Ә кая? Бармы җирдә без качарлык урын? Бармы?! Алар бит безне барыбер табачаклар, мәхәббәтебездән көләчәкләр, сез бер-берегез өчен түгел, дип, барыбер инандырачаклар! *(Битләрен каплый. Егет тә, башын тотып, җиргә утыра.)*

Е г е т *(башын күтәреп)*. Җир! Нинди зур син, җир! Ә шулай да ике гашыйкны яшерерлек, сакларлык, сыендырырлык урының юк синең. Кая качыйк без бу кешеләрдән, гадәтләрдән, гайбәтләрдән. Кая?!

Кинәт быргы, барабан тавышлары ишетелә. Егет сикереп тора.

Е г е т. Мине эзлиләр. Мине чакыралар. Хуш, җаным! *(Кочаклашалар.)*

Шул вакыт кыңгыраулар чылтыраган авазлар, серле-сихри музыка ишетелә.

К ы з *(башын күтәреп)*. Аллалар безне эзлиләр. Алар безгә ярсулы. Хуш, бәгърем, башка юл юк, күрәсең...

Быргы, барабан тавышы кыңгырау авазлары белән аралаша, ярыша, көрәшә. Егет белән кыз икесе ике якка атылалар, яңадан йөгереп килеп кочаклашалар. Кинәт бар да тынып кала. Егет белән кыз әкрен генә бер-берләреннән аерылышалар да, башларын иеп, икесе ике якка чыгып китәләр.

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

Бай һәм затлы сарай. Һәр нәрсәдә зәвык, зиннәт, заманчалык чагыла. Пөхтәлек, чисталык һәм югары культура сизелә. Бу — Хатын-кыз алла сарае. Хатын-алла үзе, келәмнәр җәелгән, үрмәле гөлләргә уралган тахта-

тәхеткә кырын ятып, каршындагы зур экранны күзәтә. Киемнәре үтә күренмәле, бик затлы. Ул пульттагы кнопкага баскан саен, кадрлар үзгәреп тора. Тыныч, талгын музыка ишетелә. Экранда — кыска ак спорт киемнәре кигән яшь кызлар. Алар тыныч, сабырлар. Төгәл приборлар белән йолдызларны күзәтәләр, укыйлар, язалар...

Әкрен генә залга Яшь кыз керә. Ул да сабыр, салкын кыяфәтле. Бераз роботка охшаган.

Яшь кыз. Хәерле иртә, аллабыз.

Хатын-алла. Хәерле иртә, кыз бала. Йә, аллалыкта нинди яңалыклар бар?

Яшь кыз. Сезнең янга чит ил хәбәрчесе керергә тели, аллабыз.

Хатын-алла. Хатын-кыз затыннан булса, рәхим итсен. Безнең дөньядан яшерен серләребез юк.

Яшь кыз. Ул нindидер мин белмәгән сәер кеше. Өлкәннәр аның битен каплаганнар.

Хатын-алла *(сикереп торып)*. Димәк, минем аллалыгымда ир-ат?!

Яшь кыз. Белмим. Мин ул сүзнең ни икәнен аңламыйм.

Хатын-алла *(аңа карап ала, үзалдына)*. Әйе, син ул сүзнең ни икәнен аңламыйсың шул. *(Йөренә-йөренә.)* Нишләргә соң? Минем патшалыгыма ир-ат аяк басмаганга инде 15 ел... Әле ир-атның ни икәнен онытмаган хатын-кызлар бар... Бу чит ир-ат алар күңелендәге яшерен хисләрне кузгатмасмы? Әле яңа үсеп килүче яшь кызлар бар. Алар ир-атның нәрсә икәнен бөтенләй белмиләр. Күргәч, кызыксынулары бар. Нишләргә соң? Аны анда, ишек төбендә дә озак тотарга ярамый. Ул бит анда хатын-кызлар арасында. *(Яшь кызга.)* Ярый, бар, керсен, тик битеннән бөркәнчеген салмасын.

Яшь кыз чыга. Хатын-алла ялгызы.

Хатын-алла. Йә, ярар, ир-ат, карап карыйк үзеңә, ничек яшисең икән син хатын-кыздан башка? Ярты миең мин-миңлек чире, яртысы аракы сөреме белән капланган иде, хәзер ул мескен баш ни хәлдә икән? Ә минем пат-

шалыгым менә гөрләп чәчәк ата... Тигезлек, хокук, иркенлек, камиллек — минем аллалыгымда барысы да бар. Халкым тыныч яши, рәхәт яши.

Ишектән башына бөркәнчек ябынган Егет керә.

Егет. Исәнме, алиһә?

Хатын-алла. Исәнме, адәм? *(Тыныч, вәкарьле хәрәкәт белән.)* Йә, уз, утыр, сөйлә. Ни китерде сине минем патшалыгыма?

Егет. Мәхәббәт.

Хатын-алла *(сикереп тора, аннан үз-үзен кулга алып)*. Син минем аллалыгымда тыелган сүзне әйттең. Ләкин мин сине бер юлга гафу итәм. Чөнки сине алдан кисәтмәгәннәрдер: минем аллалыгымда мәхәббәт, наз, сөю-кадерләү кебек сүзләр яңгырарга тиеш түгел. Ишеттеңме, адәм? Минем аллалыгымда мәхәббәткә урын юк! Йә, ни китерде сине бирегә?

Егет. Мәхәббәт.

Хатын-алла *(ярсый төшеп, пышылдап)*. Син икенче тапкыр минем аллалыгымның законнарын бозасың. Аһ син, кире беткән ир-ат, синең каныңда һаман шул азгынлык уйный икән әле. Мин синнән соңгы тапкыр аек акыл белән сорыйм: ни китерде сине минем сараема? Нәрсә эзлисең син биредә?

Егет. Мәхәббәт.

Хатын-алла кулын кулга суга. Утә күренмәле ефәктән иркен киемнәр кигән хатын-кызлар керә. Әкрен генә егетне урап алалар.

Хатын-алла. Алып китегез бу адәмне! Ул безнең аллалыкның иң мөһим законнарын бозды. Һәм ул җәзаның да иң катысын алырга тиеш. Илтеп ташлагыз аны алтын рәшәткәле чәчәкләр бакчасына. Ул анда бер көндә чәчәкләр исеннән буылып үләчәк!

Төркем:

— Аһ, нинди куркыныч җәза!

— Безнең инде ничә еллар беркемне кыерсытканыбыз юк.

— Ни өчен шундый каты җәза, аллабыз?

Хатын-алла. Чөнки ул — ир-ат!

Хатын-кызлар «аһ» итеп як-якка сибеләләр.

Төркем. Ир-ат?!

Хатын-алла. Әйе, ир-ат! Һәм куркыныч ир-ат. Ул биредә беркемгә дә кабатларга ярамаган сүзләрне әйтте.

Төркем. Ни диде ул, аллабыз?

Хатын-алла. Сез минем иң якын, иң ышанычлы киңәшчеләрем. Мин сезгә әйтә алам. Ул мәхәббәт сүзен телгә алды. Ул бирегә мәхәббәтен эзләп килгән.

Төркем *(гаҗәпләнеп)*. Мәхәббәт?! Ул сүз исәнмени әле?

Хатын-алла. Тс-с! Күп сөйлисе булмагыз. Ул сүз безнең өчен инде 15 ел элек юкка чыкты.

Төркем. Аллабыз, зинһар, сөйләсен әле, нинди мәхәббәтен эзләп килгән ул бирегә? Без бит аны соңыннан да үтерә алабыз. Сөйләсен инде.

Хатын-алла. Тик биредә кыз балалар булмасын. Алар ул сүзне, ул хисне бөтенләй белмиләр һәм белмәсеннәр дә.

Төркем.

— Юк, юк, биредә инкубатор балалары юк.

— Алар анда җыелып космик фәннәрне өйрәнәләр.

Хатын-алла. Өйрәнсеннәр. Башларын чүп-чар хисләр белән тутырганчы, гыйлем җыйсыннар, төгәл фәннәрне үзләштерсеннәр. Дөнья барыбер алар кулына каласы. Әнә, ир-ат заты, башы һаман азгынлыкта. Мәхәббәтен эзләп килгән, имеш. Юк ул дөньяда мәхәббәт, юк.

Егет *(бөркәнчек аша)*. Бар ул дөньяда мәхәббәт, бар... Мин аны менә ничә еллар эзлим... *(Туктап кала.)*

Төркем. Аһ, сөйләсен әле, сөйләсен, ул ниндидер кызык нәрсәләр сөйли...

Егет. Мин аны 15 ел эзләдем, 15 ел аның исемен әйтеп саташтым. Шуның аркасында 15 ел ир туганнарымнан, аллабыздан сүз, рәнҗеш ишеттем. Мин алардан кач-

тым, әмма сезнең аллалыгыгызга да юл ябык иде. Ерак илләр гиздем, сагыш-сагынуларымны дәрья суларына салып калдырмакчы булдым. Ләкин ул сагыш, ул моң, ул сагыну һаман менә бирелә, йөрәк түрендә сыкрады, әрнеде. Мин аны күрмичә инде бер минут та тора алмас хәлгә килгәч, ирлегемне аяк астына салып, бөркәнчек ябынып, менә сезнең каршыгызга килеп егылдым. *(Тезләнә.)*

Төркем. Аһ, ул нинди кызганыч.

Хатын-алла. Ул, әлбәттә, матур сөйләде, без инде ничә еллар буе ишетмәгән сүзләрне әйтте. Ләкин шуны да онытмагыз, ул — ир-ат. Ә ир-ат — безнең кан дошманыбыз.

Төркем. Аһ, ул нинди кызганыч!

Хатын-алла. Күрәм, сез ниндидер бер азгын ир каршында бөтенләй җебеп төштегез. Сез алардан күргән җәбер-золымнарны, мыскыллауларны оныттыгызмыни?

Төркем дәшми.

Сез онытсагыз, мин онытмаган. Мин сезнең аллагыз, мәңгелек аллагыз. Сез онытылып киткәндә дә мин уяу булырга тиеш. Йә, алып китегез аны.

Егет. И алла! Шушы кадәр илләр гизеп, шушы кадәр сагынып, тилмереп килеп тә, сөйгәнемнең йөзен бер күрергә дә рөхсәт итмәссеңмени? Тик бер генә тапкыр күрим үзен, аннары мине теләсәң нишләт.

Төркем. Без бит аны үтерергә кайчан да өлгерәбез, и алла! Күреп калсын соңгы тапкыр булса да сөйгән ярын.

Хатын-алла. Сөйгән яр? Бирелә сөйгән ярлар юк, бирелә ирекле хатын-кызлар гына бар... Йә, егет, күтәр башыңны, кара мәгъшукаңны, әгәр таный алсаң...

Егет. О, мин аны меңнәр арасыннан да таныр идем, ләкин ул бирелә юк.

Хатын-алла *(пультка килә, микрофонга иелеп)*. Безнең эрага кадәр туган хатын-кызлар керсен. Инкубаторда туып-үскән кыз-балалар кирәкми. *(Борыла.)* Бу төркемдә

дә булмаса, мин сине аллалыгымда озак тота алмыйм, егет. Синең биредә булуың безнең җәмәгатьчелек өчен бик зарарлы.

Ефәктән киенгән тагы бер төркем керә. Барысының да киемнәре дә, чәчләре дә нәкъ бертөсле.

Хатын-алла. Йә, егет, ник дәшмисең, кайсы синең эзләгәнең?

Егет. Ләкин ул биредә дә юк.

Хатын-алла. Бәлки син инде аны танымыйсыңдыр? Әз гомер узмаган бит.

Егет. И алла, күзләрем йомык булса, мин аны аяк тавышларыннан таныр идем. Инде колакларым да ишетмәсә, мин аны чәчләреннән килгән кыр-урман исләреннән тояр идем. Ләкин ул биредә юк.

Яшь кыз керә.

Яшь кыз *(салкын, рапорт тонында)*. Космик фәннәр институты галимнәре яңа йолдызлар белән элемтәгә кергәннәр. Алар сезне көтәләр, и алла!

Хатын-алла. Йолдызлар торып торыр. Монда әле җирдәге мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк. *(Пультка килә.)* Космик фәннәр институты галимнәре! Барыгыз да минем янга керегез.

Үзе тирән уйга чумып, тахта-тәхетенә барып утыра. Кыска ак халатлар, ак чалбарлар кигән галим хатын-кызлар керә. Вәкарь генә баш иләр. Хатын-алла сүзсез генә ир-атка карый. Ул «юк» дигәнне белдереп, башын чайкый.

Хатын-алла *(галимнәргә)*. Барыгыз да килдегезме?

Галимнәр. Йолдызлар буенча баш галимебез юк.

Хатын-алла *(пультка килеп)*. Йолдызлар буенча баш галим, минем янга керегез әле. *(Галимнәргә.)* Нигә тоткарланды соң ул?

Галимнәр. Ул яңа йолдызлар белән элемтәгә керде. Алардан кемнедер эзли ахры.

Хатын-алла. Кемне эзли ул йолдызлардан? Безнең бу араларда яңа йолдызларга кораблар җибәргәнебез юк бит?

Галимнәр. Бездә тулы хокук, без берәүнең дә күңеленә кермибез, и алла!

Озын сары күлмәк кигән баш галим керә. Егет тезләнгән урыныннан сикереп тора.

Егет. Син! *(Аңа атыла.)*

Кыз башта гаҗәпләнеп бөркәнчек ябынган егеткә карап тора. Аннан, күңеле нидер сизеп, аңа таба атлый.

Кыз. Син! *(Килеп кулларыннан ала.)* Бу бит — син. Мин сине тавышыңнан таныдым. Ә мин сине ерак йолдызлардан эзлим тагы. Җирдә булса, күптән табар иде, килер иде дип, менә инде ничә еллар сине йолдызлардан эзлим!

Егет. Ә син бер дә үзгәрмәгәнсең. Күзләрең генә моңсулана төшкән...

Кыз. Ә мин синең күзләреңне күрә алмыйм. Сал пәрәнҗәңне, бәгърем! *(Әкрен генә, бөркәнчекне салдырырга теләп, кулларын күтәрә.)*

Хатын-алла. Туктагыз! Үзегезнең кайда икәнлегегезне онытмагыз. Йә, егет, син теләгәнеңә ирештең — эзләгән кешеңне күрдең, инде сине безнең җәза көтә.

Төркем. Аһ, алла!

Хатын-алла. Әйе, җәза көтә. Син безнең аллалыкка алдау юлы белән килеп кердең, әйтергә ярамаган сүзләрне әйттең. Әмма иң куркынычы әле бу түгел. Иң куркынычы — син минем төп белгечләремнән берсе булган баш галим йөрәгендә хис дигән, мәхәббәт дигән авыруны кузгаттың. Яман авыруны. Ә аның берninди дә дәвасы юк!

Кыз. Бар! Бар аның дәвасы, аллам! *(Ялвара.)* Аерма син безне бер-беребездән, күрсәт шәфкатеңне, и аллам, синең бит кодрәтең чиксез киң!

Хатын-алла. Бүген син ир-ат белән бергә булырга теләсәң, иртәгә башкалар күңелендә хис кузгалыр. Ул чагында минем аллалыгымнан җирдә ни кала?!

Егет. Шәфкатеңнән аерма, и аллам! Без син ни әйтсәң дә риза. Тик аерма гына безне.

Кыз. Аллам! Җибәр берәр яңа йолдызга. Икебезне. Мәңгегә. Һичкем яшәмәгән берәр йолдызга җибәр безне?!

Хатын-алла. Акылыгыздан шашарсыз! Акылыгыздан шашарсыз, әмма соң булыр. Җир ерак булыр. Юк, мин андый шәфкатьсезлек эшли алмыйм. *(Уйланып.)* Егет, мин сине үз аллалыгымда калдыра алам. *(Кулын күтәреп.)* Тик бер шарт белән — син дә хатын-кызга әйләнергә тиеш.

Егет. Аллам! Кызган мине, мин бит ир-ат булып туган.

Хатын-алла. Ир-ат булып тугансың, хатын-кыз булып үләрсең. Мәхәббәтең хакына.

Егет. Мин... нишләргә тиеш соң... хатын-кыз булу өчен?

Хатын-алла. Иң беренче, беркайчан да менә бу пәрәнҗәңне салмаска!

Егет «дерт» итеп китә. Хатын-алла, кисәтеп, тагын кулын күтәрә.

Хатыныңа беркайчан да тел тибрәтеп каршы сүз әйтмәскә. Йортыгыздагы иң авыр, иң кара эшне дә син башкарырга тиеш. Хатының — минем аллалыгымның иң мөһим белгечләреннән берсе — эшләү өчен аңа бөтен шартлар тудырылырга тиеш. Ашарга хәзерләү дә синең өстә. Менә шуларга риза булсаң — каласың.

Егет. Мин барысына да риза. Тик... *(Туктальт кала.)*

Хатын-алла. Нәрсә, тик?

Егет. Тик... бала табарга гына кушмагыз миңа.

Төркем. Ха-ха-ха!

Хатын-алла. Артта калгансың, егеткәй! Бездә инде 15 елдан бирле баланы кеше тапмый. Без балаларны инкубатор юлы белән табып үстерәбез. Бездә хатын-кызлар

гомерләрен бала табып, бала үстереп әрәм итмиләр, болар барысы да автоматларга тапшырылган. Йә, ярар, барыгыз, үз көнегезне үзегез күрегез. Шул шартларның берсе генә үтәлмәсә дә, егет, безнең җәмгыятьтә урын юк.

Кыз. Барысы да үтәлер, аллабыз. *(Егеткә.)* Курыкма, бәгърем, мин сиңа үзем булышырмын. Мәхәббәт бар җирдә мондый гына авырлыклар авырлыкмыни ул?! Бездә хәзер тау-ташларны телгә китерерлек көч, боз тауларын да эретерлек хис бар. Безнең уртак мәхәббәтебез бар! *(Җитәкләшеп чыгып китәләр.)*

Төркем дә чыга. Сәхнәдә Хатын-алла һәм Яшь кыз калалар, Хатын-алла уйга чумган.

Яшь кыз. Аллам!

Хатын-алла. Аһ, син бирегә идеңмени, кыз бала?

Яшь кыз. Аллам. Мин бирегә сәер сүзләр ишеттем. Нәрсә ул мәхәббәт? Нәрсә ул хис? Инкубатор программасында без аларны үтмәдек.

Хатын-алла. Ярамаган сүзләр ишеткәнсең, кыз бала. Ярамаган сүзләр. Ярар, ахыры хәерле булсын... *(Уйга чума.)*

Яшь кыз *(салкын)*. Аллам! Мин соравыма җавап алмадым. Ә бу безнең җәмгыять законнарына туры килми. Нинди сүз ул мәхәббәт? Нинди сүз ул — хис?

Хатын-алла. Кыз бала! Мәхәббәт ул сүз генә түгел, мәхәббәт ул — хис. *(Үз-үзенә.)* Нәрсә сөйлим әле мин? Мин — алла, яшь кыз балага мәхәббәт турында аңлатам. Нигәдер, фикерләрем чуалып китте...

Яшь кыз. Аллам! Мин берни дә аңламыйм. Мәхәббәт ул — хис, хис ул — мәхәббәт... Бернинди космик терминнарга да туры килми.

Хатын-алла. Аңламассың да шул. Сезнең ясалма каныгызга бу сүзләрнең тәэсире салынмаган. Сездә — салкын акыл, сәләт, тәвәккәллек, ә хис... юк сездә.

Яшь кыз. Аллам! Бу хәл яхшымы әллә, начармы?

Хатын-алла. Сез — инкубатор балалары, безнең җәмгыятьнең иң зур киләчәге. Сезнең ясалма йөрәгегездә беркайчан да хискә урын булмаячак. Беркайчан да... Кыз бала, минем сарай көнемнең яртысы җир эшләрен хәл итеп үтте. Ә миңа яңа йолдызларның берсенә күзәтүләр оештырырга кирәк. Бар әйт, мине юлга хәзерләсеннәр.

Яшь кыз чыгып китә. Хатын-алла ялгызы.

Хатын-алла *(тирән итеп сулап куя, башын куллары белән каплый)*. Юк! Юк! Юк! Мондый хәлнең булуы мөмкин түгел. Ул хис инде миндә күптән үлде, тапталды, юк ителде. Мин аны үзем юк иттем. Үз кулларым белән. Миңа инде 18 яшь түгел, янасы ярылган, йөрәк җәрәхәттән генә тора, анда инде хискә урын юк, юк, юк!!! Ә нигә соң бу җәрәхәтле йөрәк әрнеп сулкылдый... Шулай ук ялгыштыммы икәнни мин? Дөньяда мәхәббәтне, хисне юк итәргә теләдем, тигезлек, хөррият дидем, минем кебек уйлаучы миллионнарча хатын-кызны үз артымнан ияртгем. Ә менә бүген, кабат ир затын күргәч, күңелдә әллә нинди тиле уйлар уянды. *(Уйлана.)* Чыклы үләнгә, ятып йолдызларны санадым... Күзләремнән үпте... «Ә мин йолдызларны санамыйм, минем йолдызым бер генә», — диде. Мин идем ул йолдыз. Аннан, сабый баладай назлап, кулларына күтәрде. «Син — зәңгәр күгем», — диде. Мин кояш та, ай да булдым, бәхеткә, хыялга да әйләндем... Әмма беркөнне мин хатын да булдым. Шуннан, мәңгегә хатын булып калдым да. Хатын булып. Ә бүген мин — алла. Хиссез, йолдызсыз, кояшсыз-айсыз алла. Мәхәббәтсез алла! Әмма алла! Миңа миллионнарның карашы төбәлгән, миллионнарның ышанычы, киләчәге. Миңа хискә бирелергә ярамый. Ярамый. *(Башын тотып.)* Әмма минем, бер генә мизгелгә булса да, кабат хатын булып карыйсым килә... Ә ул ничек матур итеп сөйләде... Ул нинди хисле, тәвәккәл егет! Әгәр мине шулай эзләп килсәләр, алла буларак шәфкать ялварып түгел, хатын-кыз буларак наз

сорап аягыма егылсалар? О!.. Ә мин аның йөзен дә күреп өлгермәдем. Бәлки аны бирегә чакыртыргадыр.

Яшь кыз керә.

Яшь кыз. Махсус кораб әзер, алла!

Хатын-алла. Кыз бала! Башта ир-ат затын минем янга чакыр.

Яшь кыз. Минем зирәк акылым ул кешенең бирედә булуын яхшы дип тапмый.

Хатын-алла. Синең акылың хәл итә торган мәсьәлә түгел бу, кыз бала! Бар, чакыр!

Яшь кыз чыга. Хатын-алла ялгызы.

Хатын-алла. Нәрсә булды миңа. Йөрәгем туктыйм-туктыйм дип тибә. Бөтенләй хәлем китте. *(Барып утыра.)* Ах, кемнәндер иркәләнәсе, сөеләсе, назлау сүзләре ишетәсе килә. Кемнеңдер көчле күкрәгенә башны салып, бер онытыласы килә. *(Сикереп тора.)* Килә! Бу — ул килә. *(Тиз-тиз генә рәтләнә.)*

Бөркәнчек ябынган егет керә. Хатын-алла аның янына атылып килә.

Хатын-алла *(кулларын сузып)*. Егет! Син нигә минем янга бөркәнчектән керәсең?

Егет. О, алла! Мин аны бары тик сөйгәнем янында гына сала алам.

Хатын-алла. Ә мин — алла. *(Шаярып.)* Бирედә минем сүз закон...

Килеп егетнең бөркәнчеген салдыра. Яшь, чибәр ир-ат йөзен күреп, читкә тайпыла.

Хатын-алла *(читкә)*. О, ул нинди чибәр. Ул нинди серле! Ул ничек мине үзенә тарта! *(Егеткә.)* Утыр, чибәр егет, син минем янда бераз ял итә аласың.

Егет. Миңа синең сүзең закон, и алла!

Хатын-алла. Алласын алла, ләкин мин бит хатын-кыз алласы. *(Егетнең чәчләренә кагыла.)* Ә син курыкма, якынрак кил.

Егет якынрак килеп утыра. Хатын-алла кулын аның җилкәсенә сала.

Хатын-алла. Мин сине нигә аллалыкта калдырганны беләсеңме?

Егет *(башын иеп)*. Синең шәфкатең чиксез киң, алиһә. Мин бу яхшылыкны мәңге онытмам.

Хатын-алла. Ә нигә мәңгелеккә калдырырга? *(Якынрак килеп.)* Кочакла мине, о, егет, мәхәббәтен эзләп килгән тәвәккәл егет!

Егет *(гаҗәпләнеп)*. Ләкин минем мәхәббәтем син түгел бит, алиһә!

Хатын-алла. Ә сиңа барыбер түгелмени, ир-ат? Синең каршыңда алиһә үзе баш ия. Синдә аның хисләрен кире кагарлык көч, ай-һай, булырмы икән?

Егет. Алиһә! Йә син мине сыныйсың, йә — көләсең! Нигә кирәк минем белән болай рәхимсез шаярырга. *(Читкә борыла.)*

Хатын-алла *(атылып килеп)*. Тукта! *(Кочаклап ала.)* Аһ, тиле егет, тиле егет. Соң син менә миңа кагылып кара *(кулын алып күкрәгенә куя)*, мин бит ут янам, мин бит хистән шашыр дәрәҗәгә җиткән! *(Иркәләнә.)* Йә, кочакла мине, йә, курыкма, йә?

Егет гаҗәпләнеп, тетрәнеп аңа карый. Хатын-алланың кулларын көч белән үзеннән каерып ала.

Егет. Ю-у-к, юк, алиһә... Мин мәхәббәтемә хыянәт итә алмыйм. Мин ул мәхәббәт хакына тормышта бөтен нәрсәдән ваз кичтем — ирегемнән аерылдым, ирлегемнән баш тарттым. Инде син мине нәрсәгә өндисең. *(Китә башлый.)*

Хатын-алла *(егетнең аякларына тезләнеп)*. Китмә! Мин синең хакка барысын да эшлим, ирегеңне дә, ирлегең-

не дә кире кайтарам. Тик кал гына минем янымда. Тик бер генә тапкыр булса да, кал?!

Егет. Хыянәт бер генә тапкыр була. Хыянәт бер генә тапкыр була, алиһә! Аннары инде ул хыянәт түгел, гадәткә әйләнә. Юк, мин моңа риза түгел, алиһә! Мине җәзалый аласың, үтерә аласың, тик үзеңнеке итә алмассың, алиһә! *(Чыгып китә.)*

Хатын-алла тезләнгән хәлдә ялгызы кала.

Хатын-алла. Ул миннән баш тартты. Ул миннән, хатын-кызлар алласыннан баш тартты! О! О! Әйе, мин аны җәзалый да, үтерә дә алам. Ләкин ул миңа кирәк. Ул миңа ир-ат буларак кирәк. Ул минем инде беткән, тапталган хисләремне кабат кузгатты. Ул минем йөрәгемне йокыдан уятты. О! О! Син минеке булырсың әле, егет. Моны сиңа мин, хатын-кызлар алласы әйтәм.

Яшь кыз керә.

Яшь кыз. Махсус самолетыгыз сезне көтә, и алла!

Хатын-алла *(ашыгып)*. Бик яхшы. Әйе, эшкә чумарга кирәк миңа хәзер. Ул авырудан башка дәва юк! Дәва юк... *(Ашыгып чыгып китә.)*

Яшь кыз ялгызы. Аякларын бөкләп тахта-тәхеткә менеп утыра.

Яшь кыз. Минем инкубатор белеменә бүген яңа сүзләр өстәлде — мәхәббәт, хис. Ләкин мин аларның мәгънәсен белмим. Мин белергә тиеш. Безне инкубаторда шулай өйрәттеләр. Мин белергә тиеш. Аның өчен мин нишләргә тиеш? Мин күрергә тиеш. Нәрсәне? Мәхәббәтне, хисне. Ә кайда ул мәхәббәт, хис? *(Пультка килә.)* Инкубатор балалары, алла сараена керегез! Киңәшәсе бар... Әйе, мин ул нәрсәне белергә тиеш!

Төз, озын аяклы, кыска ак спорт киемнәре кигән яшь кызлар керә. Берәм-берәм тахтага килеп утыралар. Кайсылары сузылып ята. Салкыннар, битарафлар.

Я ш ь к ы з. Минем сезгә соравым бар. Нәрсә ул мәхәббәт? Нәрсә ул хис?

К ы з л а р *(салкын)*. Без моны инкубатор программасында үтмәдек.

Я ш ь к ы з. Мин дә үтмәдем. Ә менә тормышта андый сүзләр бар икән.

К ы з л а р. Күрсәт.

Я ш ь к ы з. Нәрсәне күрсәтим?

К ы з л а р. Мәхәббәтне, хисне.

Я ш ь к ы з. Мин аны белмим. Ләкин минем салкын акылым мәхәббәтне белгән кешеләрне белә. *(Пультка килә. Кнопкага баса. Экранда безгә таныш Егет белән Кыз күренә. Егет, бөркәнчек ябынып, ашарга пешереп йөри. Кыз өстәл янында язып утыра.)* Менә ул мәхәббәт. Карагыз.

К ы з л а р. Өстәл янында утырганы — йолдызлар буенча баш галим. Тегесе ниндидер җанвар.

Я ш ь к ы з. Җанвар түгел ул, безнең кебек үк кеше. Тик аның исеме ир-ат.

К ы з л а р *(салкын)*. Белмибез.

Ул арада экрандагы кыз урыныннан тора, егет янына килә, кулларыннан алып, янәшә утырта. Нидер аңлата, егет, каршылык белгертеп, башын селки. Кыз аны тыңламый, әкрен генә күтәреп, бөркәнчеген ача. Алар, бер-берсенең кулларыннан тотып, шактый вакыт карашып торалар.

Я ш ь к ы з. Аның йөзе безнекенә охшамаган. Ул әллә нинди, сәер.

Экрандагы егет белән кыз бер-берсенә якын ук киләләр, әкрен генә бер-берсенең иреннәреннән үбәләр. Тахта-тәхеттә утырган яшь кызлар бик зур игътибар белән аларны күзәтәләр.

Б е р к ы з. Нишлиләр алар?

И к е н ч е с е. Без моны инкубатор программасында үтмәдек.

Я ш ь к ы з. Аларны бирегә чакырырга кирәк. *(Пультка килә.)* Ир-ат дип аталган адәм һәм баш галим! Алла сараена керүегез сорала!

Экранда кочаклашып утырган егет белән кыз, гаҗәпләнеп, бу якка карыйлар, аннан тагы бер-беренә карап торалар. Егет тиз генә алып бөркәнчеген кия һәм ашыгып чыгып китәләр.

Яшь кыз. Без мәсьәләне уртага салып хәл итәрбез, тикшерү объектларына конкрет анализ ясарбыз, бәлки математик юл белән сорауларга җавап табарбыз.

Егет белән кыз керә. Яшь кызлар әкрен генә урыннарыннан торып, егет янына җыелалар.

Яшь кыз *(бөркәнчеккә ишарәләп)*. Бу чүпрәк кисәге ни өчен кулланыла?

Егет. Сездән йөземне яшерер өчен, туташ.

Яшь кыз. Ә йөз яшерү ни өчен кирәк?

Егет. Сезне, хатын-кызны... аздырмас өчен, туташ.

Яшь кыз. Азыну дигән сүз безгә таныш түгел. Йөзеңне ач!

Кыз. Ярамый, кыз бала. Аңарга сезнең каршыда йөзен ачарга ярамый.

Яшь кыз. Мин ярамый дигән сүзне белмим. Йөзеңне ач!

Егетнең бөркәнчеген тартып төшерә. Яшь кызлар, зур гаҗәпләнү белән, аны әйләнеп чыгалар.

Кызлар. Ә ул безгә охшамаган.

— Сәер, ямьсез, тупас җан иясе.

— Аның йөзе күбрәк ат йөзенә охшаган.

— Ә аның мәхәббәте, хисе кайда икән?

Яшь кыз *(егеткә)*. Синең мәхәббәтең кайда?

Егет *(кызга күрсәтеп)*. Менә минем мәхәббәтем.

Яшь кыз. Ул мәхәббәт түгел. Ул йолдызлар буенча баш галим.

Егет. Ул сезнең өчен баш галим, ә минем өчен гомерлек мәхәббәтем.

Яшь кыз. Ышандырырлык түгел. Исбатлау сорала. Исбатлап күрсәтегез мәхәббәтегезне.

Кыз. Оял бераз, кыз бала!

Я ш ь к ы з *(салкын)*. Оят сүзе миңа таныш түгел. Мин салкын акыл белән эш итәм. Ә ул һәрбер аңламаган нәрсәне исбатлауны таләп итә.

Е г е т. Мәхәббәтне исбатлау өчен бөтен бер гомер кирәк. Аны бер минутта гына исбатлап булмый.

Я ш ь к ы з. Беренче мәсьәлә хәл ителмәде. Икенчесе. Без экранны күзәткәндә, сез нindидер сәер эш эшләдегез. Нишләдегез сез? Кабатлап күрсәтегез.

К ы з. Оят сиңа, кыз бала!

Я ш ь к ы з. Кабатлап әйтәм, ул сүз миңа таныш түгел. Инкубатор программасында ул сүз каралмаган.

К ы з. Ләкин бит әле инкубатордан башка тормыш дигән нәрсә бар!

Я ш ь к ы з. Исбат итмәдегез.

К ы з л а р.

— Әйе, исбат итмәдегез.

— Кабатлагыз, нәрсә эшләгән идегез?

Егет белән кыз, сәерсенеп, бер-берсенә карашалар, әкрен генә якын киләләр, кочаклашып үбешәләр. Яшь кызлар, зур игътибар белән якын ук килеп, карап торалар.

Я ш ь к ы з. Бу хезмәт ничек дип атала?

Е г е т. Бу — хезмәт түгел, бу мәхәббәтнең, хиснең шулай кайнап тышка чыгуы, бер билгесе.

Я ш ь к ы з. Исбатламадыгыз. Сез тагы анда ни эшләдегез, кабатлап күрсәтегез.

Егет белән кыз, куркышып, бер-берсеннән читкә тайпылалар.

Е г е т. Сез нишлисез?! Сез бит хатын-кызлар! Оят дигән нәрсәне белмисез икән, әдәп, тыйнаклык булырга тиеш бераз! Йөрәгегез бардыр бит!

Я ш ь к ы з. Юк бездә чын йөрәк. Бездә ясалма йөрәк кенә. Без хис белән түгел, акыл белән эш итәбез.

К ы з л а р. Сез безгә мәхәббәтегезне ахырына кадәр исбатлап күрсәтергә тиеш.

— Күрсәтергә тиеш!
— Күрсәтергә тиеш! *(Егетне тарткалыйлар.)*

Егет *(ярсып)*. Юк, юк, юк! Беркайчан да! Беркайчан да! Йә, Алла! Кайда эләктем мин! Нигә ир-ат булып тудым икән бу дөньяга?! *(Ашыгып, бөркәнчеген ябына.)*

Кыз. Тынычлан, бәгърем. Янәшәңдә мин барында бернинди нәрсәдән курыкма. *(Пультка килә.)* Өлкән тәрбияче ана! Өлкән тәрбияче ана! Хәзер үк алла сараена керегез! Хәзер үк алла сараена керегез!

Яшь кызлар берәм-берәм тахта-тәхеткә килеп утыралар. Салкын, битараф кыяфәт.

Әйттем мин аллаһе тәгаләгә. Инкубатор балаларына үзебездәге кебек чык йөрәк ясыйк, дидем. Риза булмады. Имеш, чын йөрәк булса, аларда хис кузгалачак, ә хис бар җирдә мәхәббәт бар. Мәхәббәт бар җирдә ир-ат бар... Бу кыз балалар үзләре үк ир-аттан куркынычрак, яманрак бит.

Ашыгып өлкән тәрбияче ана керә. Ул теге вакытта без күргән ана.

Ана. Ни булды биредә? Нигә хәвеф-хәтәр сигналлары эшли башлады?

Яшь кыз *(егеткә күрсәтеп)*. Без менә бу ир-аттан мәхәббәтен исбатлауны таләп иттек.

Ана. Ир-ат? *(Егет янына килә. Бөркәнчеген күтәрә.)* Йә, хода, ир-ат шул. *(Яшь кызларга.)* Кыз балалар, сез хәзер барыгыз да инкубаторларыгызга кайтыгыз. Анда хәзер оча торган автомобильләрне сынау башланачак.

Яшь кызлар дәррәү сикереп торып, «Ур-р-ра!» кычкырып чыгып йөгерәләр.

Ана. Теге дөньядан бер ир-ат килгән дип ишеткән идем, син идеңмени инде ул, егет? Мәхәббәтен эзләп килгән егет?

Егет. Өлкән тәрбияче ана! Миңа бередә куркыныч. Алар миннән очраган бер җирдә мәхәббәтемне, ирлегемне исбатлауны таләп итә башласалар... ул мәхәббәт гадәткә әйләнер, ул мәхәббәт югалыр бит.

Кыз. Җаным! Син ни сөйлисең? Мин сине биредә калдыраммы соң? Мин башта барысына да риза идем: синең хатын-кыз кыяфәтенә керүеңә дә, бөркәнчек ябынуыңа да. Ләкин синең күңелеңне бу ясалма йөрәкле ясалма кызларның таптавына юл куймам. *(Кочаклый.)* Мин сине артык озак көттем, инде сине, синең мәхәббәтеңне югалтасым килми. *(Елый.)*

Егет. Нишлик соң, җаным, нишлик?

Кыз. Син моннан 15 ел элек бу сорауны биргәндә, мин әле аңа җавап бирергә әзер түгел идем. Мин бүген синең ул соравыңа җавап бирә алам, җаным! Китәбез! Үзем ачкан яңа йолдызларның берсенә китәбез.

Ана. Чү, бала, акылыңа кил, анда бит сез ялгызлыктан акылдан шашачаксыз! Анда бит мәңгелек караңгылык, салкынлык, бушлык!..

Кыз. Кайгырма, Ана, анда саф сөю белән янган, гадәт-гайбәтләрдән өстен булган яңа парлар киләчәк. Анда мәхәббәт аллалыгы булачак. *(Егеткә.)* Киттек, бәгърем, төп алла — табигать алласы тарафыннан безгә бик аз гомер бирелгән. Без аның яртысын инде болай да әрәмгә, мәгънәсезгә уздырдык. Киттек!

Ана. Туктагыз, балалар! Алай ашыкмагыз. Уйлагыз, Җирдән китәсез бит. Мәңгегә китәсез. Мондый табигатьне, мондагыдай айлы кичләрне, чишмә-суларны сез бит беркайчан да таба алмаячаксыз. Болар бит бары тик Җирдә генә бар! Җирдә генә!

Егет. Әмма Җирдә әле тупаслык, ялган, битарафлык та бар. Җирдә әлеге ясалма йөрәкле кешеләр дә бар. Без андый Җирдән баш тартабыз. Җансыз кешеләр арасында яшәгәнче, җансыз планетада яшәвең артыграк.

Кыз. Өлкән тәрбияче ана! Әйдә безнең белән. Син безгә анабыз урынына булырсың.

А н а. Юк, балалар. Беркайчан да, беркайчан да мин бу Җирдән китә алмаячакмын.

Егет. Ни тота сине җирдә, Ана? Ниең кала синең биредә?

А н а. Аналарны җирдә балалар тота. Балалар... Ана кеше Җир язмышы өчен дә, баласы язмышы өчен дә бертөрле хәвефләнә, борчыла. Ана кешелекнең мәңгелек сакчысы. Ананың балалары исән чагында, Җир йөзен ташлап китәргә хакы юк.

К ы з. Ә безгә рөхсәтең бармы соң, Ана? Бир бер киңәшеңне Җирнең адашкан балаларына!

Егет белән Кыз Ана каршына килеп тезләнәләр. Ана аларның башына кулын сала.

А н а. Барыгыз, балалар, төзегез үз дөньягызны. Йолдыздамы, айдамы — икәү янәшә булганда сезгә инде берни дә куркыныч түгел. Иң мөһиме — бер-берегезгә карата мәхәббәтегезне югалтмагыз, хисләрегезне саклагыз. Табигать-алла сезне бер-берегез өчен яраткан икән, моны инде башка бернинди көч тә юкка чыгара алмый. Йөрәгегез керсез, мәхәббәтегез саф чагында качып калыгыз бу гөнаһлы дөньядан! Барыгыз.

Егет белән кыз җитәкләшеп чыгып китәләр. Ана ялгызы. Тирән уйда.

А н а *(башын күтәреп)*. Дөрес эшләдемме мин аларны биредән озатып, ә аллага ни дип җавап бирермен? Аллага... Ә ни өчен аллага? Алла каршында минем гаебем юк. Дөньяда минем бер генә кеше каршында гаебем бар. Гаеп кенә дә түгел, җинаять. Гомерлек үкенеч... Менә минем дә бүген шушындый улым булыр иде бит инде. Нәни оныкларымны да тезләремдә сөяр идем. Алар минем улыма охшаган түгәрәк, матур балалар булырлар иде. *(Пышылдый.)* Йә, хода, нишләттең син мине? Мин генәме, сиңа ияргән тагы күпме хатын-кызлар гомере буе вөҗдан газабы кичерәләр, җаннарына урын таба алмыйлар. Уз-

ганнар күңелсез, ә киләчәк бөтенләй өметсез бит, бөтенләй өметсез. Яшьләр качтылар да котылдылар, ә мин кая качыйм үз-үземнән? Гаебемнән, җинаятемнән?! Мине дөньяда бер генә кеше хөкем итә ала — ул минем балам! *(Торып баса.)* Мин аны эзләп табарга тиеш! Сабый чагындагы кебек, алдына тезләнеп гафу үтенергә тиеш. Анасыз, назсыз үзган балачагы өчен гафу үтенергә тиеш мин аннан! *(Чыгып китә.)*

Сәхнә бераз буш тора. Бераздан яшь кызлар керә. Алар кулларын артка каерып бәйләгән егет белән кызны алып керәләр.

Кыз. Җибәрегез безне! Безне тоткарларга сезнең хакыгыз юк!

Яшь кыз. Сез аллалыкның законнарын боздыгыз: сез бернинди киңәш-рөхсәтсез аллалыктан качмакчы булдыгыз. Ә бу — җинаять.

Егет. Безне хөкем итәргә сезнең хакыгыз юк. Безне алла кулына тапшырыгыз!

Яшь кыз. Бездә — тигез хокук, хөррият. Һәм без үзебез — инкубатор балалары сезне хөкем итәчәкбез. Бу безгә тормыш мәктәбе булачак. *(Егеткә.)* Ә син, ир-ат, безнең каршыда икеләтә гаепле!

Егет. Сезнең каршыда?! Юк, мин сезнең каршыда түгел *(кызга күрсәтеп)*, менә аның каршында гына бик зур гаепле. Кичер мине, бәгърем, кичерә алсаң? Әгәр мин булмасам, син бу кимсетелүләрне, җәберне күрмәс идең. Кичер мине... *(Алдына тезләнә.)*

Кыз. Әгәр син булмасаң, мин дөньяда мәхәббәт барлыгын да белмәс идем. *(Алдына тезләнә.)* Син минем иң зур шатлыгым, син минем иң якты хыялым, син минем иң моңлы сагышым. Син... *(Башын аның җилкәсенә сала.)*

Яшь кызлар аларны уратып алалар.

Яшь кызлар. Алар үлем алдыннан да мәхәббәт турында сөйләшәләр.

— Нәрсә соң ул мәхәббәт?

— Кайда була ул?

Яшь кыз. Әй, ир-ат, без синнән соңгы тапкыр сорыйбыз — кайда синең мәхәббәтең?

Егет *(күкрәгенә ишарәләп, ярсып)*. Йөрәгемдә минем мәхәббәтем, йөрәгемдә! Ләкин сезгә аны күрү насыйп булмаячак. Сез бит ясалма йөрәкләр! Сез бит мескен автоматлар! Сез бәхетсез тимер кисәкләре!

Яшь кыз. Йөрәктә. Димәк, мәхәббәт йөрәктә була. *(Яшь кызларга.)* Хәзер тикшерәбез аны. *(Егеткә.)* Без хәзер синең йөрәгеңне суырып алып, мәхәббәтеңне тикшереп карыйбыз. Аннан үзеңә ясалма йөрәк куярбыз.

Кыз. Аһ! Юк! *(Сикереп тора.)* Юк! Ясалма йөрәктә мәхәббәт булалмый. Ә мәхәббәттән, хистән башка ул нинди кеше булсын! Зинһар, мәрхәмәт күрсәтегез, кагылмагыз аңа?!

Яшь кыз. Без аңлашылмаган һәр нәрсәне исбат итәргә тиеш. Алып китегез аны, алыгыз йөрәген, тикшерегез микроскоп астында.

Яшь кызлар егетне алып чыга башлыйлар.

Кыз. Кагылмагыз аңа! Ул дөрес әйтмәде. Юк аның йөрәгендә мәхәббәте! Мине алып китегез туракларга, минем йөрәгемдә ул мәхәббәт! Минем йөрәгемдә!

Яшь кыз. Ул чагында, икегезнең дә йөрәген тикшерергә, аннан үзегезгә ясалма йөрәк куярга туры килер. Борчылмагыз, безнең өчен бер минутлык эш бу.

Егет. Безгә ясалма йөрәк? Мәхәббәтсез-хиссез, шатлык-сагышсыз, хыял-борчусыз ясалма йөрәк? Ха-ха-ха-ха! Ха-ха-ха-ха!

Кычкырып көлә башлый. Кыз да аңа кушыла. Тыела алмый көләләр.

Яшь кыз *(салкын)*. Сез нишлисез?

Егет. Көләбез. Сезнең вәхшилектән, мәгънәсезлектән, акылсызлыктан көләбез.

Яшь кыз. Нәрсә ул вәхшилек?

Егет. Вәхшилекме? Кешеләргә ясалма йөрәк кую вәхшилек. Аны мәхәббәттән, хистән мәхрүм итү вәхшилек. Ясалма йөрәкле кеше чын кеше булмый инде ул.

Яшь кыз. Сезнеңчә, без дә чын кешеләр түгелме?

Егет. Сез?! Әлбәттә, чын кешеләр түгел.

Яшь кыз. Ә кемнәр соң без алайса?

Егет. Сез... кешелекнең ялгышы, куркыныч ялгышы.

Яшь кыз. Без ялгыш түгел. Без заманның законлы балалары. Һәм сез дә хәзер бездәге кебек үк ясалма йөрәкле булачаксыз.

Кыз. Юк! Беркайчан да!!!

Егет. Ясалма йөрәк белән яшәгәнче, үлүең артык!

Яшь кыз. Йә ясалма йөрәк, йә үлем сезгә! Икенең берсен сайлагыз.

Кыз. Без мәхәббәтне сайлыйбыз. Ә мәхәббәт — үлемсез! Безнең мәхәббәтебез хакында җырларда җырланачак. Җирдә булмаса, йолдызлардан йолдызларга барып җитәчәк мәхәббәт турында легенда! Бу мәхәббәт каршында сез көчсез, көчсез сез, мескеннәр!

Яшь кыз. Икесен дә алып китегез.

Егет белән кызны алып китә башлыйлар. Каршыларына Хатын-алла кайтып керә.

Хатын-алла. Нәрсә булды биредә? Нигә аларның куллары бәйле?

Яшь кыз. Без аларның йөрәкләрен суырып алып, мәхәббәтләрен тикшерәчәкбез.

Хатын-алла. Сез нәрсә сөйлисез?! Алар бит кешеләр! Алар бит йөрәксез бер минут та яши алмаячаклар!

Яшь кыз. Без яшибез бит әле. Йөрәксез дә яшибез, хиссез дә яшибез, мәхәббәтсез дә яшибез!

Хатын-алла. Сез бит чын кешеләр түгел, сез ясалма йөрәкле ясалма кешеләр.

Яшь кызлар *(гүләп)*:

— Без — кешеләр!

— Без сездән дә зирәгрәк, акыллырак кешеләр!

— Һәм без үз дигәнебезне эшләячәкбез!
— Без сезнең һәммәгезне дә йөрәксез итәчәкбез!

Егет белән кызны төрткәләп алып чыга башлыйлар. Кыз нечкә, саф тавыш белән җыр башлый. Аңа егет тә кушыла. Аннан икесе дә көлә башлыйлар.

Хатын-алла *(кулларын җәеп, аларның каршына килеп баса)*. Туктагыз! Калдырыгыз аларны! Алар бит акылдан шашканнар!

Яшь кыз. Акылдан шашып булмый. Акыл — бөек, акыл — мәңгелек. *(Алып чыгып китәләр.)*

Хатын-алла ялгызы.

Хатын-алла. Нәрсә бу? Нәрсә бу?! Алар исән кешеләрнең йөрәкләрен суырып ала башладылар. О, нинди кансызлык! Нинди мәрхәмәтсезлек! Һәм мин — алла — берни дә эшли алмыйм. Әгәр минем дә йөрәгемдә мәхәббәт, хис барын белсәләр, мине дә шул ук җәза көтә бит! Ә алар сине үтәдән-үтә күрәләр, аларда бит зирәк акыл, алар бит кеше түгел, салкын автоматлар. О, нишләргә? Кемгә барып яклау сорарга? Яклаучым? Кайда ишеттем мин бу сүзне? Кем минем яклаучым, кем?!

Гасабиланып бүлмә буйлап йөри. Битләрен каплап, тахта-тәхетенә килеп утыра.

ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

Сәхнә берара караңгыланып тора. Аннан бераз яктыра. Безнең алда — кыя-тауларга уеп ясалган ирләр аллалыгы. Тар кара креслода, залга арты белән, ирләр алласы утырган. Каршысында — йолдызлар картасы. Ул шуны күзәтә. Кинәт тавышлар ишетелә. Тавышлар көчәя. Кулларын ике ягына ике ир-ат каерып тоткан Ана керә. Чәчләре тузган, битенә төшкән. Үзе ялантяк.

Ана. Ир-ат, син буласыңмы ирләр алласы?

Ир-алла кинәт бу якка борыла.

Ир-алла. Минем патшалыгымда хатын-кыз?! Кем рөхсәте белән?!

Ана *(үзен тоткан ике ир-атны көч белән ике якка этеп җибәреп, алга чыга).* Мин — Ана! Мин бирегә газиз улымны эзләп килдем. Мине аның белән кавыштырмаска берәүнең дә хакы юк, хәтта синең дә, и алла!

Ир-алла. Ана?!

Ана. Әйе, мин аны тугыз ай буе йөрәгем астында саклап йөрттем. Мин аны зур газаплар, авырлыклар белән дөньяга тудырдым. Мин аны төн йокыларымны йокламый күкрәк сөте белән туйдырдым. Мин — Ана.

Ир-алла. Әйе, син тапкансыңдыр, күкрәк сөте белән дә туйдыргансыңдыр. Ә соңыннан? Әле яңа тәпи баскан, әни сүзен яңа әйтергә өйрәнгән сабыеңны ташлап, син кая киттең?! Хатын-кызлар аллалыгына! Балаң сине чакырып, төннәр буе елап чыга иде. Тик аның әрнүен, юксынуын менә бу салкын таш-кыялар гына ишетте. Ана назы урынына битләрен зәһәр җилләр өшетте. Ә син ул вакытта, аңа наз, җылылык иң кирәкле вакытта, син юк идең! Син аны ташладың. Сиңа тигез хокуклы хатын-кызлар аллалыгы кирәк иде! Хәзер менә улым, дисең. Юк ул синең улың! Синең өчен юк!

Ана *(аның аягына егылып).* Аһ, аллам. Юк минем гаебем бу囊 эштә. Юк! Мин баламны бер генә минутка да күңел түремнән чыгармадым. Мин гаепле түгел безнең аерым яшәвебезгә. Гаепле түгел!

Ир-алла. Шулай, сез, хатын-кызлар, беркайчан да гаепне үз өстегезгә алмыйсыз. Йә, алайса, кем гаепле соң? Тагы шул ир-атмы?

Ана *(аягына баса, кискен).* Сез — аллалар гаепле бу гөнаһлы эштә! Дөньяны ясалма йөрәкле, салкын канлы кешеләр басып китүгә дә сез гаепле! Йә, нәрсәгә ирештегез сез үзегезнең мөстәкыйль аллалыкларыгыз белән? Кешене хистән, наздан, мәхәббәттән мәхрүм иттегез. Кешене автоматка, роботка әйләндердегез. Һәм, дөнья шулар кулына кала, дип лаф орасыз. Дөнья гына түгел, сез үзегез дә

шул ясалма йөрәкле кешеләр кулына калачаксыз бит! Аларда инде ярату, соклану хисе булмаган кебек, кызгану хисе дә булмаячак. Бер йотым суга тилмереп үләчәксез бит сез!

Ир-алла. Ләкин мин — алла! Ә аллалар беркайчан да кызгануга, ярдәмгә мохтаҗ булмыйлар.

Ана. Әйе, син — алла. Ләкин аллалар санаулы гына була, ә сукырларча сезгә иярүчеләр, табынучылар — меңнәр, миллионнар! Менә шуларның киләчәге куркытырга тиеш сине, и алла!

Ир-алла. Мин дөрес юлдан барам. Минем моңа иманым камил. Ә син, хатын-кыз, шайтан коткысы таратасың. Сине бирегә юри котыртып җибәргәннәр. Минем аллалыгымның нигезләрен какшатыр өчен махсус җибәргәннәр. Ләкин бу эш барып чыкмас. Бу нигезне син түгел, синнән көчлерәкләр дә җимерә алмады. Ә менә сине, аллага тел тидергәнең өчен иң каты җәза көтә. Мин сине котырган ирләр арасына ташлыйм.

Ана. Синең моны эшләргә хакың юк. Чөнки мин — Ана. Җир йөзенә тереклекне тудыручы.

Ир-алла. Хәзер Җир йөзенә тереклекне аналар тудырмый, моны хәзер машиналар да бик яхшы эшли. Шулай булгач, синең җырың җырланган, хатын-кыз. *(Пультка килә.)* Безнең эрага кадәр туган ир-атларны бирегә кертегез. Салкын канлы ир-егетләр кермәсен. *(Анага.)* Менә син хәзер ничек сайрарсың икән, хатын-кыз? Аларның инде ничә еллар сезнең халыкны күргәннәре юк. Менә син аларга аңлатып кара үзеңнең кем икәнлегеңне. Ха-ха-ха! *(Чыга.)*

Ана ялгызы. Бераздан гүләп, барабаннар каккан, ат тояклары тавышлары чыгарып, сәхнәгә кара киемле ир-атлар атылып керә.

Ир-атлар:

— А-а-а! Хатын-кыз!

— Ничә еллар буе безнең төшләргә генә кергән хатын-кыз!

— Без сине хәтерлибез әле, о, хатын-кыз!

Ана тирәсендә кыргый бию башлана. Түгәрәк таралганнан-тарая бара, Ананы чорнап ала. Ир-атлар килеп Ананы тарткалый башлыйлар.

Ир-атлар. О, хатын-кыз, син бераз картрак инде картрагын, шулай да ярыйсы гына әле.

— О, хатын-кыз! Салып ташла бу сәләмәләреңне! Сине алда сөю-сөелү, ләззәт көтә!

Ана. Туктагыз! Сез нишлисез?! Мин бит Ана. Бирегә бердәнбер баласын—улын эзләп килгән карт ана...

Ир-атлар. Ана? Бу сүз безгә бераз таныш кебек. Ләкин ул хатирәләр бик еракта, гомернең башында ук күмелеп калган. Без ул сүзнең мәгънәсен искә төшерә алмыйбыз.

Ана. Ана сүзен оныткансыз икән, битләрегездән иркәләгән язгы кояш нурларын, йомшак таң җилләрен исегезгә төшерегез. Ана назы әнә шушындый булыр. Алай да хәтерегез уянмый икән, кышкы салкыннарда да туңмый торган диңгез суларына карагыз—ана күңеле, ана мәхәббәте әнә шуңа охшаган булыр. Алай да ана дигән затның кем икәнен аңламыйсыз икән, балаларын яклап кан дошманнарына каршы тигезсез көрәшкә ташланган ана җәнлекләргә карагыз. Ана батырлыгы, ана фидакарьлеге әнә шул булыр.

Бер егет. Исемә төште.

Ана *(сәерсенеп аңа карый, аңа таба берничә адым ясый)*. Нәрсә исеңә төште, бала?

Егет. Абына-сөртенә йөгереп, ул кешенең тезләренә килеп каплануым исемдә. Аның да миңа таба иелгәч, зур матур күзләренең яктырып китүе исемдә. Ул кешедән килгән җылы, тәмле ис—сөт исе, ризык, чәчкә исләре әле дә минем төшләремә кереп саташтыра. Мин «әни!» дип кычкырам да, уянып китәм. Ә янәшәмдә салкын кыя таулар, рәхимсез очлы ташлар. Шулкадәр озак гомер кайда булдың соң син, и ана!

Бер-беренә таба атлыйлар. Ир-ат төркеме әкрен-әкрен артка чигенеп чыгып китә.

А н а *(баласының башыннан кочып)*. Син мине таныгансың икән, димәк, мин синдә булганмын, балам. Синең каныңда, хисләреңдә, синең хыялларыңда, үткәннәреңдә, бүгенгеңдә булганмын.

Е г е т. Син миннән тагы китмәссеңме, анам?

А н а. Ә мин сиңа кирәк булырмынмы соң, улым?

Е г е т. О, анам, әле миңа ачылмаган күпме серләр бар! Минем әле беркем дә белмәгән күпме хыялларым, бу дөньяга күпме сорауларым бар. Аларны мин бары тик синең белән генә уртаклаша алам, анам!

А н а. Әйдә, балам. Мин сиңа дөньяның матурлыгын җырлармын. Мин сиңа дөньяның мәңгелеге турында дастаннар сөйләрмен. Син мәхәббәт, бәхет турында легендалар ишетерсең. Мин сине иң гади нәрсәләргә — кешеләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле булырга өйрәтермен. Әйдә, балам.

Ишеккә баралар. Каршыларында Ир-алла.

И р - а л л а. Мин синең аллаң, егет. Һәм син минем сүзләремнән чыкмаска тиеш. Ваз кич бу хатыннан!

А н а. Син — Алла, ә мин — Ана. Син — берүзең, ә без, аналар, әнә ни чаклы! Кит юлымнан! *(Улын коча.)* Бер алла түгел, мең алла каршы чыкса да, ананы баладан аерыр көч юк бу дөньяда. Юк! *(Китә башлый.)*

И р - а л л а. Мин сезне аллалыкта яшәтмим!

А н а. Җир — зур. Анда ана белән балага урын табылыр.

И р - а л л а. Мин сезне Җирдән дә куачакмын. Ха-ха-ха! Инде кая барырсыз икән?

У л ы *(алга чыгып)*. Инде Җирдән дә куасың икән, ерак йолдызларга китәрбез. Китәрбез бит, анам? Мине һәрвакыт әнә ул билгесез йолдызлар, әнә ул зәңгәр күк үзенә тартты. Сез ризамы, анам, минем белән бергә җирдән китәргә?

Ана тирән уйда.

А н а. Бер якта — газиз балам, икенче якта газиз җирем. Мин, ана, шуларның кайсын сайларга тиеш? Икесе бер

йөрәккә сыймыйлар... Җиремдә калсам — инде мәңгегә газиз баламнан аерылам. Балам белән ерак йолдызларга китсәм — Җирсез, илсез калам. О, Җир! Кичер мине, кичер мине — чәчләренә чал кергән бер карт ананы! Мин баламны ташлый алмыйм. Мин аның белән галәмнең читенә китәргә дә әзер. Тик син генә кичер мине, Җирем. *(Тезләнеп елый.)*

Улы. Тор, анам! Җиргә синең күз яшьләрең күп тамды инде. Ә бит Җирнең гаебе юк. Ул бүген үзе дә ярдәмгә мохтаҗ. Ул үзе бүген тапталган, ташланган карт ана хәлендә. Ул сине аңлар, аналар бер-берсен сүзсез аңлый алар. Әйдә, анам, яхшы күңелле карт анам.

Анасын күтәреп торгыза. Ана белән Ул, башларын югары тотып, чыгып китәләр.
Ир-алла ялгызы.

Ир-алла *(пультка иелеп)*. Аллалыктан чыгармагыз үзләрен! *(Үзалдына.)* О, хатын-кыз! О, мәкерле зат! Аллалыкның бөтен тынычлыгын боздың син! Анда әнә ирзатлар котыра, ничек тә тыяр хәл юк үзләрен. Монда балаларын аналары җитәкләп алып китә. Юк, болай булмый бит. Болай минем аллалыктан җирдә ни кала? Бетә, таркала аллалык. Нишләргә соң, кем белән киңәшергә?

Сәхнәгә кара тар киемле ир балалар керә. Болар да ясалма йөрәкле кешеләр. Яшь кызлардагы кебек ук, салкын акыл, салкын кан.

Яшь егет. Аллабыз. Без сиңа сорау белән килдек.

Ир-алла. Әйтегез, ир-балалар. Нинди сорау борчый сезне?

Яшь егет. Аллалыкның бер ир-аты безгә билгесез нәрсәгә ияреп китте. Ләкин без аларны тоттык. Без белмәгән нинди сәер җан ул?

Ир-алла. Ул — Ана.

Яшь егет. Нәрсә ул — ана?! Ул кешеме, әллә җанвармы?

Ир-алла. Ана ул — кешелеккә кеше инде анысы. Әмма ул — хатын-кыз.

Яшь егет *(ярсып)*. Ә хатын-кыз безнең кан дошманыбыз бит!

Яшь егетләр *(аңа кушылып)*.

— Ул юк ителергә тиеш!

— Безнең девиз — хатын-кыздан башка тормыш.

— Хәйләсез-мәкерсез, алдаусыз тормыш!

— Чын ирләр тормышы.

— Без аларны куып җитеп, юк итәргә тиеш.

Ир-алла. Кагылмагыз аларга! Биредә әле мин алла. Кешеләр инде болай да бер-берләрен бик күп харап иттеләр. Хагына да, нахагына да, фикер өчен дә, гамәл өчен дә тәгәрәде адәм башлары. Җир йөзендә кешеләр бөтенләй әзәеп бара.

Яшь егетләр:

— Ә без, без кешеләр түгелмени?!

— Әнә бит без күпме, санап бетергесез.

— Без кешеләр, кешеләр, кешеләр без!

Яшь егет *(ир-алла каршына барып)*. Ишеттеңме, алла, кешеләр без. Һәм үзебезгә кешеләрчә мөнәсәбәт таләп итәбез.

Төркем:

— Таләп итәбез!

— Без дигәнчә булыр!

— Без сиңа ачулы, алла!

— Син үзең үк аллалык законнарын бозасың!

— Син, Ана, дип, хатын-кызны яклыйсың!

— Ләкин син без дигәнчә дә эшләячәксең әле!

— Эшләячәксең! Эшләячәксең! Эшләячәксең!

Гүләп чыгып китәләр.

Ир-алла. Ананың да сүзләрендә дөреслек бар бит — бу ясалма йөрәкле кешеләргә генә ышанып тапшырырга ярамый Җир шарын. Кайвакыт аларның салкын акылыннан мин үзем дә куркуга калам. Шулай ук, ялгыштыммы-

ни соң мин — ир-атлар алласы? Кешеләр калмый бит Җир йөзендә, кешеләр!

Сәхнәгә атылып Хатын-алла килеп керә. Ир-алланың аягына егыла.

Ир-алла. О, хатын-кыз алласы, ни булды сиңа? Ни китерде сине минем аяк астына?

Хатын-алла. Бәла! Илгә бәла килә! Барыгызга да һәлакәт килә! Коткар мине, о, ирләр алласы! Киләләр, арттан куа киләләр.

Ир-алла. Күңелеңә нинди шом төште, алиһә! Тынычлан, кулга ал үзеңне. Син бит хатын-кыз алласы!

Хатын-алла. Минем алла буласым килми. Килми! Минем гап-гади хатын-кыз буласым килә! Минем җылы учак янында утырасым килә. О, без нинди бәхетле булганбыз икән ул чагында! Без нинди ваемсыз һәм хәсрәтсез булганбыз! Ул чакларның бер генә көненә дә мин бөтен аллалыгымны бирер идем. Ләкин соң инде, алар безне юк итәчәкләр!

Ир-алла. О, курыкма, хатын-кыз, менә миңа, ир-атка таян. Нинди шом төште синең йөрәгеңә, сөйлә. Мин бит синең яклаучың.

Хатын-алла. Аһ, соң шул инде, соң. Алар бирегә киләләр, алар безнең икебезне дә юк итәчәкләр.

Ир-алла. Кемнәр сине шулай куркуга салды, хатын-кыз?

Хатын-алла. Бирегә ясалма йөрәкле халык килә. Алар мине аллалыктан кудылар, алар мине җир йөзеннән дә юк итәргә телиләр. Мәхәббәтне, хисне юк иткән кебек.

Ир-алла. Мәхәббәтне башта без үзебез юк иттек. Ул ясалма йөрәкле халыкны да үзебез уйлап таптык. Алар безнең иң куркыныч ялгышыбыз.

Хатын-алла. О, ир-ат, уйлап тап берәр нәрсә аларга каршы. Син бит көчле, акыллы зат идең. Коткар кешелекне бу бәладән!

Ир-алла дәшми.

Хатын-алла. Ник дәшмисең, ир-ат?

Ир дәшми.

Ник дәшмисең?! Кайда синең мәһабәт көчең, кайда синең зирәк акылың?

Ир-алла. Тормыш... йотты. Мәгънәсез, вак тормыш йотты барысын да. Бушлык, фикерсезлек йотты. Дөнья артыннан куу йотты. Аннары соң син менә үзең мине юкка чыгардың, хатын-кыз. Мин чүпрәк тә булдым, ишәккә, хайванга да әйләндем. Шулай итеп бәреле-сугыла, ир дигән исемнән коры гәүдәм генә торып калды. Мин үзем бүген ярдәмгә мохтаҗ, хатын-кыз!

Хатын-алла. О! О! Кемгә барыйк, нишлик. Әнә алар инде бүлмәгә керәләр, коткар мине, җаным? *(Иренә сыена.)*

Ашыгып ясалма йөрәкле яшь егетләр керә.

Яшь егет. Аллабыз, безнең тагын сиңа бер соравыбыз бар! Синең яныңда нинди җанвар ул?

Ир-алла. Ул... җанвар түгел, ул... хатын-кыз.

Яшь егет. Тагы хатын-кыз?! Син үзең безне хатын-кызда дошман күрергә өйрәттең, кайда очраса шунда аларны юк итәргә өндәдең. Бетсен хатын-кызлар! Алар ир-атларның мәңгелек дошманы!

Төркем:

— Мәңгелек дошманы!

— Мәңгелек дошманы!

Яшь егет. Бир син безгә бу хатын-кызны! Ананы да бездән качырдың, инде монысы бездән ычкынмас!

Төркем:

— Бир безгә бу хатын-кызны!

— Без аны юк итәргә телибез!

— Син үзең безне шулай өйрәттең!

Хатын *(иргә сыенып)*. Җаным! Коткар! Бирә күрмә мине алар кулына. Коткар! Колың булырмын! Тик коткар гына!

Төркем:
— Бу хатын-кызның урыны монда түгел!
— Ул юк ителергә тиеш!
— Бир безгә хатын-кызны!

Якынаялар. Ир белән хатын бер-берләренә ныграк сыеналар. Ишектән атылып ясалма йөрәкле кызлар килеп керә.

Хатын. Минекеләр дә килеп житте. Болай булгач, котылу юк икән.

Ир. Бәлки әле, безне ташлап, бер-берләре белән кызыксынып китәрләр. Ни әйтсәң дә, болары ир-ат, тегеләре — хатын-кыз җенесе бит.

Хатын. Соң аларда йөрәк юк бит! Йөрәк! Нинди кызыксыну, нинди хис булсын аларда!

Ир белән хатын, котлары чыгып, яшь егетләр, кызларга карап торалар. Тегеләре, бию ритмы астында, бер-берләренә якынаялар. Ике төркем — берсе башында — яшь егет, икенчесендә — яшь кыз.

Яшь егет. Син кем, хатын-кызмы?
Яшь кыз. Түгел.
Яшь егет. Ир-атмы?
Яшь кыз. Түгел.
Яшь егет. Кешеме соң син алайса, юкмы?
Яшь кыз. Белмим. Ә син кем?
Яшь егет. Мин дә белмим.
Яшь кыз. Син ир-атка охшаган.
Яшь егет. Ә син — хатын-кызга.
Яшь кыз. Ә синең мәхәббәтең бармы?
Яшь егет. Бу сүз миңа таныш түгел.

Яшь кыз. Мин тикшереп карарга тиеш. *(Салкын гына килеп егетне кочаклый. Пауза.)* Юк. Синең мәхәббәтең юк.

Яшь егет. Кайдан белдең?

Яшь кыз. Чөнки мин үзгәрмәдем. Мин акылымнан язмадым.

Яшь егет. Бу яхшымы, әллә начармы?

Я ш ь к ы з. Начар. Чөнки мин мәхәббәте хакына акылларыннан язган кешеләрне күрдем. Алар бездән бәхетлерәк иде.

Я ш ь е г е т. Ә кем гаепле соң безнең мәхәббәтебез юкка?

Я ш ь к ы з *(ир белән хатынга күрсәтеп)*. Алар. Алар безне дөньяга йөрәксез итеп яраттылар. Без — аларның гаебе, аларның ялгышы.

Я ш ь е г е т. Һәм без мәңгегә ясалма йөрәкле булып калачакбызмы?

Я ш ь к ы з. Әйе... Җирдә яңа кешелек туганчы...

Я ш ь е г е т. Нишләргә соң безгә, хатын-кызга охшаган ясалма йөрәкле бәндә?

Я ш ь к ы з. Башта аларны юк итәргә. Алар артык күп ялгыш ясадылар, ә җәзасын алмадылар.

Я ш ь е г е т *(алга чыгып)*. Әй, аллалар, без сезне юк итәргә тиеш!

Х а т ы н *(иренә сыенып)*. Ни өчен... сез безне юк итәргә уйладыгыз?

Я ш ь к ы з. Безне кеше итеп яратмаганыгыз өчен. Безне йөрәксез, хиссез итеп тудыруыгыз өчен. Безне мәхәббәттән, хистән мәхрүм иткәнегез өчен. Без сезнең ялгышыгыз! Мәңгелек ялгышыгыз. Бу ялгыш өчен кемдер җавап бирергә тиеш. Менә сез, аллалар, җавап бирерсез дә.

Х а т ы н. Ләкин без бит аллалар түгел, без гап-гади ир белән хатын. Безнең гаебебез юк сезнең каршыда.

Я ш ь к ы з. Ләкин кайчандыр сез безнең өчен алла идегез. Безне сез уйлап таптыгыз, сез тәрбияләдегез, җавапны да сез бирергә тиеш! Сез!

Өсләренә киләләр.

Ир белән хатын *(тезләнеп)*. Я, Алла, коткарсаң, син генә коткара аласың безне бу бәладән. Алар безне, кешеләрне юк итәчәкләр бит. Ярдәм ит, коткар безне, Алла?! *(Икәүләп, тезләнеп Аллага ялваралар.)*

Төркем һаман болар өстенә килә. Еракта Алла сурәте пәйда була. Ләкин ул дәшми. Боларның һәммәсенә карап, шаркылдап көлә башлый, бу көлү авазлары соңыннан елауга охшап, сулкылдау ишетелгәндәй була. Табигать-Алла әллә көлә, әллә елый — аңлап булмый.

Пәрдә

ЭЧТӘЛЕК

Атылган йолдыз

5

Сандугачның балалары

83

Вакыйга җүләрләр йортында бара...

116

Безне онытмагыз...

151

Аллалар ялгышы

203

Бәйрәмова Ф. Ә.

Б 86 Безне онытмагыз: пьесалар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1998.— 254 бит.
ISBN 5—298—00680—9

Фәүзия Бәйрәмованың иҗаты күпкырлы. Ул һәр жанрда диярлек җиңел яза: проза, шигырь, публицистика... Бу җыентыгына әдибәнең драма әсәрләре тупланды. Язылу чорлары төрле булган кебек, күтәргән проблемалары да, темалары да төрле.

Б $\frac{4702560203-018}{М 132(03)-98}$ 61—98

ББК 84(Р-Тат.)—6

Байрамова Фаузия Аухадиевна

НЕ ЗАБУДЬТЕ НАС

(на татарском языке)

ИБ № 6688

Рәссамы *Рушан Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире *Фәнүзә Кәбирова*
Корректоры *Мәрьям Хәйруллина*

Нәшриятка 0201 нче номерлы лицензия
1997 елның 22 августында бирелгән.

Җыярга тапшырылды 8.07.97. Басарга кул куелды 18.02.98. Форматы 70×108 1/32. Типогр. кәгазе № 2. «Тип-Таймс» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 11,20. Шартлы буяу-оттиск 11,55. Нәшер-хисап табагы 16,60. Тиражы 3000 экз. Заказ Е-381.

Татарстан китап нәшрияты. 420503. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420503. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты типографиясе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.